ҖИДЕ ЮЛ ЧАТЫНДА



ҖИДЕ ЮЛ ЧАТЫНДА

Казан
Татарстан китап нәшрияты
1990

ББК 74.200.52
Ж38

Төзүчесе — *Газинур Вәлиев*
Редакторы — *Язилә Абдулкадыйрова*

Жиде юл чатында. Очерклар, әңгәмәләр җыентыгы.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.— 191 бит.
Ж38
ISBN 5—298—00899—2

Бу китапка үзенчәлекле язмышка, гадәттән тыш сәләткә ия булучыларның кызыклы тормышлары, аларның хезмәт һәм иҗади уңышлары турындагы язмалар тупланган.
Җыентык киң катлау укучыларга багышлана, шулай ук киләчәген, хезмәт юлын әле анык кына күзаллый алмаган үсмерләр, яшьләр өчен дә ул файдалы булыр дип ышанабыз.

Ж $\frac{0605010203-178}{М\ 132(03)-90}$ 11—90
ББК 74.200.52

ISBN 5—298—00899—2
© Газинур Вәлиев, төзү. 1990

ЖЫРЧЫ

Бер караганда, әллә ни гаҗәпләнерлеге дә юктыр инде аның,— кайсы гына ана сурәтенә карап күзләрнең туя алганы бар соң әле?! Ә шулай да гаҗәп: күзләремне ян стенага эленгән бу ана рәсеменнән һич кенә дә ала алмыйм. Әңгәмәдәшем гаять тә кызыклы, кешелекнең рухи яшәеше өчен бик тә әһәмиятле хасиятләрне үз тормышы, үзенең бай тәҗрибәсеннән чыккан фәлсәфи йомгаклар, мисаллар белән раслый-раслый сөйләп утыра. (Каян килгән аңа бу рух хакимлеге, каян килә бу гыйбрәтле акыл?!) Ул — ярты гасырлык гомеренең утыз елын тормыш мәгънәсен аңларга, аңлатырга багышлаган, исеме илгә генә түгел, дөньяга билгеле булган җырчы-фикер иясе. Стенада — рәсем. Ияк астыннан пөхтә итеп бәйләгән кәшемир яулык, яулыгы кырыеннан әз генә чыгып торган маңгай чәчләре (менә хәзер генә төзәтеп куйган да, бөртекләренә сеңеп калган бармак җылылары биткә килеп кагыла сыман) һәм күңел тынычлыгы килгән имин генә ялгыз бер сәгатьтә, ерак гамьнәргә бирелеп тирән уйга чумган, илаһи бер моң әлпәсе каплаган зәңгәр күзләр. Ана күзләре, ананың чал чәчләре...

Аһ, кадерләре шулкадәр дә арта әниләрнең, гомерләр узып, сулар агып киткәч! Хатлар да барып ирешмәс көннәр җиткәч!..

«Әниемә хат» җырын хәтерлисездер әле. Егерме ел инде бу җыр яныбызда булганда кадерләрен белеп бетермәгән әниләребезгә кулга кәгазь-каләм алып хатлар язарга

да вакыт чамалары азрак булган ул-кызларның рыясыз күз яшьләре түккән мизгелләрен җиләс таң җилләре, кичке алсу шәфәкъләр, төнге тымызык яңгырларда лепердәшкән яфрак өннәре булып хәбәр итә. Кайсы ана йөрәге сизмәде дисең моны? Кайсы угыл-кыз күңелен моң сармады ул җырдан?!

Хәтердә шул, истә. Әле дә истә!

Тәүге яңгыраган көннәрендә Татарстан радиосына, аны гына һәм бары тик аны гына һәм ул гына һәм бары тик ул — Илһам Шакиров җырлавында гына аналарга сәлам итеп тапшыруны үтенеп, йөзләгән-меңләгән хатлар яуды. Эфирны тутырып, калалар, салалар, далаларга моң тулы бер җыр агылды. Җырчы авазы шул угыллар, шул кызларның сагыну сәламе иде бит, моны Илһам Шакиров кына түгел, алар җырлый, алар көйли, алар моңая иде. Үзең җырлаганга күрә дә шундый якын, шундый газиз җан авазына әверелде дә ул.

Әмма кайда туган да, кайлардан килеп чыккан соң әле ул — үзе һәркемгә дә уртак, үзе бер генә кеше авызыннан ил-күкләренә ашкан бу моң?

Кырый стенадагы рәсемнән арына алмыйм. Күз һаман шунда тартыла. И, тимерче Гыйльметдин хатыны нурлы Нуриәсма апа! Күзләреңдәге моң суларын ни дип бүләк иттең икән син бу угълыңа? Ни дип аңа Илһам дип исем куштыгыз икән соң сез — әти-әни?

Сиңа карыйм, оланыңа карыйм: икегез дә шундый охшагансыз, икегез дә моңлы карашлы. Исән булсаң, әйтеп кенә бирер идең дә бит: «Без генә моңлы идекмени соң ул чакларда? Бөтен илен моң баскан иде ләбаса аның...» — дияр идең дә...

— Моң, дисез...— Бераз уйланып торгач, Илһам, сүзен дәвам итә.— Моң булмыйча ни булсын соң? Ни генә күрмәгән халык!.. Борынгысын әйтеп тә торасы юк инде, ә безнең гомердәгесе... Ул сугыш ачылары... Ул әти-абыйларларның үлем хәбәрләре... Түзгәннәр инде бичара әниләр. Куллары да түзгән, рухлары да сүнмәгән. Күтәргәннәр, үстергәннәр бит әле безне, хәлләр житкән... Моң — шул инде ул, минемчә: агач башыннан түгел, кеше, ил башыннан йөри торган язмыш җилләре авазы ни сөйләсә, җырдагы моң да шул буладыр инде ул.

— Моң — халкыбыз хәләтенең иң асылларыннан берсе, димәк? Талант — халык байлыгы, дибез. Бәс алай икән, «талант» белән «моң» сүзләрен бер тактага куеп буламы?

— Әйе, моңсыз талантны, көйсез, ваемсыз һәм, ниһаять, гамьсез талантны мин чын талант дип әйтә алмас

идем. Сәләт анысы, мәгълүм дәрәҗәдә, булырга мөмкин әле... Ләкин талант?.. Юк, талант ул кайгы-хәсрәтне уратып үтә алмый. Әнә ич Тукай да:

«Мискин адәм! Тыштан уйный, тыштан көлә,
Яман якны уйлап куя эчтән генә.
Безнең гомер уен түгел, бәйрәм түгел,—
Бер кайгысыз кеше булса, адәм түгел!» —

дип язып калдырган. Яки менә монысы:

«Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,
Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен...»

Менә шулай җырчы сәгатьләр буе Тукайны, Такташны; Пушкинны, Лермонтовны; Җәлилне, Туфанны; Бодлерны, Байронны; Сибгат Хәкимне, Зөлфәтне... яттан укый ала. Һәркем кызыгырлык хәтер, теләсә кем көнләшерлек кызыксынулар даирәсе... Һәм бу, белдеклелекне бер ялтыратып алып, «ушны җибәрү» өчен эшләнми, юк, бу — аның тормыш фәлсәфәсе, бөек гакыл һәм сәнгать иҗләре дәрәҗәсе белән үз аршыныңны үлчәп карау; бу — камиллеккә омтылу: кеше буларак та, сәнгать әһеле буларак та...

— Әмма сез әнә күпме гомер зур сәнгатьтә бит инде. Сез йөзләрчә җыр җырлаган кеше. Сезне яраталар талантыгыз алдында миллионнар сәҗдәгә китә. Тагын да камилрәк булырга мөмкинме соң инде?

Рәхәтләнеп көлеп җибәрә җырчыбыз. Аннары кинәт кенә — житди йөз. Кыска гына тын алу. Фикер туа:

— Мөмкин генәме соң?! Кирәк — су, һава кебек зарур процесс ул. Камиллеккә ирештем, дип, беркем дә, бер генә рәссам да әйтә алмас. Галәмнең чиге булмаган кебек, камиллекнең дә очы-кырые юк аның. Рәссамнарның иң камиле, дисәк инде, анысы — халык булыр, әлбәттә. Менә анда инде — җәүһәрләр, анда инде — энҗеләр! Ләкин анда да әле «Һәр ялтыраган алтын түгел». Белинский әнә нәрсә ди: «Халыкта бөтенесе дә халыкчан түгел»,— ди. Бик килешәм бу фикер белән. Шуңа күрә җырлар сайлаганда, эзләгәндә, тапканда бик талымлы, сизгер булырга кирәк... Аеруча яшьләргә. Чөнки сәнгатебезнең киләчәге алар кулында булачак. Аң талымы белән күңел сизгерлеге — ул шул ук камиллек манарасының ташлары инде...

Күзем ян стенага төшә. Ярабби, елмаеп куйды түгелме соң ана? Елмайды шул, бөтен йөзенә гаҗәеп бер сөенү җылысы йөгерде. «Кара син аны,— ди бугай ул.— Сарманнан кирза итек киеп укырга дип кенә чыгып киткән иде бу бала, әнә нинди акыллы сүзләр сөйли, гыйлем иясе дә булган түгелме соң бу олан?»

Куан, апа! Сезгер күңелле оланыңа барыр юлларында сезгер күңелле акыллы абыйлар да, апалар да туры килде. Аларга юлыкмаган булса... Алар очрамаса, ул Казан консерваториясенең авыр ишекләрен авылдан килеп ачып кергән була алыр идеме икән... Алар аңа үзләре язган җырларны беренче булып башкарырга ышанып тапшырдылар. Махсус аның тавышына исәп тотып, җырлар яздылар. Аркасыннан сөеп кактылар, матур-матур сүзләр каттылар. Мансур Мозаффаров, Нәҗип Җиһанов, Заһит Хәбибуллин, Александр Ключарев, Рөстәм Яхин кебек ил күрке булган олы аксакаллар улыңның дус абыйлары булды. Сәнгатебез күгендә якты йолдыз булган Гөлсем Сөләйманова, Рәшит Ваһапов, аңа хәерле юл теләп, соң тапкыр балкып, бәхилләшеп киттеләр....

Истә, барысы да истә... «Һаман истә»...

1965 нче ел. Радионың концерт студиясе. Пульт янында тавыш режиссеры композитор Исмай ага Шәмсетдинов. Аның сабыр фәрманы яңгырый: «Дикъкать! Башладык!» Һәм шундый бер моңлы көй агылып китте ки, без, ул вакытта радиода эшләүчеләр, колакларыбызны торгыздык. Тавыш режиссеры бүлмәсенең ачыграк калган ишеге төбенә өелдек. (Җыр язганда, әчкә үтәргә рөхсәт ителми.) Бу — моңарчы беребез дә ишетмәгән, туган як җилләредәй саф, аның чишмәләренең салкын суларыдай татлы, йөрәкләрне чемердәтеп куя торган яңа гаҗәеп бер могҗизага тиң моң иде. Шулай тоелды ул чакны безгә «Һаман истә» дигән бу көй. ...Ул көнне, ул көнне генә түгел, аннан соң да озак кына вакыт әле күбебез бу көйнең, халык көе булмыйча, Илһам Шакировның үз йөрәгеннән саркып чыккан моңы, үзе язган көй икәнен белми иде. Халык көе түгел үзе (композитор белән шагыйрь Ләбиб Айтуганов язган), ә нәкъ халыкныкы кебек агыла. Могҗиза түгелмени шул?!

Икенче көнне музыкаль редакциягә композитор Рөстәм Яхин килеп керә. Язылган җырны тыңлау бара. Җыр тәмам була. Тынлык урнаша. Рөстәм ага шунда:

— Татар көенең квинтэссенциясе, каймагы инде бу, егетләр,— дип куя. Үзенә дә бик таләпчән бу композитор авызынан андый мактау сүзе ишетү гаять зур дәрәҗә икәнен истә тотыйк. Ул да бу көйнең Илһам Шакиров көе икәнлеген белми әле. Менә шулай авторның үз теләге белән бу гүзәл сәнгать әсәре «халыкныкы» булды да калды. Ул гынамы соң? Ә «Син сазыңны уйнадың», ә «Гөлмәрьям»? «Идел буе каешлары», «Сәлам сезгә»?.. Боларын да Илһам Шакиров иҗат иткән бит. Ә күбесе халык көе дип

җырлана да, тапшырыла да аларның. Җырчы авторлыкны дәгъва кылмый гына түгел, киресенчә, әсәрен халыкныкы дип әйтергә кыенсынганда гына үз исемен әйттерә. Менә шундый тыйнаклык инде... Халкыбыз сыйфаты, этиэлидән килгән хасият.

— «Халык» дигәннән... Сезне яратып тыңлаучы миллионлаган халыкның җыры сезнең аңлауда нәрсә ул?

— Башта без Тукайның мәгълүм билгеләмәсен искә төшереп үтик. «Халык җырлары — ул халык күңеленең саф вә раушан көзгеседер»,— ди ул. Моннан да кыска һәм төгәл итеп беркем дә әйтә алмастыр... Халык күңеле...

— Исемә 1966 ел килеп төшә,— дип дәвам итә җырчы.— Ул елны Мәскәүдә Муса Җәлилнең 60 еллыгы бик зурлап билгеләп үтелде. Тантаналы кичәдә мин нигездә халык җырларын җырладым... Язучыларның Үзәк йортындагы икенче кичәдә немец язучысы Леон Небенцаль минем янга килде дә: «Кичә җырлаган «Карурман»ны җырлагыз әле, зинһар»,— дип үтенде. Мин гаҗәпләнебрәк калдым. Бу ерак кунакка татар җыры ник кирәккән икән, дим. Җырлавын җырладым, әлбәттә. Алкышларга күмделәр. Леон Небенцаль сүз сорап торып басты да болай диде: «Дөньяда күпме патшалар беткән, күпме дәүләтләр юкка чыккан, ә менә хәсрәт моңы югалмый, гасырлар буе яши, һаман йөрәкне яндыра, уйландыра...»

— Немец язучысы бу җырны тыңлаганда нәрсә аңлады, нәрсәләр турында уйланды икән соң? Музыкаль дөньяларыбыз бик нык аерыла бит, аеруча халкыбыз музыкалары... Берсебез, кем әйтмешли, мәгърибтә, беребез мәшрикътә бит. Һәм ни өчен ул нәкъ менә «Карурман»ны тыңларга теләгән икән?

— Бу хакта мин дә шактый озак уйландым... Леон Небенцаль — күренекле язучы, ә язучы кеше кызыксынмаган бер нәрсә дә юк дөньяда. Аның өчен һәрнәрсә мөһим, һәрнәрсә әһәмиятле. (Бөтен кеше дә шулай булса иде!) Ерак бер халыкның моңы белән танышу аңа, әлбәттә, кызыклы булган булырга тиеш. Андый очракны мин үзем дә кулдан ычкындырмаган булыр идем. Ә менә ни өчен ул «Карурман»га тукталган? Монысы — кызык инде. Леон Небенцаль бит Муса Җәлил турында китаплар язган, «Кызыл ромашка» дигән фильм төшерүдә булышкан кеше. Аңа, әлбәттә, Җәлилнең каһарманлыгы тамырына тирәнрәк, һаман тирәнрәк төшү кирәк булырга тиеш. Нинди туфракта шыткан бу тиңсез батырлык, нинди рух чишмәләре суында коенган ул? Язучыны тоемы алдамый, юк. «Карурман» ирек турында җыр, якты иркен дөнья, бергәлек-бердәм-

лек турында хәсрәтле гимн лабаса. Җырларны үлеп яраткан батырыбыз йөрәген алар да сугарган, алар да тәрбияләгән, билгеле.

Кеше гомере буе тәрбияләнә, беребез дә хатадан хали түгел. Үз хезмәт өлкәмә килгәндә, сәнгатьчә рухта тәрбияләү — ил кешеләрнең каты күңелләрен йомшарту, күгәрек баса башлаган йөрәкләрен сөртү, саф күңелләрне тагын да сафрак итү. Киләчәккә саф күңелле кешеләр генә барсын иде:

...Күзем ихтыярсыз ян стенага төшә: ә ана бу хакта ни уйлый икән? Ул, кыймылдап, безгә таба борылыбрак куйгандай итте. Күз төбендәге җыерчыклары ишәебрәк киткән сыман булды. Юк, картайганнан түгел, алар — сөйкемле бите буйлап сузылган елмаю нурлары гына иде. Моңлы бер елмаю. «Улым шулай дигәч, шулайдыр инде»,— дип баш кага сыман ул. Әйе, шулайдыр шул, и, тимерче Гыйльметдин хатыны, мәшһүр җырчы анасы нурлы Нуриәсма апа!

Эльс Гаделев

ГАРМУН БӘЛӘКӘЙ БУЛСА ДА...

Авылга Казан артистлары килү турындагы хәбәр яшен тизлеге белән таралды. Кичен клуб янына махсус ясалган сәхнә тирәсен олысы-кечесе, яше-карты сырып алды. Артистларны яхшылап күрү өчен койма башларына, хәтта клуб түбәсенә үк менеп кунаклаучылар да бар.

Менә сәхнәгә эреле-ваклы гармуннар белән тулы өстәл чыгарып куйдылар. Гармунчысы да озак көттермәде. Кара түбәтәйле башын кыңгыррак салып, үз гармунының тавышына үзе хәйран калган кыяфәттә уйнап та җибәрде. Ул уйный башлаганда нинди торышта булсалар, тыңлаучылар, сихерләнгәндәй, шул хәлдә калдылар. Суламыйлар да иде бугай алар бу минуттта. Көй артыннан көй агылды: «Сандугач», «Салкын чишмә», «Күбәләгем»... Безнең күзләргә гармунчы үзе инде күренми дә башлады сыман. Кичке тынлыкта бары яралы кошчыктай талпынучы гармун гына торып калган. Тартыла, бәргәләнә, өзгәләнә... Бер елый, бер көлә ул, җаныңны әле күкләргә алып менә, әле агымсуларга илтеп сала...

Гармун бәләкәй булса да,
Әйтә үз кирәкләрен...

Әйтте гармун. Авыл егетенең күрше кызына белдерә алмыйча йөргән яшерен мәхәббәтен дә әйтте, ирләре сугыштан кайтмаган хатыннарның еллар буе йөрәгендә йөрткән сагышын да чыгарып түкте, чишмә булып та челтерәде ул, сандугач булып та сайрады.

Без ул көнне музыканың, моңның тирәнлегенә, зурлыгына хәйран калдык, халкыбызның шундый гармуннары һәм гармунчылары булуы өчен сөендек. Искиткеч көйләре белән авылны сихерләп киткән кеше атаклы гармунчы Гали ага Җәмлиханов иде.

Әлеге язмабызның герое — бүгенге әңгәмәдәшебез — әнә шул матур традицияне дәвам иттерүче, концерт гармуннарында уйнау остасы, ТАССРның халык артисты, музыка коралларында уйнаучыларның Бөтенроссия һәм Бөтенсоюз конкурслары дипломанты Рәшит Мостафин.

— Рәшит, сез — гармунны-моңны гомерлек юлдаш итеп сайлаган кеше. Беренче тапкыр гармун тавышын кайчан ишеткәнегезне хәтерләмисезме?

— Минем әти гармунда уйнаган. Тальянда. Тик ул чакта миңа бер яшь чамасы гына булган. Ә хәтердә калган гармун моңнары — авылдагы печән өмәләреннән, сабан туйларыннан. Әле дә исемдә: Сосна (Балтач районы) сабан туена халык күрше-тирә авыллардан да җыела иде. Машиналар белән дә киләләр, атлар белән дә, җәяүләп тә. Һәм, әлбәттә, сабантуйга гармуннар килә. Мин көне буе шуларны тыңлыйм. 6—7 яшьләремдә шундый сабантуйларның берсендә кемнеңдер искиткеч моңлы итеп әлегә кадәр мин белмәгән көй уйнавын ишеттем. Үзенә тартып алды мине ул көй. Сабантуй тарала башлаган чак иде. Гармунчы утырган ат артыннан ияреп киткәнмен. Күрше Кариле авылына барып җитүемне дә сизмәгәнмен. Ул көй «Сания апа» көе булып чыкты.

— Гармунда уйнарга кайчан өйрәндегез? Беренче башкарган көегез нинди иде?

— Сүзне уйнаудан башлагач, уйнаудан булсын инде: мин кечкенә чакта катыргы тартманы, капкачын ача-яба, гармун итеп уйнаганмын. Соңрак чын гармунны да тотып карадым. Ә беренче тапкыр кулыма гармун тотып беренче көй өйрәнүем беренче класста укыганда булды. Әнинең энесе Исмәгыйль абыйның венский гармунында. «Мәк чәчәге» исемле халык көе — минем беренче башкарган көем. Ул өстәге клавишлардан башлана, уйнарга җиңелрәк иде. Аннан соң ишеткән һәр яңа көй минем өчен яңа бер дөнья

булды. Үзебезнең урамдагы скрипкачы бабай уйнаган көйләрне отып калырга тырышып, артыннан ияреп йөрүем әле дә хәтердә.

— Ә концерт гармуннарына кайчан алындыгыз?

— Фәйзулла Туишев, Гали Җәмлиханов, Фәйзи Биккинин кебек виртуоз гармунчыларның уйнавын күп тапкырлар сокланып тыңлаганым бар иде. Әмма әле ул чакларда кайчан да булса үземнең берәр вакыт шундый гармуннарда уйнавымны башыма да китерми идем. Барысына да Татарстан җыр һәм бию ансамбленә эшкә килүем сәбәп булды. Шунда Фәйзи һәм Гали абыйлар белән таныштым. Аларга кушылып баянда уйный идем...

Бервакыт Чаллыда гастрольдә вакытта Гали абый миңа үз һөнәрен өйрәтә башлады. Икәү ванна бүлмәсенә кереп бикләндек (һәр бүлмәдә репетиция бара). Ул концерт гармунында уйнау алымнарын күрсәтә. Ә минем кул баянга күнеккән, ул күрсәткәннәрне булдыра алмыйм гына бит! Байтак азапландык. Ахырда Гали абый түзмәде, маңгаеннан тирен сөртеп алды да, кулын селтәп әйтте: «Юкка маташабыз бугай ла, энем. Бер дә өйрәнергә ошамагансың!»

Аның бу сүзләре күземнән яшьләр килер дәрәҗәгә җиткерде. Ләкин максаттан кире чигенмәдем, буш вакыт булган саен кулга кечкенә гамуннарны алдым.

Беренче тапкыр тамашачы алдына концерт гармунында аерым номер белән 1970 елда чыктым. «Күзләр» спектакленнән Рәйсә җырын башкардым. Зал тыенкы гына кабул итте. Шулай да бу тамашачы өчен ачыш иде. Сәхнәдән чыккач, беренче булып Гали абый кулымны кысып кысты: «Рәхмәт, энем, шулай дәвам ит!»

— Рәшит, концерт гармуннарының тарихы белән дә таныштырып китсәгез иде.

— Аның тарихы әллә ни зур түгел. Узган гасырның 70 нче елларында Тула шәһәрендә Белобородов дигән гармун мастеры үзенең кияве Петр Невскийга вак гармуннар — «черепашкалар» ясап бирә. Тегесе шуларда уйнарга өйрәнә һәм циркта аерым номер белән чыгыш ясап йөри. Гастрольләрнең берсендә Фәйзулла абый Туишев шушы Петр Невскийга йомышчы булып ияреп китә һәм кечкенә гармуннарда уйнарга өйрәнә. Берничә елдан эстафетаны Фәйзулла абыйның туганының малае Гали абый кабул итеп ала.

Фәйзи Биккинин исә 30 нчы елларга кадәр скрипкачы булган кеше. Фәйзулла абыйның дәртле-моңлы һөнәре аны да үзенә тарткан.

— Концерт гармуннарын каян аласыз? Аларны үзең ясау мөмкинлеге юкмы?

— Мин Фәйзи ага Биккинин вафат булгач, аның гармуннарын сатып алдым. Барысы сигез гармун иде. Ләкин алар вакыт узу белән туза, таушала. Яңалары беркайда да ясалмый. Элекке гармуннар үрнәгендә заказ биреп ясатсаң гына инде. Миңа, мәсәлән, берничә гармунны Казан гармун фабрикасы мастеры Салих абый Шәйдуллин ясап бирде.

Гармуннарны үзең ясау — катлаулы эш, әмма кулдан килмәслек түгел. Аның өчен билгеле бер күнекмәләр, тәҗрибә һәм материал гына кирәк. Минем күп кенә гармуннарны ремонтлаганым бар. Алга таба үзем ясап карарга да исәп юк түгел. Фәйзулла абыйның Татарстан дәүләт музеендагы гармуннарыннан күчермә алырга иде. Әйбәт гармуннар алар.

— Сәнгатьнең бер төре буларак, концерт гармуннарының киләчәген ничегрәк күз алдына китерәсез?

— Үсәргә, киләчәк сәхнәсеннән дә үзенә урын дауларга хаклы тармак бу. Бу гармуннарда яңгыраган көйләрне халык кайда да алкышларга күмә. Аннан соң хәзер бу төр сәнгатебезнең милли үзенчәлеге буларак та ныгыды. Концерт гармуннарында уйнаучылар илебездәге башка милләт халыкларында очрамый диярлек.

Тагын шунысын да әйтергә кирәк: концерт гармуннарының мөмкинлекләре зур. Миңа симфоник оркестрга кушылып Җ. Фәйзинең концерт гармуны өчен пьесасын башкарырга туры килгәне бар. Ул чыгыш шушы кечкенә гармунның киң сулышы, олы тойгыларны тапшырырга сәләтле инструмент икәнлеген күрсәтте. Анда классик әсәрләр белән беррәттән халык көйләрен дә бик күп интерпретацияләр ясап уйнарга була. Шунысы кызганыч: композиторларыбыз концерт гармуны өчен махсус әсәрләр язмыйлар диярлек. Безгә скрипка яки гобой өчен язылган әсәрләрне үзебез өчен эшкәртеп уйнарга туры килә. А. Ключаревның «Тау әкияте» балетыннан бию, Х. Вәлиуллинның скрипка өчен язылган биюе әнә шундыйлардан.

— Фәйзулла абыйлар башлаган эшне сезнең кебек дәвам итәрдәй яшьләр үсәме?

— Концрет гармуннарында уйнаучылар күп түгел. Фәйзи Садыйков, Мостафа Сәлахетдинов һәм тагын берничә һәвәскәр башкаручы. Инде алар да өлкән яшьтәгеләр. Культура институтында укучы яшьләр арасында да бу һөнәргә өйрәнүчеләр булгалый булса кирәк. Ләкин әле бу җитәрлек түгел, минемчә. Яшьләрне күбрәк тартасы иде.

Моның өчен культура уку йортларында концрет гармуны буенча махсус дәресләр кертәндә, анда уйнау өчен кулланмалар чыгарганда да яхшы булыр иде. Кыскасы, концерт гармуны үзенә юл ачуны сорый.

— Халык сезне яратып кабул итә дидегез. Ә сезнең үзегезгә нәрсә бирә бу гармуннар...

— Әйе, моң халык йөрәгенә юлны тиз сала. Таныштыра, күңелләрне берләштерә. Шулай, узган ел Иркутск шәһәрендә безнең концертлар бара. Бер көнне концерттан соң яныма бер картны алып килделәр (ул үзе йөри алмый иде). Хәрби кеше булган, гомере туган җирдән читтә узган. Күзендә — яше, авызында — сүзе. Ул бик гозерләп өенә чакырды: «Гомерем буе саклаган гармуным бар, уйнап карасагыз иде...» Бардык. Ундүрт телле тальян. Уйнадым. Тагын сорап уйнатты, тагын... «Гармун тереләе, киң сулап җибәрде»,— ди. Ахырдан гармунын миңа васыять итте.

Бу вакыйга нык тәэсирләндерде. Әйтерсең гади бер карт түгел, гармунының язмышын миңа халык ышанып тапшыра иде...

— Рәшит, сезне гармунгыздан аердылар ди...

— Гармуннан язган гармунчы — баласыннан язган кош ул. Мондый хәлнең шаһиты булырга туры килгәне бар.

Гали абый Җәмлихановка лаеклы ялга китәр вакыт җитте. Менә соңгы гастрольдә генә йөреп кайтасы да...

Ләкин шушы соңгы гастроль аңа искиткеч зур югалту китерде: Казанга кайтышлый поездда гармуннар салынган чемоданын урлап киттеләр. Аның ничек өзгәләнгәнен күрсәгез иде сез!..

Тырышканда, гармуннарны кабат табып та була, аларда уйнау мөмкинлегеннән мәхрүм итмәсен язмыш...

— Сезнең яраткан шөгылегез нинди?

— Мотоциклда йөрергә ратам. Музыка инструментлары һәм радиоаппаратура ремонтлау да минем өчен бик мавыктыргыч шөгыль. Шулай да иң мавыктырганы һаман да музыка, халык моңнары, халык аһәңнәре. Ял вакыты да күпчелек шулар белән үтә. Хәер, ял вакыты гына түгел, гомер бөтенләе белән шул моңнарда безнең...

Ә бит без дә гомер буе алар көйләгән моңнарга гашыйкбыз.

Харрас Әюпов

СҮЗ КӨЧЕ

Муса Җәлилнең атаклы «Моабит дәфтәре» туган илебезгә исән-имин кайтып ирешкән еллар иде. Ул ялкынлы шигырьләрне безнең Әлки якларына якташыбыз — нәфис сүз остасы Әзәл Яһүдин алып кайтты дисәк, ялгышмамдыр. Чөнки патриот-шагыйрьнең фашист тоткынлыгында да какшамаган коммунистик рухын, баш очында палач балтасы торганда да елмаерга-көләргә көч табуын бөтен тулылыгы белән тоярга безгә ул вакытта Әзәл Яһүдин ярдәм итте.

Беренче мәртәбә «тере артист» күргәнгәме (артистның да нindие генә әле; үзе сөйли, үзе гармун уйнап җырлый, кирәксә: тыпыр-тыпыр биеп тә китә), я булмаса Муса Җәлил шигырьләренең ялкыныннанмы, без — Алпар урта мәктәбенең ул вакыттагы укучылары — искиткеч тәэсирләнеп калган идек. Тамаша залын бер артистның сәгатьләр буе үз авызына каратып тота алганлыгын безнең моңарчы күргәнебез дә ишеткәнебез дә юк иде. Менә шигырьне ничек яңгыратырга мөмкин икән! Сөйли белеп сөйләгәндә әсәрнең аһәңе, кодрәте әнә ничек арта икән. Менә ул профессиональ сәнгать дигәннәре нинди була икән!

Ул еллардан соң инде шактый җилләр исте. Совет Армиясе сафларыннан кайтып, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында укый башлагач, аннары газета редакциясендә эшләү елларында Әзәл ага Яһүдин концертларын күп тапкыр күрү-тыңлау, артистның үзе белән дә якыннан танышып, аралашып яшәү бәхетенә ирештем. Ләкин аны авыл сәхнәсендә беренче мәртәбә күрүнең хатирәсе күңелдә аеруча якты бер нур булып саклана. Күрәсең, сагынылган, көтеп алынган яңгыр болыты кебек, ул безнең сәнгатькә сусаган күңел кылларыбызга бик вакытлы килеп «яуган яңгыр» булгандыр.

Бүгенге очрашуга да ул концерт белән авылларга чыгып китәр алдыннан, ашыгып, җил-җил атлап килеп керде.

— Кичкә таба үзебезнең «мишәрстанга» очам,— диде ул,— Чистай якларына. Утызлап чыгыш ясарга исәп. Филармониядән барасы нәфис сүз остасы авырган. Үтенгәч, бик теләп барырга булдым.

— Ярты гасырдан артык сәхнә хезмәтегездә шактыйга җыеладыр Сезнең мондый командировкалар, Әзәл ага?

— Һи, башымдагы чәчем дә җитмәс. Бөек Ватан сугышы елларында госпитальләрдә генә дә 400 дән артык шефлык концертында катнашырга туры килде. Ул вакытта

мин Татар дәүләт академия театрының хәрби шефлык комиссиясе председателе идем. Бу комиссия составындагы артистлар барысы 600 ләп концрет куйдылар...

50 нче еллардан соң янә исәп-хисап алып бара башладым. Бүгенгәчә 6 меңгә якын концерт бирелгән. Кайда нинди әсәрләр сөйләгәнемне махсус дәфтәрләргә язып барам. Бу — бүгенгечә итеп әйтсәк — хезмәтне фәнни оештыру, хуҗалык исәбе алып бару кебегрәк нәрсә була инде. Болай эшләү теге яки бу урында кабат чыгыш ясаганда үз-үзеңне кабатламас өчен дә кирәк. Югыйсә кайларда гына булынмады бит инде. Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшләгәндә, башка сәхнә осталары белән берлектә, гастрольләрдә Балтик буе белән Ерак Көнчыгыш арасындагы шәһәрләрдә, илебезнең иң эре промышленность үзәкләрендә, шахтерлар янында булдык. Урал — Себер якларындагы төзелешләрдә, Урта Азия, Кавказ республикаларында, Украина һәм Идел буе өлкәләрендә күп тапкырлар чыгыш ясарга туры килде. Ә үзебезнең Татарстан районнарын гына димим, хәтта һәрбер авылны, һәр шәһәрне берничәшәр тапкыр йөреп чыктык. Шуңа күрә заман рухын күздә тотып, репертуарны яңартып торырга туры килә.

— Әзәл ага, сез репертуарыгызны төзегәндә нәрсәләргә әһәмият бирәсез?

— Беренче шарт — әсәрләрнең көнүзәк әһәмиятлелеге. Аларның югары сәнгатьле булуы. Икенче шарт — әсәр тыңлау өчен күңелле булсын, ялыктырмасын. Ләкин шунысы да бар: һәрбер яхшы әсәр сәхнәдән тиешенчә яңгырамаска да мөмкин. Аннары һәрбер артистның үз амплуасы, үз мөмкинлекләре дә бар бит әле. Юрганыңа күрә аягыңны сузасың. Мине «тыңларга теләмәгән» кайбер шигырьләр, мәсәлән, бүтән артистлар тарафыннан менә дигән итеп башкарылырга мөмкин. Халык йөрәгенә үткәрерлек итеп сөйләүгә иманың камил булмаганда, шигырьне әрәм итмәү хәерлерәк. Сәхнәдән әсәр сөйләгәндә, үзеңнең генә түгел, язучының да абруе турында истә тотарга кирәк.

— Сезне «яхшы тыңлый», сезгә «буйсына» торган әсәрләр дип нәрсәләрне саныйсыз?

— Моны мин үзем дә тамашачылардан гына беләм. Габдулла Тукайның юмористик шигырьләрен, Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре»ндәге әсәрләрне һәм «Хат ташучы» поэмасын, Габдрахман Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» романыннан «Шаһиевның өйләнүе» турындагы өзекне, Сибгат Хәкимнең «Кырыгынчы бүлмә», Әнвәр Давыдовның «Алтын көз», Мөхәммәт Садриның «Бәхет турында

җыр» поэмаларын һәм, әлбәттә, Фатих Кәримнең «Кыңгыраулы яшел гармун»ын тамашачы бик яратып кабул итә. Сәхнәгә җибәргән кош теледәй язуларда, үземә язылган тамашачы хатларында әлеге әсәрләрне күбрәк башкаруымны сорыйлар.

— Сез бервакыт «Кыңгыраулы яшел гармун» әсәрен башкару өчен авторның үз фатихасын алуыгыз турында язып та чыккан идегез...

— Әйе... 1942 елның җәендә фронттан яраланып кайткан Фатих Кәрим бу әсәрен Казан госпиталендә дәваланганда иҗат итте. Беренче тапкыр аны сәхнәдән Хәким Сәлимҗанов сөйләде. Мин бу әсәре бик тә ошаттым. Һәм, аны музыка белән башкарып булмый микән, дип уйладым. Җыр өчен музыка сайлашуда миңа композитор Җәүдәт Фәйзи ярдәм итте. 1942 елның декабрь азагында Фатих Кәрим сәламәтләнеп чыккач, фронтка китәр алдыннан аңа «Кыңгыраулы яшел гармун»ын сузып җибәрдем. Фатих Кәрим игътибар белән тыңлады. Мин башкарып чыкканнан соң дулкынланып кулымны кысты да: «Бик рәхмәт, Әзәл туган, әйбәт чыккан бу!»— диде. Менә шуннан бирле бу үлемсез әсәрне дүрт мең мәртәбәдән артык башкардым инде. Бу әсәр миңа авыр сугыш елларын, госпитальләрдә чыгыш ясаган вакытларны хәтерләтә. Поэманы тыңлаган яралыларның җанланып, рухланып киткән йөзләрен кабат күргәндәй булам. Бу әсәрне башкарган саен үзем өчен ниндидер яңалык ачам мин...

— Һәм шул яңалыкны тамашачыларга да җиткерергә тырышасызмы?

— Билгеле. Шуңа күрә ул тыңлаучыны туйдырмый да. Белинский әйткәнчә, актер үзе башкара торган әсәр авторның колы булырга тиеш түгел. Ул үз уены белән автор идеалын тулыландыра. Автор иҗатын әнә шушы тулыландыру белән бизи дә.

— Сез репертуарыгызга сатира-юмор әсәрләрен бик теләп аласыз. Тамашачы күңелен күтәрү үзеңә дә җан рәхәте бирәдер ул?

— Әлбәттә шулай, әмма көлдерү — үзмаксат түгел, ә бәлки кеше күңелен кытыклап, аңа яшәешнең мөһим фикерләрен җиңелрәк итеп җиткерү чарасы ул. Кайвакыт тамашачының кирәкмәгән урында көлеп утыруына борчылган чаклар да була. Мәсәлән, хәтерлисездер, Һади Такташның «Киләчәккә хатлар» поэмасында Мохтар карт турында мондый юллар бар:

Ул авылда тырышып колхоз төзегән,
Оештырган ярлы, ялчыны.

Шул эш өчен аны кочагыннан
Мәхрүм иткән сөйгән карчыгы.

«Бар колхозың белән йокла,— дигән,
Җылы кусныи карчык ачмаган...

Кайбер нәфис сүз осталары тамашачыны көлдерү өчен шушы строфаның соңгы юлларына басым ясыйлар. Ә биредә баштагы ике юлдагы фикер бик мөһим. Биредә сүз күмәк хуҗалыклар төзү, яңа тормыш формалашу турында бара. Сыйнфый аңның үсүе крестьян психологиясендәге үзгәрешләр турында бара. Һәм шуңа басым ясап сөйләргә дә кирәк.

— Осталык турында сөйләгәндә шуны дә әйтсәгез иде, Әзәл ага. Нәфис сүз остасы, Сезнеңчә, нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?

— Безнең эш шундый четерекле инде. Сәхнәдә берүзең, ярдәмчеләр юк. Шул хәлендә тамашачының игътибарын бик тиз яулап алырга, аның ихтыяры белән идарә итә белергә кирәк. Нәфис сүз остасы сәхнәгә чыгу белән үзен залның хуҗасы итеп тоярга һәм, әлбәттә, үзең сөйләгәннәрне җисми итеп күрү зарур. Муса Җәлилнең «Күршеләр» шигырен сөйләгәндә теге, кәбестә кимереп йөрүче мут кәҗәне мин шундый итеп карыйм ки, алгы рәттәге тамашачыларның башы ирексездән шул якка таба борыла.

Көтелмәгән төрле хәлләрдән югалып калмау, шул очрактан оста чыга белү — эстрада артисты өчен шулай ук бик кирәкле сыйфат.

— Шундый хәлләргә юлыккан чаклар да булдымы?

— Булды, әлбәттә. Узган концертларның берсендә бер егет «шайтан суы» кабып килгән. Шул, ат дагалаганда бака ботын кыстыргандай, кычкырынып утыра бит. Мин, концерт программасында булмаса да, салмышларга бик ачы әйтелгән «Ачуланма, эпсм!» дигән шигырьне сөйләп җибәрдем. Илдар Юзеевның шушы шигырен укып бетергәч, малаем башына суккандай шым булды. Зал шаулатып кул чапты. Сәхнәнең бик шәп тәрбия чарасы булуы кайвакыт әнә шулай минуты белән күренә...

— Әзәл ага, Сез юлларда күп йөри торган кеше. Артистлык тормышында мондый көтелмәгән хәлләр шактый очрыйдыр...

— Очрамыймы соң?! Мин аларның кайберләре турында үземнең «Артист язмалары»нда искә ала киләм. Мәсәлән, сугыш вакытында шефлык концертлары куеп йөргәндә шундый бер хикмәт булды. Концертка барганда, баянны күтәреп килүче иптәш аягы таеп егылды. Концерт башлан-

гач, әлеге баянны алып, Рокыя Ибраһимова сәхнәгә чыкты. Ул Салих Сәйдәшевнең «Совет Армиясе маршы»н уйнарга тиеш иде. Ләкин баяннан марш урынына һава гына пышылдап чыкты. Җиргә бәрелү сәбәпле баянның телләре коелып беткән икән. Сәхнәгә чыкканчы шуны карарга вакыт та булмады. Мин, хәлне төзәтү өчен, сәхнә артыннан үземнең венский гармунымны суздым. Рокыя уйный башлаган иде, гөнаһ шомлыгына каршы, гармунның бер теле батып кычкыра башлады бит. Аптырагач, үзем Рокыя янына басып, гармунның «түбәсенә» йодрык белән төя тордым, ул уйный торды. Шулай итеп, кактык-суктык, барыбер ерып чыктык!

— Нәфис сүз аксакалы буларак, язучылар иҗатында нинди әсәрләр күрергә теләр идегез?

— Тамашачы яратып тыңларлык, тирән эчтәлекле, югары сәнгать дәрәҗәсендәге, юморга бай әсәрләр күбрәк булсын иде. «Кыңгыраулы яшел гармун», «Хат ташучы» шикелле әсәрләр. Бүгенге үзгәртеп корулар, хәбәрдарлык заманы иҗат кешеләре өчен тагын да киң мөмкинлекләр ачты. Әмма әлегә бу мөмкинлекләр искене, үткәнне сүгүгәрәк кайтып кала шикелле. Үзгәртеп кору юлындагы бүгенге каршылыкларны, кимчелек-хаталарны ачып салу җитми. Шундый әсәрләр язылса, без, нәфис сүз осталары, аларны пропагандаларга, халыкка җиткерергә һәрвакыт әзер. Шулай бергәләшеп иҗат иткәндә генә, сүзнең илаһи көченнән тулы файдаланып, Шекспир әйткәнчә, үз заманыбызның көзгесе, елъязмачысы була алырбыз.

Шамил Маннапов

СӘХНӘ БАСКЫЧЛАРЫНДА

Манарасы бәреп төшерелгән мәчеттә һинд фильмы бара. Мәчет каршындагы кайчандыр изге җаннар кулы белән утыртылган тармаклы тупыллар арасына чыпчык көтүедәй булып бала-чага кунаклаган. «Балаларга карарга ярамый» дигәч, таралмыйни инде алар?!. Башка вакытта да еш кына билет бәясен алыштырырга ярдәм иткән бу тупыл ботаклары бу көнне дә «тамашачы»лар белән тулы иде. Олы юл буендагы клубның тәрәзәләре тузанлы булса да, безнең өчен ярый иде инде ул. Ул елларда һинд халкы-

ның җырга-моңга, дәртле биюләргә бай фильмнары сирәк күрсәтелә иде әле. Пәрдәгә бу күренеш шәүләсе төшү белән чәчләрен агач ботаклары тузгытып бетергән чегән кызыдай берәү үзенең җайлы урыныннан сикереп төште дә тәрәзәгә капланды. Без барыбыз да: «Қаплама, кем ул, Әнсәрия, син икән, кит аннан»,— дип кычкырышырга тотындык. Ул арада эрерәк малайлар дөп-дөп җиргә сикереп Әнсәрияне йолкый ук башладылар.

*
* *

Икенче көнне авылыбызның ике урамы уртасыннан агып уза торган инешнең зирәкле тегермән буасы артындагы аланчыкта Әнсәриябез шыңшый-шыңшый кичәге фильмда күргән кыз кебек боргаланып биеп ята иде. Без, кызлар, шушы аланлыкта гел куаклар арасына шәльяулыклар элеп өй ясап, кунак-кунак чакырыш уйный идек. Әнсәрияне өйдә очратмагач, мин тагын монда килдем. Тавышын әллә кайдан танысам да бик мавыгып биергә өйрәнүен күреп, оялып китәр дә орышып ташлар, дип, агачлар артыннан гына күзәтә башладым. Минем күңелемдә бу күренеш кичәге кинодан һич тә аерылгысыз булып тоелды. Безнең тегермән авыл башында, кара урман куенына ук кереп урнашкан. Аларны шомыртлык кына аерып тора. Урманда сайраган кошлар тавышы белән тегермән улагыннан аккан су шавы бер дә һинд тауларындагы шарлавыклардан ким түгел. Җитмәсә, яланаяклы каракайның аларга охшатып моңлануы хисләрне ерак Һиндстанга алып китте. Ә Әнсәриянең үзен олы юлга, ерак сәхнәләргә хәзерли башлаган.

Энҗедәй вак кына ап-ак тешләрен җемелдәтеп, өстенә ак күлмәк кигән бу кыз манарасы алып ташланган мәчет сәхнәсендә бәйрәм саен күренә башлады. Үсеп буйга житсә дә ак күлмәге тузмады, керләнмәде аның, зифа буена килешә генә барды. Җәйнең сихри кичләрендә елга буена җыелган яшьләр түгәрәгенә, сабан туеның җыр-бию ярышларына бик күп ямь өстәде аның дөньясын онытып биюләре. Алай гына да түгел, безнең кебек үсмер җилбәзәкләрне дә үзенә тартты Әнсәрия. Теләгең генә булсын, теләсә кайда вакыт табып биергә өйрәтергә ярата иде ул безне. Ә үзе үзешчәннәр чыгышында күрәме, профессиональ артистлар биимеме — һәр хәрәкәтне бөтен нечкәлекләре белән отып ала. Алдагы концертка кадәр авыл яшь-

ләренә өйрәтеп, аны сәхнәгә чыгара. Авыл халкының элеккедән килгән җырлы-биюле уенлыкларында да ул башлап йөри. Әнсәрия биемәгән кичләрне хәтерләмим мин.

*

* *

Тормыш агымы Әнсәрияне Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә ияртеп китерде. Кеше күзенә бик җиңел генә тоелган бу хезмәтнең гаять авыр эпизодлары белән көн дә очраша башлады ул. Ансамбльнең яшь биючеләре күбесе шәһәр мәктәпләреннән килгәннәр. Алар анда ук инде түгәрәкләргә йөреп хореографик күнегүләрне үзләштереп өлгергәннәр. Балетмейстер Әхмәт Кәлимуллин абыйлары: «I позициягә басыгыз»,— дип команда биргүгә аяк-кулларын тиешле формага куеп басалар яки: «Фондию — фондию», «Зур Бадман»ны кабатларга»,— диюгә, шушы хәрәкәтләрне ясарга тотыналар. Ә Әнсәрия бу терминнарны башта бөтенләй аңламый җәфаланды. Балетмейстерның аның аркасында еш кына кәсфе китеп:

— Сиңа, сеңлем, фермада сыер савучы булып кына эшләсәң яхшырак булыр иде,— дип кул селтәгән чаклары аз булмады.

*

* *

Өйдә иң беренче Зәйтүнә апа уяна. Кече яктагы сукыр лампаны гына кабыза да тиз-тиз киенеп фермага эшкә китә. Аның салкында карлы сукмакны шыгырдатып киткәне әкренләп югала. Гөлчирәттәйгә дә сызланган буыннарын урын өстендә озак язып ятарга туры килми. Олы кызы фермадан иртәнге эшен бетереп кайтуга өйне җылытып, ашарга әзерләп куярга кирәк. Иртәнге салкын авыл өенә ниндидер серле җанлылык бөркеп, каен тузына чытыр-чытыр ут эленә, мич эчен кызу ут чолгап ала. Әнсәрия шуны гына көтеп яткан икән. Сикереп торып, урын-җирен тирә-якка эткәләп куя да мич каршындагы сәкедә кичә апасы белән концертка баргач кызыгып карап утырган Сания, Мәрьям апаларына охшатырга тырышып биергә тотына. Ишегалды, мал-туар арасындагы эшен бетереп кергән әнисенең «Әй ходай орган бала, таң тишегеннән торып өйдәге фәрештәләрне качырырга тотынмасаң, тукта дим» дигән сүзләренә дә игътибар итми. Мичтәге утыннар янып бетеп

тәмам сүрелгәнче тәрәзәдәге үз шәүләсенә карап боргалануын белә...

5—6 яшьлек чагындагы бу күренешләрне Әнсәрия иң матур хатирәләренең берсе итеп саклый.

*

* *

Әнсәриянең биюче кызлардан калышасы килми. Репетиция залында берүзе калып, көн буе өйрәнгәннәрен аякларының җегәре беткәнче яңадан кабатлый. Икенче көнне иртән арыган мускулларын уа-уа көчкә торып баса. Тагын да катлаулырак хәрәкәтләр, катлаулырак күнегүләр башлана.

Татарстанның атказанган биючеләре Фәйтүнә Абдуллина, Нәҗия һәм Мансур Гатиятуллиннар авылдан килсә дә бу кыздагы сәхнә өчен кирәкле гүзәл сыйфатларны, ихтыяр көченең нык булуын тоеп, аңа ярдәм итәләр. Кечкенә генә булса да уңышларын күреп, рухландырып җибәрәләр. «Яшьләр биюе», «Ак бүрек» күмәк биюләрендә Әнсәрия сәхнәгә дә чыга. Ләкин әле болар гына аның өчен иң югары чик түгел. Алда яңадан-яңа катлаулы, авыр репетицияләр. Аннан арып кайткач әнисен, апасын өзелеп сагынып елау дисеңме... Әнә шулай берсен-берсе катлауландырудан туган уйларына буйсынып Әнсәриядә туган ягына кайту теләге уяна. Авыл сәхнәсендә биерлек кенә сәләте бар ич, көндезләрен эшләп, кичләрен клубта уздырырга була. Аннан соң өйләреннән һаман сагынып, авыл халкының кызлары турында «эшләмичә биеп йөри» дип сөйләүләреннән куркып, апасы белән әнисе чакырып хат язалар.

*

* *

Бер елда җыйган шәһәрчә киемнәрен тутырган чемоданын күтәреп Әнсәрия Әгерҗе вокзалына кайтып төште. Ямурзага кайтырга машина көтеп йөргәндә күзенә биючеләр, җырчылар сурәте төшерелгән белдерү чагылып китте. Башта әһәмият бирергә тырышмаса да, машина көтә-көтә шунын каршына барып басты. Ижевскидагы дәүләт җыр һәм бию ансамбленә чакыралар икән. Әллә барып карарргамы? Монысы авылга да якын, бик сагынсаң кайтып килергә була.

Әнсәрия тагын биючеләр арасында. Биредә балетмей-

стер Анатолий Бондарев аны өйрәнчекләр группасына ала һәм, алар арасында иң сәләтлесе икәнен күреп, Әнсәрия белән өстәмә занятиеләр уздыра башлый. Үзенә аерым игътибарны тойгач, биюченең күңеле көннән-көн күтәрелә, әлбәттә. Бүлмәсенә кайткач, элеккеге кебек сагынып, уңышсызлыкларына хурланып ачы күз яше белән кроватена капланмый. Көзге каршында үз-үзенә сокланып күнегүләр кабатлавын дәвам итә.

Концертларда башлап биюче булып китә.

1962 ел. Удмурт дәүләт җыр һәм бию ансамбле Мәскәүдә Кремльнең Зур сараенда концрет бирә. Ничә ел буе бөтен ихтыяр көчен туплап туктаусыз шөгыльләнүнең беренче ләззәтен, беренче уңышларын шунда татый Әнсәрия.

*
* *

1966 елда Ижевскига РСФСРның атказанган культура работнигы Князева Ольга Никелаевна җитәкчелегендә Урал халык хоры килә. Бу ике сәнгать коллективы концертлардан соң үзара тәҗрибә уртаклашалар. Бер-берсенә киңәшләр бирәләр. Ольга Николаевна шунда бер дә икеләнмичә Әнсәриягә карап:

— Менә бу кызның дәртле биюе миңа аеруча ошый. Темпераментлылыгы белән ул безнең биюләрне хәтерләтә. Әллә безгә бирәсезме бу кызыгызны? — дип куя.

*
* *

Җиләк пешкән чак иде. Әнисе белән апасына шәһәр күчтәнәчләре төяп туган авылына кунакка кайтты Әнсәрия. Сагынышканнар, сөйләшер сүзләре күбәйгән бу гаиләнең. Кызының тагын да сылулана, акыллылана төшүен күреп куана Гөлчирәттәй. Алай да аның күңелен бер нәрсә борчый. Әнсәрия дуслары, туганнары белән күрешеп кайтырга җыенгач түзмәде ана, кыенсынып кына әйтеп куйды.

— Кызым, кешегә биеп йөргәнеңне әйтә күрмә, забутта эшлим, диген. Югыйсә апаң белән без сораганнарга шулай дидек. Гөлчирәнең кызы һаман чикерткә кебек сикергәләп, эшсез яши икән әле, диярләр.

Әллә ничек булып китте Әнсәриягә. Ник авыл халкы өчен шулхәтле кыргый күренә икән бу артистлар хезмәте.

Үзләре аларның концерт-театрларын ничек күтәп алалар, яратып карыйлар. Сәхнәгә чыкканчы күпме тырышлык, түземлелек таләп иткәнен генә аңламыйлар. Юк, алдарга җыенмый Әнсәрия. Авыл халкының культура дәрәҗәсе бүген булмас иртәгә аны гына аңларлык булыр.

*
* *

Урал халык хоры Әнсәриянең иҗади эшчәнлегеп истәлекле вакыйгаларга баетты. Ул бу коллективта беренче мәртәбә чит илгә гастрольгә чыкты. Чехословакиянең Прага һәм тагын 16 шәһәре, Италиянең Рим, Венеция һәм башка шәһәрләре сәхнәләрендә биеде.

Мәскәүнең Чайковский залында концерт биргәннән соң илебезнең культура министры белән очрашу булды. Анда министр үзе Әнсәрия Кретовага СССР Культура министрлыгының Мактау граматасын тапшырды. Әиң дә әһәмиятлесе — Әнсәрия белән Николай Кретовлар бу коллективта матур тормыш корып җибәрделәр.

*
* *

1970 елда Татарстанның халык артисты Гай Таһиров ансамбль белән Свердловскига килә. Коллегалары белән очрашкач, ул Әнсәрияне танып ала. Аның иҗат уңышлары турында да ишетә. Бу республикабызның ярты гасырлык юбилеена хәзерлек барган чор була. Әлбәттә, халкыбыз культура өлкәсендәге үсешләрне яктырту буенча сәнгать коллективларына зур бурычлар йөкләнә. Бу күтәрелештә татарларга башка милләт халыкларының йогынтысы да әһәмиятле роль уйнаган. Шуңа күрә Гай Таһиров концерт репертуарына милләтләр дуслыгын чагылдырган күмәк бию кертә. Ә ник андагы рус кызы белән егете урынына ул биюләр эчендә кайнаган артистлар башкарса, начар булырмы? Шундый ният белән Гай Хаҗиевич Кретовларны Казанга чакыра.

*
* *

Данлы юбилейга багышланган концретны Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең биючеләр коллективы төрле милләт халыкларының берләшкән биюе белән тәмамлый.

Бизәкле зәңгәр сарафан кигән, башына күбәләк кебек ак бант куйган рус кызының төгәллек белән өзек-өзек тыпырдатып, дәртле җитез хәрәкәтле биюе һәркемне сокландырды.

Артистканың көчен, сәләтен казанлылар югары бәяләделәр. «Яшьләр биюе», «Аулак өйдә», «Шаяру» һәм башка татар халкының шаян, күмәк биюләрендә Әнсәрия башлап биючеләр рәтенә күтәрелде.

*
* *

— Иҗади хезмәт юлында икенче сынауны да үтәргә туры килә. Юлия белән өйдә утырганнан килеп туды ул. Күпме генә үз-үзең өстендә эшләргә тырышсаң да өйдә торганда гәүдә нәфислеген саклавы авыр икән. Эшкә чыгарга 2 ай вакыт калды, ә мин һаман ябыга алмыйм. Тәүлекнең 7—8 сәгатен тоташ катлаулы күнегүләр, сикерү, йөгерүләр белән үткәрә башладым. Бу шулхәтле зур көч, егәрлек таләп итә. Арыйм. Атна-ун көн көчкә түздем. Үлчәнәм, авырлыкны шактый киметкәнмен. Рухланып куйдым. Тагын шулай. Үҗәтләнеп шөгыльләнергә тотындым. Эшкә чыкканда инде сәхнәгә чыгып биер хәлгә килгән идем,— ди ул.

*
* *

Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле 1977 елның җәендә Туниста үткәрелгән фольклор фестивалендә катнашты. Анда коллектив яулаган уңышлар белән горурланып Әнсәрия болай ди:

— Борынгы Карфаген амфитеатрында ике елга бер мәртәбә уздырыла торган төрле илләрнең халык сәнгатен күрсәтүгә багышланган бу фестивальгә 30 дан артык илдән сәнгать коллективлары катнаштылар. Безнең чыгышларны да Тунис халкы көчле алкышлар белән бәяләде.

Фестивальдә катнашучылар арасыннан бары безнең коллективка тагын 10 шәһәрдә концерт бирергә тәкъдим ясадылар. Ул безгә программабызны киңәйтеп үзебезнең татар сәнгате аша халкыбызның азат илдә яшәү бәхетен бөтен тулылыгы белән ачып бирергә ярдәм итте.

*
* *

Аннан соң Әнсәрия Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артистлары концертларында биеде. Бу биючедә аеруча зур осталык таләп итә иде. Чөнки ул сәхнәдә үзе генә. Рус, татар, башкорт халыклары биюләрендәге үзенчәлекле якларны тамашачы күңеленә җиткерә белергә кирәк.

*
* *

Әнсәриянең сәхнәләрдә биеп туктаганына инде ун ел. Бу чорда ул Химиклар культура сараенда «Яшьлек» ансамбле өчен ничәмә-ничә буын балаларны биергә өйрәтте. Алар арасында Кретовларның үз кызлары Юлия дә бар. Ул, әнисе мәктәбен үтеп, хәзер әтисе Николай Кретов группасында. Менә шулай Әнсәрия Николайга алмаш әзерләп тора. Әйтүе генә җиңел бу турыда. Ә бит алар һәр бала, аннан соң һәр егет, һәр кыз өчен җаваплы.

Сәләтле балаларны, кызларны-егетләрне ансамбльгә йөртү өчен башта Кретовлар аларның әти-әниләрен үгетлиләр. Чөнки аларның биеп йөрүчеләргә ышанычы булмый, ә инде соңыннан балаларын (бигрәк тә улларын) юлдан язудан саклап калганнары өчен үзләре үк Әнсәрия белән Николайга рәхмәт әйтеп бетерә алмыйлар. Ә бит моңа ирешү өчен «Яшьлек» ансамбле җитәкчеләренә күпме тырышлык, сабырлык, күпме ихтыяр көче таләп итеҗә!

Бу ансамбльнең чыгышларын Казанда гына түгел, республикабызның башка төбәкләрендә дә бик яратып карыйлар. Аның репертуары халкыбызның ерак үткәне белән бүгенгесен тоташтыручы биюләрдән тора. Заман рухына яраклаштырып биюләр кую өчен, Кретовлар башта айлар буена уйлап йөргән сюжетларын берләштерәләр, аннан репетиция залында икәүләп 2—3 әр сәгать шуны биеп карыйлар. Шуннан соң гына яшьләргә өйрәтә башлыйлар.

Эшче-биючеләрнең ял вакытларын күңелле итеп оештыру өчен, Кретовлар һәр елны диярлек коллективны илебезнең тарихи истәлекләргә бай булган шәһәрләренә, Идел буйлап сәяхәтләргә алып чыгалар. Шуңа күрә дә яшьләр, күнозын эштә булуларына карамастан ансамбльгә бик те-

...н йөрилэр. Энсэрия Сэлаховна белэн Николай Григорьевич алар өчен тату гаилэ үрнэге, акыллы киңэшче, хезмэтлэре төшкэндэ иң ышанычлы ярдэмче булып эверелэлэр.

Язилэ Абдулкадыйрова

КЕШЕ СЫНЛЫ ӨЕРМЭ

Эмирхан Еники эйткэнчэ, кайбер исемнэрдэ ирексездэн игътибарны үзенэ тарта торган ниндидер бер тылсымлы көч бар. Моның сере, элбэттэ, исемнең үзендэ түгел, э иясендэ. Бу хакыйкать планетабызның мэшһүр биючесе СССРның халык артисты, Социалистик Хезмэт Герое Мэхмүд Эсамбаевка бигрэк тэ туры килэ.

Мэхмүд Эсамбаев — тере легенда. Нинди генэ сүзлэр йөрми Җир шарында аның турында. «Бию короле», «Хореография шагыйре», «Сөяксез, каучук кеше», «Пластика тылсымчысы», «Мимика философы», «Грациягэ тере һэйкэл»... Күренэ ки, чагыштырулар төгэл һэм образлы. Аның турында бэхэслэшэлэр дэ: иҗатын нинди төргэ һэм жанрга кертергэ? Сораулар күп, бэлки бу милли бию сэнгатедер, яисэ классика белэн бергэ үрелгэн халык биюедер, һич булмаса, эстрада хореографиясе өлгеседер? Юк, бирелдэ бертөрле генэ билгелэмэ бирeп котылып булмый, чөнки Мэхмүд Эсамбаевның таланты да, иҗаты да үтэ үзенчэлекле, уникаль күренеш. Ул биеп кенэ калмый, э пластика теле белэн тормыш турында, безнең иксез-чиксез планетабыз кешелэре турында образлы итеп сөйли. Эсамбаев биюдэ кискен сюжет вариациялэрен сайлый, аларны үз манерасында башкара, нэтиҗэдэ образлылык һэм төгэллек белэн һэр биюне новеллага, поэмага, хэтта эпоска, спектакль-монологка эйлэндерэ. Бу инде без кararга гадэтлэнгэн бию түгел. Эйтик, Һиндстан, Испания, Бразилия... халкы мэшһүр биючене үз милли биюлэрен иң оста башкаручы дип таныды. Бразилиядэ милли бэйрэмдэ ул иң оста йоглар белэн бергэ «Макумба» биюен уникe сэгать рэттэн башкара.

Чечен-Ингуш АССРның башкаласы Грозный шэһэрендэ крайны өйрэнү музеенда бер зур бүлек бар. Анда мэшһүр бию тылсымчысына бик күп миллэт халыкларының төрле иллэрдэ, тугандаш республикаларда бүлэк ителгэн бию

костюмнары саклана. Ике йөзгә якын алар. «Планетаның кеше сынлы өермәсе» үз вакытында шуларны киеп биеп йөргән.

Мин Мәхмүд Алисолтанович белән аның туган төбәге Грозныйда, якташлары һәм авылдашлары янында, шулай ук Мәскәүдәге квартирасында һәм илебезнең күп кенә шәһәрләрендәге гастрольләре вакытында очрашып сөйләшү бәхетенә ирештем.

— Мәхмүд Алисолтанович, нигәдер афишаларда да, концерт барышында да Сезнең титулларыгыз телгә алынмый.

— Әңгәмәне кисәтү ясаудан башларга туры килә инде. Миңа «Сез» дип мөрәҗәгать итмә. Бу галәмдә бүтән Мәхмүд Эсамбаев юк, мин — берәү. «Сез»дән ниндидер минминлек, ясалмалылык сизелә кебек. «Син» күңелгә дә якын, телгә дә ятышлы, дуслык һәм туганлык белән сугарылган. Мактаулы исемнәргә килгәндә инде, чынлап та миңа РСФСРның, Кыргызстан ССРның, Чечен-Ингуш, Төньяк Осетия, Кабардин-Балкар, Дагстан АССРларының халык артисты исемнәре бирелде. Берничә тапкыр Бөтендөнья һәм Бөтенсоюз конкурслары лауреаты булдым. Болары җыелышларда телгә алынганда гына күңелле. Берәр эшченең орден-медальләрен тагып, титулларын кабатлый-кабатлый станок артына басканын күргәнең бармы?! Биегәндә мин дә шундый эшче бит. Сәхнәдә мактаулы исемнәр түгел, ә Мәхмүд Эсамбаев бии. Эш, минемчә, нинди титуллар йөртүдә түгелдер, ә нәрсә эшләүдә һәм ничек эшләүдә.

— Кавказ халыклары биюне ярата инде ул. Сезнең авыл халкы гына читтә калмагандыр.

— Мин Чечен-Ингушетиянең Иске Атаги авылында туганмын. Гомеремдә беренче тапкыр ишеткән аһәң әнием тавышы белән ярсулы Аргун елгасы гөжләве булды. Безнең авыл Аргунның тау ташларыннан сикерә-сикерә йөгереп төшеп, үзәнлеккә җәелгән урынына утырган.

Инде Кавказ халкының сәнгатьне яратуына килгәндә, чынлап та, безнең авылның бер очында берәү кулын чапылдата, икенче очында инде кемнәрдер бии башлый.

— Артист булу теләге синдә кайчан туды?

— Анысын төгәл генә әйтә алмыйм. Мөгаен, ул теләк минем белән бергә дөньяга килгәндер. Ләкин «артистлана» башлавым хәтердә. Бәләкәй чакта мине сарык көтәргә җибәрәләр иде. Мин сарыкларны бии-бии саный башладым. Соңрак «Кечкенә көтүче биюе» шул хатирәләрдән тугандыр.

Миңа сигез яшь тулгач, безнең гаилә Грозный шәһәренә

...үчте. Анда иске базарда мин су сата башладым. «Кемгә су кирәк? Тәмле су? Боз белән!» Бер карт яныма килде дә боын күрсәтергә кушты. Мин югалып калмадым: «Бозы әле генә эреп бетте»,— дидем. Карт, миңа карап серле генә елмайды да, кояшта җылынган суны бик тәмләп эчте. Мин аны ышандыра алуыма шат идем. Сәнгать әсәре дә ышандыру көченә ия булырга тиеш, бу — төп шарт.

— Әти-әниең дә бии идеме?

— Бездә бии белмәүчегә: «Башкалар биегәндә чыккан тузанны эчеп утыручы»,— дип әйтәләр. Ә сөйгән кызыңның, атыңның башка кеше белән биюен гарьлек дип исәпләләр. Бәйрәмнәрдә туй вакытында әти дә, әни дә бииләр иде. Тик биюне һөнәр итеп сайлаучылар бик аз. Мин әтидән кача-поса гына үзешчән хореография студиясенә йөри башладым. Анда миңа «балерина» кушаматы тактылар. Әти моны сизеп алган да студиягә килгән. Минем җитәкче Мария Стефановна Форманчук аның тиргәвенә ничек түзгәндер, белмим. Кич белән әти мине урыннан кузгала алмаслык итеп кыйнап ыргытты.

— Әтиең шулай иске карашлы кеше идемени?

— Әти озак еллар авыл Советы председателе булып эшләде, беренче колхозларны оештырды. Монда эш башкачарак. Әти: «Ишхоевлар нәселендә беркайчан да клоуннар булмады һәм булмаячак та!» — ди иде. Ул минем судья, прокурор, һич югында врач булуымны теләде. Шуңа күрә минем биюче булуыма каршы төште.

— Берзаман врачлар сиңа биюне ташларга кушканнар дип сөйлиләр, шул дөресме?

— Дөрес. Бөек Ватан сугышы елларында безнең ансамбль сугышчыларга 360 концерт бирде. Алгы сызыкта чыгыш ясаганда, минем аякка снаряд кыйпылчыгы эләкте. Бик озак больницада яттым. Атлап та йөрep булмый иде. Врачлар бию турында мәңгегә онытырга куштылар. Ә мин әне-төне күнегүләр ясадым, үземне дә, аякны да «җиңдем». Һәм Кыргызстан дәүләт опера һәм балет театрында ...п партияне башкару бәхетенә ирештем.

— Мәскәү дәүләт университетының концерт залындагы чыгышыгыз вакытында миңа: «Эсамбаев — биюләр Шаляпины! Аның биюләрендәге хәрәкәтләрдә музыка яңгырый», — дигән сүзләрне ишетергә туры килде.

— Хәрәкәтләр аша уй-фикерләремне тамашачыга җиткерү — сәнгатьтәге төп максатым. Башта мин биюләргә тәби текст язам, ә биегәндә һәр сүзне, уй-фикеремне хәрәкәт аша чагылдырырга тырышам. Моңа ирешәм икән, тамашачы минем ни әйтергә теләвемне яхшы аңлый.

— Ә шулай да биюләр ничек иҗат ителә?

— Мин башкарган һәм иҗат иткән биюләрнең чыганагы өчәү. Беренчесе — халык биюләре. Икенчесе — чит илләрдә гастрольдә булган чакта миңа бүләк ителгән биюләр. Өченчесе — шул гастрольләр вакытындагы тәэсирләр нигезендә туган биюләр.

Шунысы ачык: әгәр дә син шушы биюне тудыручы халыкның күз яше белән еламасаң, синең бернәрсәң дә килеп чыкмаячак.

— Синең репертуардагы ике бию — һинд халкының «Алтын алла»сы һәм Бразилиянең «Макумба»сы гомерлек бугай.

— Мин шушы катлаулы ике биюне сәхнәдә чакта һәрвакыт башкарачакмын. Аның сере шунда: һинд биюендә буш хәрәкәтләр бөтенләй юк, аларның һәрберсе нәрсәнедер аңлата, нәрсә хакындадыр хикәяли, тик аны «укый» белергә һәм аңларга гына кирәк. Әйтик, кул хәрәкәтләре генә 700 дән артык мәгънәгә ия. «Алтын алла»да аякларга киелгән кыңгыраулар бронза белән көмештән эшләнгән, шуңа алар моңлы һәм матур яңгырый. Ләкин «Алтын алла»да Кояшның чыгуын бию башында биш минут буена аяк очында күтәрелеп күрсәтү һәм азактан кояш баюын биш минут буена чүгеп күрсәткәндә бер генә кыңгырау да селкенергә тиеш түгел.

— Мәхмүд Алисолтанович, Херсон шәһәрендәге концертларыңның берсендә культура-агарту училищесының телсез студенты синең биюне карап дулкынланудан телгә килгән дип сөйлиләр. Чынмы бу?

— Әйе, булды андый хәл. Концерт барышында берәү нидер кычкырып җибәрде һәм һушыннан язды. Сәхнә артында аңына килгәч, егет, әкрен генә: «Мәхмүд ага, мин сөйләшәм бит»,— диде. Миндә бер фото саклана. Анда шундый сүзләр язылган: «Тылсымлы савыктыручыма. Анатолий Барыгин, «Веснянка» украин ансамбле биючесе». Хәзер Анатолий Нежин шәһәрендә яши, Украина ССРның атказанган сәнгать эшлеклесе. Хатлашып, очрашып торабыз.

— Мәхмүд Алисолтанович, биюләрегезне сәхнәгә берәрсе куямы, әллә...

— Юк, үзем. Башыннан азагына тиклем.

— Бер бию өстендә озак эшлисеңме?

— Бию минем башымда озак туа, күп вакыт шул хакта уйланып йөрим, халыкның тормышын, гореф-гадәтен, фольклорын, музыкасын өйрәнәм...— Ул бераз уйланып торды да өстәп куйды: — Ә беләсезме, биюнең һәм бию-

генең мөмкинлекләре искиткеч күп. Хәтта Анна Карениныны да биергә мөмкин.

— Репертуарыңда ничә бию бар?

— Әллә инде, бик күп алар, үземнең бер дә санаганым юк.

— Программаңны еш алыштырасыңмы?

— Юк. Чөнки халык — мәңгелек. Шулай булгач, халык биюләре дә беркайчан да искерми.

— Чит илләрдә еш чыгыш ясарга туры киләме?

— Бик күп илләрдә чыгыш ясадым. Булмаган илләрне санап чыгуы җиңелрәктер. Һәр илгә Советлар Союзының тулы хокуклы илчесе булып бару почетлы да, җаваплы да. Сәнгать иң оста илче — дипломат бит ул.

— Мәхмүд Алисолтанович, ә көндәлек гадәти репетицияләр озак дәвам итәме?

— Иртән. Хәлдән таеп урынга егылганчы. Концерт алдыннан — сәгать ярым.

— Башкарган биюләрдән кайсысы иң авыры?

— Минем җиңел биюләрем юк. Аларның һәрберсенә көчне тулысынча бирергә кирәк. Сәхнә артына манма су булып чыгам. Әгәр дә тамашачыга минем бию җиңел булып тоелса, димәк, мин үз бурычымны үтәгәнмен. Әгәр инде зал биюнең физик яктан авыр башкарылганын тойса, бу артистның формада түгеллеге турында сөйли.

— Артист формада булмаска да мөмкин ич.

— Әлбәттә. Ләкин бу очракта аның тамашачыга күренергә хакы юк. Артист хәтта авыру булырга мөмкин, ләкин моны тамашачы сизмәскә тиеш.

— Синең хезмәт кенәгәң 1939 елның 29 январенда ачылган. Гомернең ярты гасыры биеп уздырылган. Ә гадәттә профессиональ биючеләр 15 ел биегәч пенсиягә китә. Әйтегез, Мәхмүд Алисолтанович, кайчан әйбәтрәк бии идегез: хәзерме, әллә 25—30 яшьтәме?

— Хәзер бик күпкә яхшырак биим. Әле аңлап, тәмен белеп, йөрәктән кичереп, күңел хисләре белән биелә. Яшь чакта ризыкны йотасың гына, ә олыгайгач — чәйнәп ашыйсың. Хәзер тәҗрибә һәм мәгълүмат зур, тик үземне һаман яшьлек итеп тоям.

— Кулыңдагы бердәнбер алтын балдак та чит ил бүләге булса кирәк.

— Әйе. Мин ювелир бизәкләр яратмыйм, шулай да моны киеп йөрим. Аны миңа Колумбиядә «Бамбука»ны куйганнан соң бер оста ювелир бүләк итте. Анда Колумбиянең дәүләт гербы сурәтләнгән. 78 яшьлек бер карт элек дә «Бамбука»ны иң оста башкаручы булган икән.

— Хәтердә Рәсүл Гамзатовның әйткән сүзләре яңара: «Төньяк Кавказда бөтен дөньяга даны таралган артист Мәхмүд Эсамбаев бар. Ул чечен папахасыннан йөри һәм аны беркайчанда салмый...»

— Әһә, сизәм, сүз минем иң зур горурлыгым турында бара. Биредә сер минем пеләш булуда гына түгел. Папаха — безнең милли баш киеме. Аны кигәч, мин көзгедә тәмамланган образ күрәм.

Аргентинада бу папаха турында күп сүз йөрде. Имеш, ул меңәрләгән доллар тора. Бер миллионер малае аны гаражындагы теләсә кайсы җиңел автомобильгә алыштыруымны үтенеп теңкәмә тиде. «Папаха безнең илнең Кызыл кенәгәсенә кертелгән, ул дәүләт тарафыннан саклана»,— дип кенә котылдым.

— Берничә ел элек: «Йокыны юкка чыгарып булса иде. Йоклаганда мин үземнең вакытны урлыйм, шул вакыт кызганыч миңа,— дигән идең. Хәзер ничегрәк?

— Хәзер элеккегә караганда да кызганычрак. Еллар үтү белән ыграк эшләргә кирәклеген тоясың.

— Ә алтмыштан артык яшьтә дә егетләрчә җиңеллекне, буй-сынны саклауның сере нәрсәдә икән? Синдә ул иң гүзәл кызлар да көнләшерлек ич.

— Сере бер: төгәл режим саклау! Һәр өлкәдә дә. Бар бокал шампанскоеның зур бәйрәмнәрдә генә күтәрәм. Артык күп ашамыйм. Минем көнлек азыгым — бер стакан шулпа белән бер сыңык икмәк. Моннан берничә ел элек Парижда гастрольләрем вакытында француз газеталары: «Борынгы француз грациясен саклаганы өчен бу совет артистына рәхмәт! Буе — 180, биле 47 сантиметр!..» дип язган иде. Аз йоклыйм, күп хәрәкәт итәм. Әгәр формамны югалтсам, минем сәнгатем юкка чыгачак.

Кеше сыны чынбарлыкта гүзәл ул. Без аны үзебез бозабыз. Матурлыкны һава, кояш нурлары, су һәм хәрәкәт иҗат итә бит. Ә артист һәрчак матур булырга тиеш.

Ә минем яшем тау халыклары өчен җитлегү һәм чәчәк ату чоры гына ул. Кыскасы, егет чак!

Миннән өлкәнрәк Сарлен Дитрих, Жозефина Бэкер, Аркадий Райкинга карап соклана идем. Алар һәрчак яшь, энергияле һәм төз гәүдәле. Хәрәкәтсез, эшсез тору — художник өчен иң куркыныч. Ә һәркем үз эшендә художник була ала.

— Ә буш вакытыңны нәрсәгә багышлыйсың?

— Мин елына бер ай гына өйдә булам. Калган вакыт гастрольдә үтә. Дусларым күп, алар белән очрашып, әңгәмә тергезергә яратам. Югары белемем булмаса да, алар

елән кибернетика, геология, космик эзләнүләр турында сөйләшә алам. Белмәгәнемне сорыйм. Китап укырга ярамым. Бигрәк тә төнлә. Безнең бай һәм зур шәхси китапханәбез бар. Мемуарлар, «Танылган кешеләр тормышы» сериясен, энциклопедияләр, борынгы китапларны укырга ик яратам.

Дюмага гашыйкмын. Толстой, Бальзак, Мопассан, Стендаль, Жорж Санд, Джек Лондон, Шолохов, Фадеев, Горький... Толстойда бөтен дөреслек. Чехов, Драйзер..

— Ә хәзерге язучылардан?

— Аларның күбесе минем якын дусларым, киңәшчеләрем. Айтматов, Гамзатов, Кулиев, Мостай Кәрим, Нодар Думбадзе...

— Ә спортка мөнәсәбәт?

— Спорттан башка яшәүне күз алдына китермим. Гимнастика, акробатика, хоккей, су чаңгысы — мин табынган спорт төрләре шулар.

— Гаиләң турында берничә сүз әйтсәң иде.

— Тормыш иптәшем Нина — врач. Кызыбыз Стелла нисе юлыннан китте — нейрохирург. Оныкларыбыз бар. ерсе — Мәдинә — биюче булмакчы.

Иске Атагида безнең сакля урынына кардәш энем Абулхәмит йорт корган. Ә күрше авылда бертуган апам ада яши. Авылга яшьләргә киңәш бирергә, аксакаллардан иңәш алырга кайтам. 1957 нче елдан бирле якташлар ечен-Ингушстия Верховный Советына депутат итеп сайыйлар, аннары 12 ел РСФСР Верховный Советы депутаты, улдым.

— Остазның гадәттә укучылары да була. Син үз һөнәренең серләренә күпләрне төшендердеңме?

— Моңа кадәр туктаусыз даими шөгыльләнергә вакыт улмады. Һәрчак гастрольләрдә бит. Биергә һәркемне өйрәтергә була: маймылны да, бегемотны да. Ләкин биюне ңлый белергә бөтен кешене дә өйрәтеп булмый. Ул кешең үзендә, күңеленә салынган була. Минем оныгым бар. Ілактанып әйтмим: ул, бәләкәй булса да, биюне аңлый. «Мин картәтием кебек биюче булачакмын»,— ди. Мин ның өчен укытучы да. Үзем исә күп күренекле кешеләрдән осталыкка өйрәндем. Минем дә укучыларым булса, үземне өхетле санар идем.

— Мәгънәсезрәк сорау: биюдән кайчан туктарга исәп, Мәхмүд Алисолтанович?

— Көч-гайрәт барында биергә иде әле. Профессиональ әхнәдә сиксән яшькә кадәр. Ә биюдән тау халкы дөнья өлән хушлашкач кына туктый. Дөресрәге, үлем туктата.

— Шулай да, зур сер булмаса әйт әле: синең өчен бию нәрсә ул?

— Биюме? Бию — мин ул. Ул — минем гомер, барлык булмышым һәм хыялым, матур үткәнем, иң бәхетле минутларым һәм якты киләчәгем.

— Сәнгатьтәге девизың нинди?

— Бию аша кешеләргә шатлык өләшү, күңелләрен нурландыру.

— Әйтче, Мәхмүд Алисолтанович, шулкадәр көч-гайрәт һәм темперамент кайдан килә ул?

— Көчсез, хәлсез ир-атны һич күз алдыма китерә алмыйм. Андыйларны бик кызганам. Димәк, кеше үзенең кадерен белми, үз-үзен мыскыллый. Кеше үзенә табигатьтән бирелгән байлыкны бик сак һәм акыллы тотарга, тик файдага гына сарыф итәргә тиеш.

— Ә иң зур байлыгың нәрсә?

— Ватаным. Чит илләрдән хатыныма: «Нина, безне бик яхшы кабул итәләр, монда бик кызыклы, тик озак торырга язмасын. Тизрәк үзебезгә кайтырга туры килсен. Үз илемнең теләсә кайсы почмагында яшәргә риза»,— дип яза идем.

— Профессиональ сәхнәдә бер гасыр биергә язсын, Мәхмүд Алисолтанович.

— Изге теләкләрең өчен рәхмәт. Бию — яшьлек ул.

Әңгәмәне *Замир Низаметдинов* алып барды.

«ҺӘР ЯЗМЫШТА — КҮҢЕЛЕМ ҖЫЛЫСЫ»

Алсу Гайнуллинаның профессиональ сәхнәгә аяк басуына әллә ни озак вакыт узмады да шикелле. Ләкин ул иҗат иткән образлар галереясына күз салсаң, артистканың осталык үренә никадәр югары күтәрелүенә сокланасың. Әйтерсең лә, әнә шул гомер елъязмасын язучы һәр роль, һәр спектакль, һәр сезон Алсуның иҗатка булган омтылышын көчәйтә, аңа дәрман, илһам өсти.

Алсу — Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры актриссасы, иҗат яшьләренең Бөтенсоюз смотры лауреаты, Татарстанның халык артисткасы.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының Мәскәүдә булып узган иҗат имтиханнарның берсенә бәя биргәндә, үзәк газеталар Алсу Гайнуллинаның актерлык осталыгына аерым тукталдылар. Мисалга, «Бирнәсез

кыл» — театрның бәхәссез уңышы,— дип язды «Правда» газетасы,— иң беренче чиратта ул — актерлар уены уңышы. Бу пьеса илебез сәхнәләрендә сирәк куела, чөнки Лариса Огудалова роленә актриса табуы кыен. Камал театрында андый актриса бар. Ул — яшьлеге һәм чибәрлеге бөркелеп торучы, көчле драматик темпераментлы А. Гайнуллина».

— Алсу, кайсы гына йортка кунак килеп төшсә дә, сүзне гадәттә кунакның кайсы яктан булуы, туган-кардәшләре турында сорашудан башлыйлар. Ә безне сезнең театрга килүегез, профессиональ сәхнәдә ясаган тәүге адымнарыгыз кызыксындыра.

— Гаиләбездә тугызынчы бала булып дөньяга килгәнмен. Туган җирем — Чүпрәле. Мин өченче класска җиткәндә гаиләбез Казанга күчеп килде.

Мәктәптә укыганда ук Урицкий исемендәге культура сараеның татар халык театры спектакльләрендә катнаша идем. Ул чакта театрны ТАССРның атказанган культура работнигы К. Саттаров җитәкләде. «Театр язы»ның бер конкурсыннан соң жюри председателе Рәшидә ханым Җиһаншина һәм Һидият абый Солтанов миңа театр училищесына килергә тәкъдим ясадылар. Училищега кердем. Укуымның беренче көннәрендә бу адымым өчен үкенүемнең чик-чамасы булмады. Ләкин театрның сихри көче, мавыктыру сәләте тора-бара бөтен икеләнүләремне, шик-шөбһәләремне юкка чыгарды. Иң мөһиме — куркуымны җиңде. Янәшәмдә тәҗрибәле педагоглар булуына әле дә сөенәм. Бигрәк тә укытучым М. Сәлимҗанов киңәшен, сабырлыгын кызганмады.

Училищены 1974 елда тәмамладым. Профессиональ сәхнәдә башкарган иң беренче ролем — А. Гыйлаҗевның Бөек Җиңүнең 30 еллыгына багышлап язылган «Я кайтырбыз, я кайтмабыз» спектаклендә Шәфыйка иде. Хәтеремдә бу рольнең кыенлыгы гына сакланган. Бәлки, зур сәхнәдә беренче адымым булуы, үтә җаваплылык хисе, театрның олуглыгын тою — болар барысы да бергә җыелып, күңелемне каушау, курку биләгәндер.

— Беренче мәртәбә канәгатьләнү хисен кайчан кичердегез?

— Канәгатьләнү хисе кичергәнем юк. Башкарган эшеннән, ролеңнән рәхәт табу, ләззәт кичерү хисләре миңа берничә елдан соң гына килде. Бу халәт үз-үзеңә ышаныч тууга, сәхнәдә чын-чынлап яши белә башлауга бәйле, мөгаен. Әллә образларны җаным-тәнем белән тойганга, әллә аларны ихластан яратканга мы, «Әлдермештән Әлмәндәр»дәге Йөзембикә белән Гөлфирә рольләрен уйнап чык-

кач миңа шулкадәр рәхәт була. Ләкин мондый рәхәтлек озакка бармый. Аннан соң тагын бер чор башлана. Ул чакта нәрсәдер җитми, эзләнәсең, иҗатың тулы түгел шикелле тоела. Хәтта үз-үзеңне яратмый башлыйсың.

— Димәк, иҗат газабы башлана. Шулкадәр дә газаплымыни соң ул, Алсу? Газеталарда яшьләр шул газапны кичерергә әзер торулары, артист булырга хыялланулары турында язалар.

— Газап чигәргә берәү дә ашкынмый. Кирәкми дә, булмасын да ул. Ә иҗат газабы икенче нәрсә. Туктаусыз эзләнүләрдән, күңел бизүләрдән, өмет өзүләрдән соң, ниһаять, уңыш киләчәгенә ышаныч бар. Хезмәтеңне сөйсәң, мондый газап куркытмый. Һәр образ бер язмыш бит ул. Аңа йөрәк хисеңне, күңел җылыңны салмасаң, уңышка ирешәм димә.

— «Менә бу уңыш ичмасам!» — дигән чагыгыз булдымы?

— Юк. Ә: «Менә бу бәхет ичмасам!» — дигән чагым булды. Училищены тәмамлап, Г. Камал исемендәге театрга эшкә калдыруларын белгәч, мин үземне иң бәхетле кеше дип санадым.

— Сезгә театр сәхнәсендә генә уйнарга туры килми, радиода да, телевидениедә дә еш язылася. Шулай да спектакльне кайда уйнавы кызыклырак?

— Әлбәттә, сәхнәдә, үз тамашачыларың алдында. Тамашачының мөнәсәбәтен тоеп, аның белән рухи уртаклык табып уйнау бөтенләй башка. Ә телевидениедә син җансыз камера каршында, бернинди элемтәсез каласың.

— Сезгә тамаша залындагы реакция нинди йогынты ясый?

— Күңел тамашачының сине аңлавын, кичерешләреңне уртаклашуын тели. Ләкин алкышларга алданырга да ярамый. Алкыш һич тә тынычланыр өчен сәбәп түгел.

— Бер үк спектакльне кат-кат уйнау ялыктырадыр, мөгаен?

— Һич юк. Һәр спектакльдә образга нәрсәдер өстәлә. Спектакль камилләшүдән һичкайчан туктамый. Кайчакта: «Эх, шул детальне алданрак, элегрәк ник тапмадым икән?..» — дисең. Роль яшь бала сыман бит ул. Көнләп, айлап үсә, ныгый, кан йөгерә. Актер һичкайчан да үз геройларыннан аерылмый. Әйтерсең зур гаиләңне барлап яшисең. Спектакль репертуардан төшкәч, ролең белән аерылу гаять ямансу. М. Кәримнең «Ташлама утны, Прометей!» трагедиясендәге Агазия белән аерата шулай булды.

— Сезнеңчә, иҗатта нәрсәгә юл куелмаска тиеш?

— Канәгатьләнүгә, тынычланып калуга, гамьсезлеккә.

— Кешеләрдәге нинди сыйфатны кабул итә алмыйсыз?

— Икейөзлелекне. Хөрмәт иткәнем — кешеләрдәге ихласлык.

— Хәзерге заман актерының нинди сыйфатларга ия булуы мәҗбүри?

— Актерның, иң беренче чиратта, профессиональ осталыкка, фикер йөртү сәләтенә, гражданлык хисләренә ия булуы шарт. Актер замандашларының уй-хисләре, хыяломтылышлары белән яшәргә тиеш.

— Актерның яраткан партнеры буламы?

— Әлбәттә. Минем өчен, мәсәлән, Шәүкәт ага Биктимеров һәм Ринат абый Таҗетдинов белән уйнау үзе бер зур хозурлык. Алар көтелмәгән, кыен ситуацияләрдә һичкайчан ярдәмсез калдырмыйлар. Күз карашлары, интонацияләре белән шул мизгелдә үк ярдәмгә киләләр.

— «Бирнәсез кыз» дагы Лариса Огудалова роле өстендә эшләвегез турында да берничә сүз әйтсәгез иде.

— Гадәттә актрисалардан: «Нинди роль уйнарга хыялланасыз?» — дип сораганда, күпләр Лариса Огудалова диләр. Мин бу хакта хыялланырга да курка идем. Театрның әлеге әсәргә алынуы минем бәхеткә булгандыр. Образ җиңел бирелде дип әйтә алмыйм. Репетицияләр вакытында образның «орлыгын» әле табып, әле югалтып гаҗизләндем. Күп әдәбият укырга, эзләнергә туры килде. Ә иң мөһиме — Марсель Хәкимовичның киңәшләре, анык күрсәтмәләре ярдәм итте. Башкала тәнкыйтьчеләре театрыбызның бу эшен югары бәяләделәр. Бу — зур куаныч. Ләкин Лариса образын әле дә булса бөтен тирәнлеге белән тамашачыга җиткерә алмыйм дыр шикелле. Эзләнергә дә эзләнергә әле.

— Көтелмәгәнрәк сораудыр, бәлки, шулай да «Казан сөлгесе»ндә «апагыз» кызганыч түгелме?

— Нигә? Мин аны рәнҗетмим ич. Казан егетенең күзе миңа төшкән икән, мәхәббәтебез дә уртак булгач, апамны көтеп утыра алмыйм бит инде мин.

— Алсу, кунакка тәмам ияләшеп, аның белән танышып җиткәч, гаилә хәлләре турында да сорашырга кыенсынмый башлыйлар. Тормыш иптәшегез Илдар Хәйруллин да Татарстанның атказанган артисты бит. Ике танылган кешегә бер гаиләдә яшәү кыен түгелме?

— Һич кыен түгел, киресенчә, эшкә ярдәм итә. Илдар миңа караганда тәҗрибәлерәк тә бит әле.

Искәндәр исемле ул үстерәбез. Улыбыз бик мөстәкыйль. Эшебезне аңлый, юк-бар белән борчымый. Илдар белән

икебез дә гаилә җанлы булып чыктык. Мин пешерергә яратам. Илдар да йорт эшләрендә бик теләп катнаша.

— Инде әңгәмәбезне дә гадәти сорауга җавап белән түгәрәклик: киләчәктә нинди рольдә уйнарга хыялланасыз?»

— Монысы сер!

— Әңгәмә өчен зур рәхмәт, Алсу. Серле хыялыгыз тормышка ашсын.

Әңгәмәне *Илдус Сафин алып барды*

УЛ — КАЕННАР ИЛЕННӘН

Яңа ел кичәсе алдыннан булган бер вакыйга хәтергә сеңеп калган.

Казан телестудиясе журналистлары «Зәңгәр ут яктысында» дигән тапшыруга композитор Сара ханым Садыйкованы чакырырга уйлыйлар. Ә ул аларга ультиматум куя:

— Мөнир Якупов катнашса гына.

— Нигә алай дисез?

— Аның җырлавын башкалар да тыңласын инде,— ди Сара ханым.

Артистны заказ белән җырлата башласалар, алкышларга күмсәләр, аңа чәчәк бәйләмнәре бүләк итсәләр, ул инде популярлыкның үсә баруы хакында сөйли. М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры солисты Мөнир Якупов әлегә менә шушы танылу чорын кичерә, җыр сәнгатенең югары баскычына күтәрелергә омтыла. Монда аңа табигать биргән таланты ярдәмгә килә.

Мөнир Ульяновск өлкәсенең Кулатка районы Иске Атлаш авылында урман каравылчысы гаиләсендә туып үсә. Беренче стихиясе — урман, ул җитәрлек күләмдә азыктөлек ала да Катмир исемле этләрен ияртеп урманга чыгып китә, икешәр атна йөреп кайта. Шул чыгуда мул итеп печән, утын хәзерли, җиләк, гөмбә җыя, кош-корт, кырмыска ояларын рәтли, урманның сакланышын күзәтә. Күп вакытын табигать җырчыларын — кошлар симфониясен тыңлап үткәрә. Аларга кушылып үзе дә җырлый.

Каеннар илендә туып үскән егет үзенең урман-күлсез яшәвен күз алдына да китерә алмый. Сигезьеллык мәк-

тәпне тәмамлагач, ул урман кисүче була, аннары тракторчы һөнәрен үзләштерә. Профессиональ-техник училищеда укыганда бер үк вакытта кичке урта мәктәпне дә тәмамлый. Һәм кинәт барысы да үзгәрә...

Авылга Казаннан Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең Венера Шәрипова житәкчелегендәге бригадасы килеп төшә. Сирәк була торган кунаклар. Бу көн күпләр өчен бәйрәмгә әверелә. Ә Мөнир өчен ул бигрәк тә. Егет концерт тәмамлануын да көтмичә, тәнәфестә сәхнә артына килеп керә.

— Мине тыңлап карагыз әле,— ди ул, бер Венера Шәриповага, бер Габделхак Шаһиевка карап.

— Нәрсә жырларга исәбең?

— «Родина»ны. Туликов музыкасы.

Артистларны Мөнир Якуповның көчле тавышы таң калдыра. Нигездә дөрес жырлый. Үзендә өмет уята.

— Татарча бер жыр да белмисеңмени соң, энем? —дип сорый Венера апасы.

— Беләм лә соң, ди дә:

Без утырган машинаның
Тоткалары жиз генә.
Йөгерсә китәрдәй булам ла,
Кайтып житәрдәй булам.
Күзгә ачы жилләрдә —
Туган-үскән илләргә,—

дип жырлап жибәрә.

— Менә бит татарча да бик әйбәт жырлыйсың икән ләбаса. Күбрәк жырлар өйрән син,— дип, күңелен күтәрәләр егетнең. Аны тиз арада Казанга килеп чыгарга чакыралар.

Ансамбльнең ул чактагы житәкчесе, танылган композитор А. С. Ключарев филармониядә Мөнир Якуповны тыңлауны оештыра. Уңай бәялиләр. Шунда ук, элеккеге эш урыныннан азат итүләрен сорап, Мөниргә кәгазь язып бирелә. Ә тагын бер атнадан инде ул ансамбль составында гастрольгә китеп бара.

Яшь жырчы өчен серле яңа дөнья ачыла. Беркадәр вакыт ул үзен зифа каеннар арасыннан куе яшел имәнлеккә кергәндәй хис итә. Әлеге гүзәллекнең тәэсире белән рухланып яши башлый. Яңадан-яңа жырлар өйрәнә, репертуарын баета.

Аннары хәрби хезмәт. Анда да жырны ташламый, ансамбльдә актив катнаша. Совет Армиясе сафларыннан кайткач та егет филармониягә эшкә урнаша. Бер үк вакытта ул консерваториянең хәзерлек курсларына йөри баш-

лый. Аннары СССРның халык артисты, атаклы композитор Нәҗип Җиһанов егеткә консерваториянең төп курсына күчәргә тәкъдим итә. Шулай итеп, Мөнир Якупов ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе В. А. Воронов классында укый башлый. Музыкаль грамотаны — ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСРның Глинка исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Фасил Әхмәтовтан, камера җыры буенча дәресләрне РСФСРның атказанган артисты Гөлшат Сәйфуллинадан ала, актерлык осталыгына ТАССРның халык артисткасы Шәхсәнәм Әсфәндиаровадан өйрәнә.

Консерваториядә укыганда аңа М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрының баш режиссеры, РСФСРның халык артисты Нияз Даутов игътибар итә. Чөнки бирдә ул кафедра җитәкчесе дә, һәр студентның талантын һәм мөмкинлекләрен белеп тора.

— Егетнең тавышы көчле, матур, буй-сыны күркәм, артистлык сыйфатлары югары. Аны зур театр сәхнәсендә җырларга тиеш дип саныйм,— ди Нияз Курамшевич, Мөнирнең театрга ничек аяк басуы турында сөйләп.

Һәрбер студент Нияз Курамшевич кебек олы талант кулы астында эшләү хакында хыялланадыр. Нияз Даутов — татар опера сәнгатендә үзе бер мәктәп бит ул. Өлкән җырчы Мәскәү театр студиясен уңышлы тәмамлый. Югары уку йортының Гыйльми советы карары нигезендә консерваториядә калдырыла. Шушы елларда ук Муса Җәлил, Нәҗип Җиһанов кебек талантлы яшьләр белән аралаша, аларның җырларын башкара. Бөек Ватан сугышы алдыннан Мәскәүдә үткәреләчәк татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына хәзерлек эшләре башлана. Н. Даутовка әлеге авторларның «Алтынчәч» операсыннан Җик партиясен тапшыралар. Билгеле сәбәпләр аркасында декада булмый кала. Ләкин җырчы Җикне беренче булып башкару бәхетенә ирешә. Аннары «Евгений Онегин» операсыннан Ленский партиясе. Моңа чаклы бу гаять катлаулы психологик партияне атаклы җырчылардан Собинов, Лемешев һәм Козловскийлар башкарган була. Шул рәвешчә яшь җырчы Нияз Даутов сәхнә пәһлеваннары белән бер сафка баса.

Мәскәүнең Станиславский һәм Немирович-Данченко исемендәге, аннары Свердловск шәһәре театрлары бу җырчыны яңа югарылыкка күтәрде. Ниһаять, 1955 ел. Казан. Ә тагын бер елдан М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры ачылуы. Н. Даутов анда баш режиссер итеп чакырыла. Татар опера сәнгатенең күтәрелеш һәм үсеш еллары нигездә нәкъ менә шушы елларга туры килә.

З. Хисмәтуллина, Ш. Котдусова, Ф. Насретдинов, У. Альмиев кебек талантлар янына яшь башкаручылар да өстәлә тора. Мөнир Якупов үзенең шундый бай тарихлы, зур талантлары белән данлы коллективка килеп эләгүенә сөенә.

Дәүләт имтиханнары аның өчен олы сәнгатькә аяк басу да була. Анда театрда Н. Җиһановның «Намус» операсында Хәйдәр партиясен тапшыралар. Хәйдәр ариясе — мәхәббәт җыры, халык моңы белән сугарылган. Моңа кадәр күбрәк рус композиторларының романсларын башкарган Якупов спектакльдә яңа бер ягы — милли колоритны уңышлы бирә белүе белән ачыла. Әлеге дебюттан соң яшь башкаручы татар халык җырларына күбрәк игътибар итә. Репертуарында төп урынны алган «Илкәем» дигән татар халык көе шундыйлар рәтенә керә. Аның сүзләрен әдәбиятыбыз аксакалы Нәкый ага Исәнбәт моннан 70 еллар элек 17 яшендә чакта ук язган. Ул елларда җыр киң таралган булса да соңга таба онытылып тора. Ә Финляндиядә яшәүче татарлар аны җырлыйлар. Читтәгеләр туган илне сагыну, сагышлануларын шушы җыр аша җиткерәләр.

Анда җырлый җирдә һәр таш,
Кул изи һәрбер агач.
Анда кайтсам мин дә башка,
Анда мин дә сандугач.

Җыр туган илгә яңадан әйләнеп кайтты. РСФСРның халык артисты Илһам Шакиров аңа икенче тормыш бирде. Атаклы җырчыдан соң Мөнир Якуповка бу әсәрне башкару җиңел түгел, әлбәттә. Ләкин көчле тавышы, профессиональ осталыгы аңа җырны халык күңеленә үтәрлек итеп башкарырга мөмкинлек бирә.

М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры — Мөнир Якуповның киң колачлы иҗат чишмәсе. Ул биредә дөнья классикларыннан Гуноның «Фауст» операсында Валентин, Вердиның «Травиата»сында Жермон ариясен, «Князь Игорь» операсында Игорьны, милли әсәрләрдән Н. Җиһановның «Алтынчәч» операсында Колый Хан ариозасын, «Качкын»да Булат ариясен, Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясендә Вафа ариясен башкарды. «Башмагым»ны хәзерләгәндә СССРның халык артисты Азат Аббасовның үзенә зур булышлык итүен Мөнир рәхмәт хисләре белән телгә ала. Башкача мөмкин дә түгел, комедиядә А. Аббасов Кәрим бай партиясен башкарса, яшь җырчы аның кияве Вафа образын сурәтли.

Өлкәннәрнең ярдәмен тоеп яшәү яшьләргә иҗади үсеш-

тә мөмкинлекләрен киң ачарга ярдәм итә. Яшь башкаручының РСФСРның халык артисты, Г. Тукай исемендәге ТАССР дәүләт премиясе лауреаты Фәхри Насретдиновка да рәхмәте зур. Алар Үзбәкстан ССРга гастрольгә бергәләп баралар. Танылган җырчы яшь башкаручыга киләчәккә репертуар сайлауда, программа төзүдә киңәшләрен бирә, башкару осталыгына төзәтмәләрен кертә. Опера өлкәсендә генә түгел, татар халкының озын көйләрен, композиторларыбыз әсәрләрен дә оста башкаруы белән күптән инде тамашачыларның мәхәббәтен казанган җырчының ул киңәшләре Мөнир өчен зур мәктәп була.

Җыр жанрына йөз белән борылуы Мөнир Якуповка яңа мөмкинлекләр ача. Татар композиторларыннан Ф. Әхмәтов, Р. Яхин, Р. Еникеев, Р. Билалов романсларын һәм җырларын ул шактый үзенчәлекле башкаруга ирешә.

Югарыда тикмәгә генә Сара ханым Садыйкова исеме телгә алынмады. Чыннан да, яшь җырчы бу авторның әсәрләрен яратып башкара. Р. Биктимеров сүзләренә язылган «Сагыш», Г. Латыйп сүзләренә язылган «Акбүз атым», «Бөтен гомергә» дигән җырлар уңышлы яңгыраган шундый әсәрләр рәтенә керә. Менә шушы ук композиторның Ә. Талипов сүзләренә язылган «Тиргәмәсләр кызлар» дигән җыры:

Тиргәмәсләр, җырларымны сузып
Иңлим әле авылым урамын.
Тиргәмәсләр, төнге йокылардан
Уята алсам авыл кызларын.

Әлеге лирик җыр Мөнирнең үзен дә туган якларына, яшел тугайларына, ак каенлы урманнарына алып китә төсле. Шуңа да ул татлы йокылардан уятырлык моңлы яңгырый. Лирик-драматик баритон тавышлы яшь җырчы иҗат юлында яңа үрләрне әнә шулай яулый.

Госман Гомәров

«ИҢ ЯХШЫ ӘСӘР ӘЛЕ ЯЗЫЛМАГАН...»

Аның исеме, тирән эчтәлекле картиналары безгә яхшы таныш. Л. Фәттәхов белән берлектә язылган «В. И. Ленинның Татарстан АССР төзелү турындагы декретка кул

куюы», Муса Җәлилнең фашист палачлары алдында да баш имәгән горур образын чагылдырган «Хөкем алдыннан», Советлар Союзы Герое М. Девятаев турындагы һәм башка картиналары...

Рәссамның соңгы елларда иҗат иткән әсәрләре арасында яшь Ульяновның студентлар сходкасында катнашуына 100 ел тулуга багышланган полотносы («В. И. Ульянов-Ленин Казан университетында студентлар сходкасында. 1887 ел») аерым урын тота.

Тарихи вакыйгаларны нәкъ чын тормыштагыча күз алдына китереп бастырган бу әсәрләр бер карауда хәтердә кала.

Рәссамның тормышы һәм иҗат юлы истәлекле һәм кызыклы вакыйгаларга бай. Ул Бөек Ватан сугышында данлы юл үткән, «Кызыл Йолдыз», II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, сугышчан медальләр белән бүләкләнгән. Аның сугыштан соңгы хезмәтләрен дә партиябез һәм хөкүмәтебез югары бәяләгән. Х. Якупов — Ленин һәм «Почёт билгесе» орденнары кавалеры.

СССРның халык художнигы, СССР Художество академиясенең член-корреспонденты, СССР, РСФСР һәм ТАССР Дәүләт премияләре лауреаты Харис ага Якупов белән мин аның Зур Кызыл урамындагы остаханәсендә очраштым. Ул, бөтенләй онытылып, ниндидер эскизлар карый иде. Ә бәлки, чираттагы зур әсәрнең туу вакыты шушыдыр? Мин аның үзенә шул сорауны бирдем.

— Ихтимал,— дип елмайды ул.— Рәссамнар арасында бер әйтем бар: иң яхшы әсәр — әле язылмаганы. Шул принциптан чыгып караганда, бусы минем әсәрләремнең иң әһәмиятлесе булырга тиеш. Хәер, без һәр картинаны язарга керешкәнче шулай дибез.

— Ә эшләнеп беткәч яңадан-яңа фикерләр, планнар туадыр.

— Әлбәттә. Шуның өчен дә иҗат бит ул. Эзләнүләр, икеләнүләр, янулар иҗатта табигый нәрсә. Яхшылыкка, камиллеккә ирешүнең чиге юк. Ирешелгән уңышлар белән канәгатьләнеп калсаң, яхшы әсәр иҗат итеп булмас иде.

— Харис Абдрахманович, үз эшеңнән, иҗат җимешеңнән канәгать бумыйча, ягъни ләззәт алмыйча уңышлы әсәр тудыруны шулай ук күз алдына китерүе кыендыр.

— Әйе, ул мөмкин дә түгел. Бу урында художник өчен тамашачы хөкеменең ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын әйтмичә ярамый. Әсәрең кешеләр күңеленә барып җитә, алар тарафыннан яхшы бәяләнә икән, димәк, куйган максатыңа

үрештең дигән сүз. Моннан да зур шатлык юк инде. Һәм ул шатлык бөтен борчуларны, иҗат газапларын оныттыра, яңа эшләргә рухландыра.

— Үзегезне аеруча дулкынландырган берәр эшегезгә тукталсагыз иде.

— «Вахитов исемендәге колхозның алдынгы кешеләре» сериясенә кергән картиналар миңа аеруча якын. Бу сериягә 7—8 картина керә. Аларда мин бүгенге колхоз тормышын, аның хезмәт сөючән уңган кешеләрен, аларның уй-хыялларын чагылдырырга тырыштым. Ул картиналарның тууы да истәлекле булды. Питрәч районының Вахитов исемендәге колхозында булырга, колхозның җәйге лагерьларында терлекчеләрнең хезмәт-көнкүреш шартлары белән танышырга туры килде. Дүрт ел чамасы мин алар белән бергә булдым. Сыер савучылар, көтүчеләр белән бер гаилә булып яшәдек. Һәм нәтиҗәдә уңышлы гына әсәрләр иҗат ителде. Бу сериягә кергән картиналар СССР Художество академиясе членнары әсәрләреннән Мәскәүдә оештырылган күргәзмәгә дә куелды. Ул әсәрләр белән Югославия, Прага, Берлин, Монголия тамашачылары да танышты.

Рәссам өчен халыкка якын килү, алар белән аралашу, аларның гадәти, җанлы әңгәмәләрен тыңлау бик мөһим. Революционер-демократ Н. Г. Чернышевский сүзләре белән әйткәндә «тормыш үзе гүзәллек» бит. Тормышка якын килү художникның иҗат офыкларын киңәйтә, яңа темаларны, сюжетларны үзе күрсәтеп бирә. Колхоз авылы кешеләре темасы — гомумән, минс нык дулкынландыра торган темаларның берсе ул.

— Сез инде танылган рәссам, өстәвенә, гаять зур җәмогать эшләре дә алып барасыз. Ә кайчандыр, балачакта, шул турыда хыяллана идегезме?

— Белмим. Мөгаен, рәссам булу хыялы минем үзем белән бергә тугандыр. Ә тормышта миңа хыял белән бик мавыгырга туры килмәде. Барысы да үзеннән-үзе баргандай тоелды. Шунысы бар, мин үземне белә башлаганнан бирле рәсем ясыйм. Кар өстенә дә, өстәл өстендәге тузанга да, парланган тәрәзә пыяласына да рәсем ясый идем. Анпары шунысы истә калган. Минем әни мәктәптә җыештыручы булып эшли иде. Ә мин, кечкенә генә малай, аңа ияреп мәктәпкә киләм. Идән себергәндә кайчак кечкенә генә карандаш, бозгыч кисәкләре табыла, кайчак хәтта төсле карандаш кисәге дә килеп чыга. Бусы инде минем өчен аеруча зур шатлык була торган иде.

— Ә иң беренче тапкыр дөнья күргән рәсемегез хәтердәме?

— Әй, әле генә исемә төште. Минем Казанның 13 нче мәктәбендә укыган чак. Үзем рәсем түгәрәгенә йөрим, «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналын, «Яшь ленинчы» газеталарын укыйм, шуларга кайбер рәсемнәремне дә җибәргәлим. Шулай бервакыт, урманда пионер лагере күренешен ясап, «Яшь ленинчы»га җибәрдем. Нәтиҗәсен көтәм, һәр санны игътибар белән карап барам. Беркөнне газетада минем рәсемем чыга. Шатланып бетә алмыйм. Рәсемне кат-кат карагач, астындагы язуына күзем төште: укучы иптәшләр, бу рәсемдә нинди ялгышлар бар? — дип язганнар. Менә шулай дөнья күрде беренче рәсемем.

Мәктәптән соң Казан художество училищесы. Фин сугышы. Бөек Ватан сугышы... Сөйли китсәң, күп инде.

Бераз буш вакытым булдымы, тарихи чынбарлыкны эченә алган документаль әсәрләр укырга яратам. Шул планда үзем дә язгалыйм. Үзем белән бергә сугыш утлары кичкән кешеләр турында истәлекләр язам.

— Харис Абдрахманович, бүгенге көн яшьләренә нинди теләкләрегез бар?

— Эшне әһәмиятле һәм әһәмиятсезгә бүлмәскә. Юкса, кайберәүләр «юк-бар эш», «мөһим эш» дип сөйләргә яраталар. Шуңа бәйле рәвештә, хезмәткә төрлечә караш туа. Нинди генә эшкә тотынсаң да, аңа күңел биреп, зур җаваплылык тоеп башкарырга өйрәнергә кирәк. Зур эшләр кечкенәләрдән җыела бит.

Рина Зарипова

«ХЫЯЛЫМДА — МАТУРЛЫК»

Туып-үскән ягым — Апас районы дип башлый әңгәмәбезне «Малыш» ательесының югары разрядлы кисүчесе Мөслимә Хәсәнова. Шунда урта мәктәпне тәмамладым. Дөресен әйтергә кирәк, мәктәптә әйбәт укыдым. Институтка керүемә берәүнең дә шиге юк иде. Хәер, мин кая укырга керәчәгем, кем булачагым турында берәүгә дә сөйләгәнем булмады. Минем өчен тегүче булу үзеннән-үзе билгеле кебек иде.

— Гаиләгездә кем дә булса тегүче булгандыр, мөгаен?

— Әйе, әбием бик оста тегүче иде. Берәр җиргә барса, яңа фасон белән тегелгән берәр кием күрсә, шулкадәр

сокланып сөйләр иде. Мин, үзем дә сизмәстән, аны тыңлап торам. Күрәсең, аның сәләте, аның тегү эшенә мәхәббәте миңа күчкәндер. 10 классны тәмамлауга, 42 нче шәһәр профессиональ-техник училищесына килдем. Менә аны тәмамлап эшли башлавыма да байтак гомер үтте инде. Коллективта дус, тату эшлибез. Республикабыз кисүчеләренең осталык конкурсларында күп тапкырлар җиңүче булдым.

— Сезгә өлкәннәргә дә, балаларга да хезмәт күрсәтергә туры килә. Балалар киемнәренә нинди таләпләр куясыз?

— Балалар киеме иркен, уңайлы, аларның хәрәкәтен чикләми торган булырга тиеш. Иң элек менә шуны да истә тотып эш итәбез. Аннары балалар өчен материалларның да иң ачык төстәгесе, матурлары сайлана. Бизәкләр, чигешләр, аппликацияләр. Балаларны чәчәк кебек киендерү үзе бер кызыклы да, мавыктыргыч та шөгыль бит ул.

— Сез эшли торган ательеда нәкъ менә сезне көтеп торучы заказчылар күп була. Моның сәбәбен ничек аңлатасыз?

— Аның сәбәбе бик гади. Кечкенә генә бер мисалдан башлыйм. Шулай бервакыт мәктәптә укучы бер кыз күлмәк тегәргә заказ бирде. Ул чакта мин бу ательеда беренче елымны гына эшли идем әле. Күлмәген бик ошатып, рәхмәт әйтеп алып китте. Икенче көнне үк әлеге кызның әнисе килгән. «Миңа да берәр күлмәк тегеп бирсәгезче»,— ди. Аның заказын үтәп бетерүгә, дәү әниләре килгән... Менә шулай, бер текттереп алган кешеләр безгә гаиләләре белән йөри башлыйлар һәм даими заказчыларыбызга әйләнәләр. Безгә укучылар да, студентлар да, гомумән, иң нәниләрдән башлап төрле яшьтәге кешеләр киләләр. Җәен дә, кышын да шулай. Сүз уңаенда әйтергә кирәк, әлеге кызның хәзер үз гаиләсе бар. Ул һаман да кием тектерәсе булса безнең ательега килә. Күптән түгел мин аның 3 яшьлек кызына күлмәк кистем.

— Мөслимә, алайса сез үз эшегездән канәгать буласыздыр?

— Ательега беренче аяк баскан кешенең алга таба да даими клиентка әйләнеп китүе безнең өчен куанычлы күренеш, әлбәттә. Ләкин эшеңнән соң чиккәчә канәгать булу мөмкин түгел дип саныйм мин. Яхшыдан яхшыга, матурдан матурга омтылырга туры килә. Мин менә урамда йөргәндә дә кешеләрнең киемен күзәтәм.Шулай күнегелгән. Карыйсың — берәүләрнең өстендәге кием шулкадәр матур,

ә икенче бирәүдә... Андый чакта уйлап куясың инде: кисүчеләргә, тегүчеләргә өйрәнәсе нәрсәләр аз түгел икән әле!

— Кисүче һөнәрен сайларга теләгән яшьләргә нәрсә әйтер идегез?

— Иң элек бу хезмәтнең бөтен авырлыгын, катлаулылыгын күз алдына китерә белергә кирәк дияр идем. Кешеләрне яратканда гына, түземле һәм игътибарлы, гомумән, кешеләрнең холык-фигылен яхшы белгәндә генә безнең эштә уңышка ирешеп була. Әйе, әйе, кешенең холык-фигылен, аның зәвыгын белми торып, аңа фасон сайлый алмыйсың. Әйтик, берәүләргә тәңгә сыланып торган кием килешсә, икенчеләр мондый күлмәктән үзләрен уңайсыз хис итәргә мөмкин. Янсә берәү артык заманча күлмәк фасонын сайлаган, тик аңа бу килешми. Аның үзенә ишләп кенә менә шуны төшендерергә, фасонның үзенә килешә торганын тәкъдим итәргә туры килә. Шуңа күрә кисүче хезмәте авыр инде ул. Аңа бер үк вакытта әллә ничә төрле һөнәр иясе сыйфатларына ия булырга кирәк. Художник та, модельер да, конструктор да, хәтта психолог та. Бары тик шул чагында гына кешеләр синең эшеңнән канәгать булалар, шунда гына син аларның рәхмәтенә лаек буласың.

— Эштән буш вакытта нәрсә белән шөгыльләнәсез?

— Сызымнар, җыр, театр, үзем пешергән тәмле ризыклардан матур итеп табын әзерләү — миңа менә шулар ошый. Матур булган бөтен нәрсә мине үзенә тарта. Һәркем өчен дә табигыйдыр инде ул.

— Соңгы сорау сезгә, Мөслимә. Үзегез өчен иң изге хыялыгызны әйтегез әле.

— Хыяллар күп инде алар. Үз профессиям буенча югары белем алырга һәм тагын берсе — һәр кешене дә бик матур итеп киендерергә. Агач күрке — яфрак, адәм күрке — күлмәк, дип юкка гына әйтми бит халык.

Әңгәмәне *Рина Зарипова*
алып барды

ҺӘР ДӘРЕСЕ — БЕР ТАРИХ

Мидхәт Ризванович Ижбулатов Кемерово өлкәсе Анжеро-Судженск шәһәрендә туа. Шундагы рус мәктәбендә укый һәм Томск дәүләт университетын тәмамлый.

Кемерово өлкәсендә мәктәптә укыган елларында татар тарихын җентекләп өйрәнә башлый. Өлкәнең «Кузбасс» исемле газетасында шул хактагы тарихи мисалларга нигезләнгән үтемле мәкаләләре белән чыга.

Татар үзешчән сәнгать коллективы оештыра. Өлкәдәге татар авылларында, татар шахтерлары арасында алар көтеп алынган кунак булалар.

Татар телендә Казанда чыга торган матбугатны Себер ягында таратуда күп хезмәт куя.

Аның татар халык тарихына багышланган мавыктыргыч лекцияләре күп милләтле шахтерлар арасында зур кызыксыну уята. Үзенең чыгышларында ул, тарихка гына кагылмыйча, туган телебезнең Америкада яшәгән инке, ацтек, майя халыклары теле белән кардәшлеге турында да сүз алып бара.

Хәзер ул Татарстан тарихын укыта һәм үзе яраткан тарихи эзләнүләр эшен дәвам итә. Бүгенге көндә ул эшләгән Рус Әҗәле (Зеленодольский районы) урта мәктәбе — совет илендәге Татарстан тарихын предмет буларак өйрәнә торган аз санлы мәктәпләрнең берсе.

— Мидхәт Ризванович, торгынлык заманында татар

халкының тарихын, культурасын яклап ясаган чыгышларыгыз нинди ышанычка нигезләнгән иде?

— Гаделсезлекнең тантанасына мин беркайчан да ышанмадым. Тарихны дөрес аңлатмау нинди коточкыч фаҗигаләргә китергәнс һәммәбезнең күз алдында. Үзенең бабаларын гына түгел, эти-әниләрен дә танырга, хөрмәт итәргә теләмәгәннәрнең күбәеп баруы әнә шуның нәтиҗәсе. Миңа, Татарстаннан читтә үскән кеше буларак, бу хәлләр ныграк таныш. Казан төбәгендә яшәүче татарлар әле күпмедер дәрәҗәдә халык тарихыннан хәбәрдар. Аларга бабаларыбызның борынгы дәүләте Болгар якын. Казан ханлыгы турында да алар азмы-күпмс ишетеп беләләр. Ә бит мин туып үскән Себер якларындагылар татар халкының Октябрь революциясенә кадәр үз язмалары булмаган, алар надан булганнар дип чын күңелдән ышаналар. Безнең белән ут күршеләр булып яшәгән башка милләтләр генә түгел, үзебезнең татарлар арасында да шулай уйлаучы яшь буын үсеп җитте. Язмасы булмаган, дигән сүз — аның галимнәре дә булмаган, шагыйрьләре дә, полководецлары да булмаган, дигән сүз белән бер ул.

— Мидхәт Ризванович, ә бу гаделсезлекне Сез кайчан төшенеп алдыгыз? Моңа бит ниндидер сәбәп этәргеч булгандыр?

— Мәктәптә укыган еллар иде. Классташларыма мин үземнең бабамның генерал булып, патша армиясендә шул дәрәҗәгә кадәр хезмәт итүен сөйләдем. Миннән тәгәрәп көлделәр. «Татарлар арасында революциягә кадәр нинди генерал булсын, алар әле тау куышларында, урман эчләрендә яшәгәннәр, ә мунчаның нәрсә икәнен дә белмәгәннәр»,— дип аңлатырга керештеләр. Мин бик рәнҗедем. Үземнең авыр уйларым белән уртаклашырга мәктәп директоры, белеме буенча тел-әдәбият белгече Галина Алексеевна Веденскаяга килдем. Бөек рус халкының каймагы булган демократик зыялылар нәселеннән чыккан шушы ягымлы рус хатыны миңа ярдәмгә килде. Мин аның олы җанлы сыйфатларында декабрист хатыннарындагы, В. И. Ленинның әнисендәге чалымнарны табам. Унынчы класста укыган чакта ул миңа «Татар халкының культурасы һәм әдәбияты тарихы» дигән темага доклад язуны тапшырды. Шәһәр китапханәсендәге бу темага кагылышлы бөтен китапларны барлап чыктым. Бөек Болгар дәүләтенә килеп кердем. Мәшһүр шагыйрь Кол Гали турында сөйләдем. Казан ханлыгына аяк бастым. Шагыйрь Мөхәммәдьяр белән таныштырдым. Ике сәгатькә сузылган бу докладны иптәшләрем тын да алмый тыңладылар. Укучылар

гынамы? Укытучылар да, «колаклар дөрес ишетәме?» дигәндәй, исләре китеп тыңладылар.

— Сез үзегезнең чыгышларыгызда, язма хезмәтләрегездә халкыбыз тарихына караган бик күп кызыклы мисаллар китерәсез. Аларны эзләргә ничек вакыт табасыз? Ә бит укытучының эше болай да «тавык чүпләп бетергесез».

— Ял көннәрем, җәйге каникул вакытларым В. И. Ленин исемендәге Республика китапханәсендә үтә. Аннан соң инде бит мин унынчы класста доклад ясаган «сары томшыклы» малай түгел. Студент вакытымда мин сабакташларым арасында бердәнбер татар малае идем. Бу минем өскә бик зур җаваплылык өстәде. Украина, Белоруссия республикаларыннан, Мәскәү, Ленинград, Кемерово, Томск кебек дистәләгән төбәкләрдән килгән студентларга халкымның күп гасырлы культурасы хакында сөйләргә кирәк иде. Төннәр буе Томск, Кемерово китапханәләрендә утырдым. Һәрбер тарихи белешмәне бөртекләп җыя бардым. Соңыннан, Татарстанга килеп Зеленодольский районының Рус Әҗәле урта мәктәбендә укыта башлагач, бу хәзинә минем эзләнүләремә ныклы нигез булды. Хыялым мәктәптә Татарстан тарихын аерым фән буларак расписаниегә кертү иде. Бәхетемә каршы, район мәгариф бүлеге мөдире һәм мәктәп директоры минем тәкъдимне хупладылар. Бу мине канатландырып җибәрде. Быел менә нәтиҗәсе дә күренде. Январь аендагы педагогик укулар вакытында, 500 укытучыга үземнең фикерләремне сөйләп, тәҗрибә уртаклаштым.

— Бүгенге мәктәпнең тәрбияви көче үз дәрәҗәсендә булсын өчен нәрсәләр эшләргә кирәк дип уйлыйсыз?

— Халык үзенең кем икәнен белергә тиеш дип уйлыйм. Балалар ата-бабаларын белергә тиеш. Кешедә горурлык хисе булырга тиеш. М. С. Горбачевның матбугат работниклары белән очрашуында бу мәсьәлә бөтен әрнүе белән кузгатылды. Ул очрашуда илебезнең тарихы юклыгы әйтелде. «Без Франция, Англия, Германия тарихын өйрәнәбез, ә илебез тарихын белмибез, бу гафу ителмәслек хәл», диелде. Чыннан да, без үзебезнең тарихыбыздан бер генә якты сәхифә дә белмибез ләбаса. Әчит ил халыклары безгә караганда күбрәк белә, мәгълүматлары да күбрәк. Әйтик, Болгария Халык Республикасының «Отечество» («Ватан») газетасы болай дип яза: «Бөек Болгар һәм Биләр хәрабәләре Троя һәм Помпей кебек үк фәнни кыйммәткә ияләр».

Мәшһүр татар галиме Шиһабетдин Мәрҗәни болгар цивилизациясен юкка гына Византия һәм Андалуз культурасы белән тиңләмәгән.

Петр патша, Болгардагы Кечс манарага менеп карагач, соклануын яшерә алмаган. Һәм шәһәрнен калган өлешен саклау турында указ чыгарган.

Мин сораудан бераз читкәрәк киттем бугай. Шулай да зыян юк. Болар барысы да мәктәптәге тәрбиягә бәйле. Балалар мәктәптә үзләренең тарихын белеп үсәргә тиеш. Балаларыбызга музыкаль белем бирелү мәҗбүри булырга тиеш. Безнең бит хәтта музыка мәктәпләрен тәмамлаучылар да татар, башкорт һәм башка тугандаш халыкларның музыкасын белмиләр. Татарстанда укып, үсеп, яшәп — Татарстанның сынлы сәнгатен кайсы бала мәктәптән белеп чыга икән? Бу безнең иң авырткан җиребездер...

Казан телевидениесе балаларга ярдәмгә килә алыр иде. Күрәсез, мәктәпнең үзеннән генә тормый. Укытучы буларак әйтәм, балалар безнең матур, омтылышлары зур. Әти-әниләрнең, бөтен җәмәгатьчелекнең ярдәме генә кирәк.

— Мидхәт Ризванович, дәресләрдә балаларның иң кызыксынып тыңлаган тарихи вакыйгалары нәрсәләр?

Балаларны бигрәк тә бабаларының борынгы тормышкөнкүреше кызыксындыра. Болгарда бит зур мәктәпмәдрәсәләр, китапханәләр эшләгән. Андагы галимнәр бөтен Көнчыгыш-шәрык илләренә билгеле булган. 1135 елда бөек гарәп галиме Әбу Хәмид әл Гарнати (әл Андалуси) ерак Испаниядән күренекле тарихчы Якуб ибн Ногман белән очрашырга Биләргә килә. Ике зур галимнең күрешүе зур фәнни-тарихи мәҗлескә әверелә. Мондагы гыйлем байлыгына исе киткән Андалуси олы улын Биләр мәдрәсәсендә белем алу өчен калдыруларын үтенә.

Бирсдә медицина фәне дә бик алга киткән була. Ике бертуган табиплар — Хәсән һәм Таҗетдин ибн Юнус әл Болгариларның «Агулануга каршы даруларны ничек әзерләргә» дигән китабы хәзергә кадәр сакланып калган. Ул бүгенге көндә Иран башкаласының фәнни китапханәсендә.

Мондый тарихи вакыйгалар шактый. Әйтик, бөек Болгар чорында яшәгән шагыйребез Сәйф Сарап 1394 елны язылган бер әсәрендә болай ди:

Әйләнде сгет бу кыз яшь тирәли,
Җир әйләнгән кебек кояш тирәли.

Игътибар иттегезме? 1394 ел! Коперниктан 150 ел алда, Джордано Брунодан 200 ел алда безнең бабайлар Җир-

нең Кояш тирәли әйләнүен, гадәти итеп карап, шигырьгә кертканнәр. Моның өчен аларны беркем дә яндырмаган да, эзәрлекләмәгән дә. Акыл һәм гыйлем тантана иткән җирдә генә шулай була ала.

Яки Германиядән 200 ел алда болгар бабайларның домна мичләрендә чуен койганнарын алыйк. Археологлар Татарстан җирлегендә әнә шундый 36 домна миче таптылар. Казан ханлыгы чорында яшәгән шагыйрь бабабыз Мәхәммәдьяр үзенең әсәрләрендә, Томас Мор һәм Кампанелла кебек, утопик дәүләт турында яза. Ул анда изүләрдән азат булган тигез хокуклы кешеләр җәмгыяте турында хыяллана.

Әйе, без әле тарихыбызны белмибез генә. Әгәр аны өйрәнсәк, белсәк, татар халкының кешелек цивилизациясе тарихында нинди урын тотканын белер идек.

— Димәк, безнең киләчәктәге эшебез узган чорыбызның әлифбасын өйрәнүдән торырга тиеш.

— Мәктәпләребездә — бу чыннан да әлифба. Татар халык җырын искә алыйк:

Урман эчләрендә урман,
Керсәм чыгалмам инде...

Чыннан да, безнең үткән тарихыбыз карурман. Аңа керсәң — ул сихри дөнья. Аңа керсәң — музыка сәнгате. Аңа керсәң — рәсем сәнгате. Безгә шул карурманга эндәшергә кирәк. Урманга аваз салганыгыз бармы? Ул кайтаваз булып җавап бирмичә калмас.

Әңгәмәне *Мөдәррис Әгъләмов* алып барды

ТЕЛЕ БАРНЫҢ ДАНЫ БАР

Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин 1925 елның 29 маенда Татарстанның Саба районы Чәбия-Чүрчи авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлагач, укытучы булып эшли. 1943—1947 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. Курск дугасындагы сугышларда, Украина, Румыния, Венгрия, Чехословакияне азат итүдә, Ерак Көнчыгышта япон империалистларына каршы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, өч тапкыр яралана, контузия ала, шәхси батырлыгы өчен Беренче дәрәҗә Ватан

сугышы ордены, ике тапкыр «Батырлык өчен» медале һәм башка медальләр белән бүләкләнә.

1948—1953 елларда — В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты студенты.

1964 елдан башлап — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни эштә. СССР Фәннәр академиясенең Дөнья культурасы тарихы буенча Гыйльми советның китапны комплекслап өйрәнү комиссиясе әгъзасы.

— Әбрар ага, язма, басма сүз — кешелек дөньясы уйлап чыгарган иң бөек могҗизаларның берсе. Бу могҗиза ничек, кайчан барлыкка килгән?

— Беренче китап XI йөздә Кытайда басылып чыга. 1445 елдан башлап бөтен Европага тарала.

— Әбрар ага, татар сүзләре белән беренче тапкыр басылып чыккан китаплар кайда чыккан һәм нинди хәрефләр белән?

— Татар телендә басылган беренче китап гарәп хәрефләре белән 1612 елда Лейпциг шәһәрендә чыга. Басма дүрт бүлектән тора. Беренче бүлеге татар телендә кулланылган гарәп язуын аңлатуга багышланган. Икенче бүлек — грамматика, өченче бүлек — синтаксис, дүртенче бүлек — татарча-латинча сүзлек. Бүгенге телебез белән чагыштырып карау өчен берничә мисал китерәм:

Әүвәл күреш, аннан белеш.
Коры янында яшь (ел) тә янар.

Күргәнегезчә, һәр сүз бүгенге кулланылышта бар.

Икенче бер кызыклы китап 1618 елны Львов шәһәрендә әрмән хәрефләре белән басылган. Бу китаплар — борынгы телебезне өйрәнү өчен гаять тә кыйммәтле чыганаклар. Әмма аларны әле татар китабы дип санау дөрес булмас иде.

— Ә безнең Идел буендагы бабаларыбыз нинди китаплар укыганнар соң?

— Татарларга басма китап XIV гасырдан бирле таныш. Алар арасында Италиядә, шәрык илләрендә чыккан китаплар киң таралган. Ләкин алар гарәпчә, фарсыча. Халык арасында шуңа күрә дә кулдан язылган китаплар бик тә күп булган. Әле хәзерге көнгә кадәр кулъязма китапларны галимнәр таба тора.

— Гафу итегез, Әбрар ага, сүзегезне бүләбез, безнең

укучылар, Миркасыйм Госманов белән очрашып, кульязма китап тарихы белән танышканнар иде.

— Бик изге эш. Бик әйбәт. Борынгы кулъязма китапларның кадерен белергә өйрәнүегез бик әйбәт. Инде Россия дәүләтенә килик. 1722 елда Петр I Иранга яу белән чыга. Аның гаскәрендә татарлар бик күп була. Патша «Манифест»ын тәрҗемә итү һәм бастыру эше чыгышы белән Кырым татары булган Димитрий Кантимергә тапшырыла. Шунысы кызыклы, 1722 елның 15 июлендә чыккан бу китап Әстерханда каекка урнаштырылган поход типографиясендә басыла. Без аны Россиядә чыккан беренче татар китабы, дибез.

Әбрар ага, без, бүгенге көн балалары, укуга, белем алуга беренче адымыбызны әлифбадан башлыйбыз. Ә беренче татар әлифбасы кайчан чыккан икән?

— Башта ук әйтеп куям: 1778 елда. Ягъни беренче татар әлифбасы чыкканга 210 ел тулды. Һәрберебездә дә бер сорау туарга мөмкин: «В. И. Ленин «халыклар төрмәсе» дип атаган патша Россиясе ничек моңа мөмкинлек биргән соң?» Тарихи вакыйгаларга килик. «Борынборыннардан татар һәм башка төрки телләрне практик яктан белү Киев һәм Мәскәү Русендә киң таралган була»,— дип яза күренекле рус галиме Н. К. Дмитриев.

Чыннан да, Мәскәү дәүләте яралган, тирә-яктагы халыклар белән аралашу өчен кешеләр кирәк була. Кем белә телләрне? Татар телен белгән кеше үзбәк, казакъ, кыргыз, азәрбайҗан, башкорт һәм башка дистәләгән төрки телләрдә сөйләшә белә. Татар рус телен белә, димәк, ул украин, белорус, болгар, поляк кебек дистәләгән славян халыклары белән аралаша ала. «Татарга тылмач кирәкми» дигән әйтем дә шуннан калган.

Академик В. В. Бартольд: «Россия телләр белүчеләргә мохтаҗлык сизмәде, моның нигезендә мәктәп-мәдрәсәләрдә гарәп, фарсы, төрек һәм башка телләрне өйрәнгән татар балалары ята иде»,— дип күрсәтеп үтә.

Әнә шул заман, Россиянең дәүләт буларак ныгу заманы, татар телен укытуны мөһим дип саный. Дәреслекләр, әлифбалар кирәк була. Шул ихтыяҗны искә алып, беренче басма татар әлифбасы нәшер ителә. Татарча исеме: «Әлиф-би». Авторы — Сәгыйть Хәлфин.

Бу китап әсәр буларак татар рухи культурасы җимеше хисапланса, китап буларак рус культурасы һәйкәле дә. Типографиядә аны ике халык кулга-кул эшләгән. Менә шулардан чыгып, бу китапны без ике бөек халыкның уртак хәзинәсе дип карыйбыз.

— Әбрар ага, ни өчен татар матбугатында 1905 елгы революциягә кадәр дөньяви китаплар шактый чыгарылса да, халкыбызның тормышы турындагылары бик аз булган? Югыйсә бит хәрефләр дә, типография дә җитәрлек.

— Ул типографияләр башта патша сүзен татар халкына җиткерү өчен булдырылса, соңыннан халык үзе өчен кирәкле хәбәрләрне дә сорый башлый. Мәктәп-мәдрәсәләр өчен дәреслекләр дә сорый башлый. 1845 елның августында патша әмер чыгара. Анда: «Казанда «Коръән» һәм башка ислам дине китапларын басу тысла»,— диелә. Ә бит гарәп хәрефе белән басылган һәрбер китап «Коръән» һәм ислам дине китаплары санала.

— Әбрар ага, ә зыялы кешеләребез бу хәл белән килешеп яшәгәннәрме?

— Иң беренче моңа рус халкының алдынгы зыялылары каршы чыккан. Татар китабын яклаучылар арасында бөек рус математигы, университетның ректоры Н. И. Лобачевскийның Петербургка җибәргән хат-мөрәҗәгатендә гыйбрәтле юллар бар: «...дини әсәрләр генә түгел, татар һәм төрек телендә әсәрләр өзлексез басылып килде... шуның өстенә, ул китапларны басу университет типографиясенә өзлексез табыш китереп торды, бу табыштан башка типография, гомумән, яши дә алмаган булыр иде».

Шушы хат нигезендә бик зур гауга куба. Нәһаять, татар китапларын басуны тыю экономик зыян икәнен аңлагач..., «Коръән» басарга рөхсәт бирелә. Россиянең изелгән халыкларына бишенче ел революциясе юл ача. Безнең Тукайлар, Әмирханнар, Рәмиләр күтәрелеп чыга. Аларның нигезендә нәкъ менә әле сөйләнгән беренче татар басма китаплары ята. Әгәр халыкның язмышын барлыйм, дисәң, аның китабы язмышын барла. Китап язмышы — халык язмышы ул.

Әңгәмәне *Мөдәррис Әгъләмов* алып барды

ЗАМАН ӘЛИФБАСЫН КЕМ ЯЗГАН?

Сәләй ага өстәлдәге кәгазьләрне, буяу, каләмнәрен бер читкәрәк җыеп куйгач, хәзер үзләренең методик кулланма әзерләү белән мәшгуль булуларын әйтте.

Шул чакта мин аның кулларына игътибар иттем. Тынгысыз бу куллар, эш сораган сыман, хәрәкәтләнергә. нәрсә дә булса кыйҗратырга әзер иделәр. Җир казыган, түтәл күтәргән, бакчада тирләп-пешеп эшләгәч, юынып өстәл артына утырган бакчачының куллары иде болар.

Әйе, алар икесе дә — бакчачы. Үстергән чәчәкләренең ничек аталуын белмим, әмма сабыйлар күңелендә шытачак орлыкларның исемнәре безгә яхшы таныш: Матурлык, Кешелеклелек, Гыйлем, Туган илгә мәхәббәт, Хезмәт сөючәнлек...

Рәмзия апа тәрәзә төбендәге гөлләргә аз-азлап су сибеп чыкты.

— Миңа көн дә язарга кирәк, шунсыз яши алмыйм. Балык сусыз яши алмаган кебек, миңа да бик тансык бу эш. Гомер буе шулай булды,— дип сөйли Сәләй Гататович.

Бу сүзләрне ул үзе турында гына түгел, Рәмзия Гыйлаҗевна хакында да әйтте. Аларның бергәләп, тир түгеп тапкан хезмәт нәтиҗәсе күз алдында. Ул — нәниләр әлифбасы. Әлифбаны төзү өч елга сузылган. Өч ел. Никадәр көч, тырышлык, туктаусыз эзләнү таләп иткәндер ул дәреслек — тау-тау китап укылган, йөзләрчә битләр каткат язылган, төзәтелгән, илһамлы мизгелләре дә, иҗат газабы да шунда, күңел төшенкелеге дә аларны читләтеп үтмәгән.

Бөек педагог В. Сухомлинский 1952 елның язында бер тәҗрибә үткәрә һәм 8 айдан соң 6 яшьлек балаларның барлык хәрефләрне таный, сүзләрне яза һәм укый белүләрен раслый. Шунда ук ул укытуның китап белән эш итүгә генә кайтып калуы нәтиҗәсендә, балаларның укырга-язарга авыр өйрәнүләре турында әйтә.

«Нәниләр әлифбасы» 6 яшьлек сабыйларның психологиясен, табигатен, үсеш үзенчәлекләрен күздә тотып язылган. «Баланың гомуми үсеше нигездә бер-берсенә органик бәйле эзлекле өч сызык буенча бара: бала күзәтә, уйлый һәм үзе эшләп карый,— диләр китап авторлары.— Укыту баланың акыл үсешеннән, тормышны танып-белү дәрәҗәсеннән алдарак барса һәм иртәгәге көнгә исәп тотса гына яхшы була ала».

Баланың теле «әннә, әттә» сүзләре белән ачылса, аның теленә икенче гомер бирүче «Әлифба» китабы була. «Әлифба»... Бишек җыры кебек тансык, йөрәк җылысы белән сугарылган, һәркемгә аңлаешлы, күз нуры белән иркәләнгән китап. Үзегезнең «әлифне таяк дип белә» башлаган чагыгызны искә төшерегез әле. Борын очыңа

бөрчек-бөрчек тир чыгарып дәфтәр битенә беренче хәрефләр сырлавыгызны хәтерләгез әле! Шуннан да кызык, истәлекле вакыт булдымы икән?

Алдымда — «Әлифба» китабы. Мин аны саклык белән кулыма алам. Ул миңа гаять кадерле, якын, чөнки балачагым белән кабат очраштырды. Беркатлы, самими, мәшәкать-борчусыз тоелган, «Әлифба» битләрендә сурәтләнгәнчә, уеннан башканы белмәгән бәхетле балачак... Мәктәп бусагасын атлап кергәнче генә без борчу-мәшәкатьсез, гамьсез күренгәнбез икән. Әнә 6 яшьлекләр «Әлифба»сы тышлыгындагы бала инде җитди, игътибарлы. Компьютер заманының «уены бетереп туган» малае шул ул.

Тәүге дәрес... Ленин бабай белән танышу. Ягымлы, нурлы күзләре белән ул безгә класс түреннән дә, «Әлифба»ның эчке битеннән дә карап тора.

Сабыйларга балалар бакчасыннан, ягъни кечәге уен дөньясыннан аерылып, белем дөньясына күчү кыен булмасын өчен алар (6 яшьлекләр) укыячак мәктәпләрдә уен, хәтта йокы бүлмәләре оештырылган. «Әлифба»ның алгы сәхифәләрендә балаларның шаян уеннарына урын бирү шуның белән дә аңлатыла.

«Әлифба» мәктәп реформасы таләпләреннән чыгып төзелгән. Хезмәт тәрбиясе — китап авторлары Сәләй Вагыйзов һәм Рәмзия Вәлитова моны һәрдаим истә тотып эш иткәннәр. Әнә балалар кош-корт ашата, ә «Әлифба»ның икенче бер сәхифәсендә аларны мастерскойда күрәбез, тагын берсендә нәниләр агач утырта, бакчада яшелчә уңышы җыя... Тукучы, игенче, икмәк пешерүче, кош-корт караучы, китапханәче, космонавт, чик сакчысы һөнәрләре белән таныштыру да шул максатны күздә тота.

Китапның «Уку», «Татар теле» бүлекләре сабыйның хәрефләрне танып, мөстәкыйль укый белүенә йөз тотып төзелгән. Әлеге бүлекләрнең шагыйрь Г. Тукай шигырьләре белән ачылуы мәгънәле. «И туган тел, и матур тел...» Әйе, вакыт узган саен сабыйның дөньяга карашы киңәя, күңел офыклары ялтыраганнан-яктыра бара. Аны шул чакта балалар әдәбиятының бишек җырын язган әдипләр — шагыйрь Г. Тукай, М. Җәлил, язучы Г. Ибраһимов иҗаты белән таныштыру бик тә урынлы. Хәзер ул, З. Нури шигырендәгечә:

Ник күккә йолдыз сибелгән?
Ник күкне зәңгәр, дибез?
Без елга дигән Иделдән
Ничек ясала диңгез? —

кебек, олыларны да уйга сала, кайчак аптырашта калдыра торган сораулар бирә торган яшьтә. «Әлифба» авторлары бу китапны төзегәндә дә үз принципларына тугры калганнар. Бала акылы күп белергә омтылучан, кызыксынучан. Аның акыл-зиһенен мәсьәләләрне катлауландыра барып кына үстереп була, диләр алар. Шуңа күрә «Әлифба»да табышмак, баш ваткыч сораулы мәсьәләләр ишле тупланган.

Китапның бизәлеше мактауга лаек. Рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов рәсемнәренең камиллеге, зәвык белән ясалуына игътибар итәсең. Р. Вәлитова һәм С. Вагыйзовның китап композициясен төптән уйлаулары күренә, һәр сәхифә бербөтен мәгънәне ача, билгеле бер максатка юнәлдерелгән. Мәсәлән, Г. Тукайның «Су анасы», «Шүрәле» поэмалары, А. Алишның «Сертотмас үрдәгә», халык әкиятләренә рәсемнәрнең текстсыз бирелүе урынлы. Шул рәсемнәргә карап нәниләр хикәяләр төзи ала, уку барышында рәссамнар әсәрне ныграк аңларга, тулы күзалларга булышачак. Өч данә язарга өйрәнү дәфтәре 6 яшьлекләр өчен шулай ук әйбәт кулланма булыр.

Бишек җырыдай ягымлы, матур, саммм, йөрәк җылысы, якты өметләр мул салынган китап иҗат ителгән.

Балаларны хәреф танырга, укырга, язарга өйрәтүдә элифба авторлары табышмаклар, җырлар, рәсемле кыска хикәяләр, баш ваткычлар, уеннар, шигырьләргә зур урын биргәннәр. Кайбер шигырьләрне Сәләй ага үзе язган. Шунысы кызыклы: заманында Самара өязендә чыккан «Колхозчы» газетасы, «Комбайн» журналының актив хәбәрчесе булган Сөләйманга «Чаян» журналында юмористик шигырьләр бастыручы кешенең «Сәләй» псевдонимы бик тә ошаган һәм Вагыйзов аны үзенә исем итеп алган.

Р. Вәлитова һәм С. Вагыйзовның укырга-язарга өйрәтү ысулы сүзнең жанлы әйтелешен өйрәнүгә корылган. Сөйләшкәндә әйтү берәмлеге булган иҗек уку һәм язу берәмлеге итеп тә алына. Балада башлангыч укуны формалаштыруның бөтен процессы сүзгә аваз анализы һәм синтез ясау нигезендә бара. «Нәниләр әлифба»сын төзегәндә авторлар илебез педагогика белеме, дәреслекләр төзүдә тупланган бай тәҗрибәдән мул файдаланганнар. Баксаң, татар әлифбасының да бер гасырлык тарихы бар икән. Грамотага өйрәтү алымнарын фәнни эшкәртүгә Г. Ибраһимов, М. Корбангалиев, Г. Сәйфуллин, М. Галләмова, Ф. Ибраһимов үз өлешләрен керткәннәр. Алар

янында Р. Вәлитова һәм С. Вагыйзовның Татарстан китап нәшриятында 24 енче тапкыр дөнья күргән Әлифбасы, «Туган тел», «Татар теле», «Рәсемле әлифба» һәм аларга методик кулланмалары, «Башлангыч мәктәптә татар теле методикасы» (1975 ел) дигән китабы аерым урын тота. Бу ике автор төзегән «Әлифба» китабының ТАССР Мәгариф министрлыгы уздырган конкурста икенче бүләкне алуы, ә инде иң яхшы китапка уздырылган Бөтенроссия конкурсында диплом белән бүләкләнүе турында әйтү урынлы.

Безгә калса, Рәмзия Гыйлмжевна һәм Сәләй Гататович белән сөйләшкән һәр кеше аларны кызыксындырган, дулкынландырган нәрсәләргә бөтен күңеле белән бирелмичә булдыра алмас иде. Алар үз фәннәренә кызыксыну уятып кына калмыйлар, ә бәлки эңгәмәдәшләрен күңелендәгеп әйтергә, уйланырга, фикер алышырга — ягъни, күмәк иҗат эшенә чакыралар. Гомерләре буе Арча педагогия училищесында укыткан бу кешеләрне мин үзенең романнарын хәтта типографиядә басылганда тикшереп-төзәткән Бальзакка охшаттым. Лев Толстой «Анна Каренина»сын 13 тапкыр күчереп язган, диләр. Сәләй ага: «Нәниләр әлифбасы»ның баштагы идеясе бүтәнчәрәк иде. Баштарак безнең әлифба менә болайрак буласы иде», дип бер төргәк кульязма чыгарды, аннары икенчесен, өченчесен... Инде китапның кульязмасы җиренә җиткерелеп танышылса да, кем әйтмешли, бу ике бал кортының, пар сыерчыкның туктаусыз эзләнүен, китапны камилләштерү, аның методикасын яхшы итеп язу өчен ару-талуны белмичә эшләүләрен күрергә була иде.

Сигезенче дистәне ваклаган, әмма теләсә кайсыбыз көнләшерлек итеп җиң сызганып эшләүче бу кешеләрнең хезмәт батырлыгының асылы «Гомуми белем мәктәбе һәм профессиональ мәктәп реформасының төп юнәлешләре» белән танышкач, тагын да ныграк ачыла төште. КПСС Үзәк Комитеты дәреслек төзүчеләр алдына «Югары идеялелек һәм фәннилек, аңлаешлылык һәм кыскалык, төгәллек, аныклык һәм җанлы итеп бәян итү, методик аппаратны камилләштерү» дигән таләпләр куйды. Бу — җаваплылыкның иң саллысы.

ТАССРның атказанган укытучылары, К. Д. Ушинский медаленә лаек булган, «Халык мәгарифе отличнигы» С. Вагыйзов, «Хезмәттәге батырлык өчен» медале кавалеры Р. Вәлитова төзегән «Нәниләр әлифбасы» бу яктан алганда да сабыйларга зур бүләк булыр дип ышаныйк.

— Кеше тәрбияләү аерым мизгелләрдән генә тормый,— дип сүзен дәвам итә Сәләй Гататович.— Бала һәрвакыт һәркайда тәрбияләнә. Әйтик, кемнеңдер якын туганы, дусты фаҗигага очраган. Аны тынычландырасың, юатасың. Бала моны күреп тора, күңеленә сала.

Бу сүзләрдән ирле-хатынлы укытучыларның Арча педагогия училищесында 30 елдан артык укыту дәверендә нинди принципларга таянуларын, тәрбия эшендә нәрсәгә кыйбла тотуларын беләсең.

— Дөньяда иң-иң матур ил

Ул — минем туган илем.

«Нәнилэр әлифбасы»ның соңгы битендәге бу юлларны укыгач, Сәләй ага болай ди:

— Укытучыдан ишеткәнне бала күңеленнән әйтә-әйтә яза. Баланы миенә тукып түгел, ә күңеленә сеңдереп кенә тәрбияләргә мөмкин.

Туган телгә, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү әлифбаның битеннән битенә күчеп, тоташ процесс булып дәвам итә. Җырда да «Ватан әлифбадагы рәсемнәрдән башлана» дип юкка гына җырланмый шул. Ә ул рәсемнәр безнең тормышыбызның, яшәү рәвешебезнең көзгесе...

Газинур Вәлиев

БӨРЕЛӘР УЯНГАНДА

Балалар таралышкач, мәктәп бушап калды. Моннан бер атна элек кенә шау-шу, ыгы-зыгы белән тулган тәнәфесләрдән соң бирсдә тирән тынлык урнашты. Бу тынлыкта үткәннәрне искә төшерә торган, уйландыра торган ниндидер бер моңсулык бар сыман. Ул моңсулык кара такта янына куелган акбур иссеннән, стенага кертеп эшләнгән шкафтан, өсләрендә, тиктормас малайларның кулъязмалары калган парталардан бөркелә шикелле.

Халидә Барыевна егерме бер ел инде шушы класста укыта. Димәк, җиде тапкыр шушында беренчеләр кабул ителгән. Җиде тапкыр беренче булып балаларга каләм тотарга, «әти», «әни», «туган тел», «Туган ил» дигән сүзләрне укырга, язарга өйрәткән. Һәр яңа кабул ителгән балалар белән өч ел гомер шушы класста узган... Ул алар-

ның һәммәсе өчен беренче укытучы булып язмышларына кереп калган.

Һәр бала үзе бер кабатланмас дөнья. Шуңа күрә укытучының күзе кайсы партага гына төшмәсен, яңадан-яңа истәлекләр баш калкыта, кабатланмас үз дөньялары белән самими карашлы балалар күз алдына килә.

Менә тагын бер уку елы узып китте. Халидә Барыевна өчен чыгарылыш елы. Укытучы класста берүзе. Айдар, Лилия, Ниязлар инде дүртенче класска киләчәк. Апалары аларда укуга, хезмәткә мәхәббәт уята алдымы соң? Күңелләрендәге матур шытымнарны күреп, үстереп җибәрә алдымы? Тәрбия эшендә хаталар җибәрмәдеме? Укытучы башында мең төрле сорау, ә аларга җавап әле әзер түгел. Аларга киләчәк җавап бирәчәк. Һәр бала үзе бер кабатланмас дөнья. Ул дөньяның үз җирлеге, үз кыйбласы, үз рухы... Һәркайсы өчен бертөрле алым ярамый. Шуңа күрә һәркайсының күңеленә алып бара торган дөрес юлны, бердәнбер юлны табарга кирәк... Дөресен әйткәндә, ялгышлар булып тора шул әле. Киемең иптәшләреңнеке төсле түгел, дип, баланы физкультура дәресенә кертмичә, борып җибәргән очраклар, бердәй җавапка төрле билге куюлар... Саный калсаң, азмыни? Телгә алып сөйләргә кечкенә булып тоелган шул «ялгышлар» кайчакта гомер буена онытылмыйлар.

Халидә Барыевнаны дусты Сәвия сөйләгән бер вакыйга тетрәндерде.

...Илленче елларның уртасында була бу хәл. Җиденчеләрнең чыгарылыш имтиханнары биреп йөргән чагы. Сугыштан соң җилкәне баскан хәерчелек балалар кыяфәтендә аеруча ачык чагыла: иске-москыдан юнәткән кием-салым... Әмма күңелләр күтәренке. Сәвия барлык сорауларга да ныклап әзерләнә. Әдәбият фәнен болай да ярата ул. Бу юлы да беренче булып билет алачак та, беренче булып җавап бирәчәк. Тик ни хикмәт, укытучысы Александра Алексеевна аңа башкалар җавап бирен бетергәч кенә билет алырга рөхсәт итә. Имтихан алучы икенче укытучы да чыгып китә. Менә шул чакны, Сәвия җавап бирергә теләк белдергәч, Александра Алексеевна йөзенә бәреп әйтә:

— Хәтерлисеңме, Сәвия, теге чакны... Александра Алексеевна кыйнады,— дип торганыңны.

Сәвия телсез кала. Хәтерли, әлбәттә, ник хәтерләмәсен! Бишенчедә укыйлар иде. Класска «кара» Хисами алып кергән күгәрчен өчен Мөгыйннең башын тактага

бәрде. Малай аңын югалтты. Класстагы шау-шуны ишетеп кергән мәктәп директоры:

— Нәрсә булды? — дип сорады.

— Александра Алексеевна Мөгыйнне башы белән тактага бәрде,— дип мышкылдады Сәвия.

Мөгыйннең әнисенә дә шул ук сүзләрне кабатлады...

Укытучысының бу кадәрле дә түбән җанлы булуын Сәвия гомер буе кичерә алмый.

Халидә Барыевнаның күз алдына әле быел гына өченчене тәмамлаган Алена килде. Уртадагы рәттә дүртенче партада утырды ул. Пионерга кергән чагын ул да укытучысына үпкәләп, рәнҗеп искә алмас микән? Шатлыгыннан бишсе урынга еларга туры килде бит аңа. Аларны пионерга алыр көн җиткәндә генә Халидә апалары авырып китте.

Пионерга лаеклы дип тапкан иптәшләрен укучылар үзләре тәкъдим итәләр, рекомендация язалар. Ә Аленага иптәшләре ул чакта рекомендация бирергә ашыкмады...

Пионерга керәсе көнне өченчеләр үзләре белән ер-яңа пионер галстуклары алып килделәр. Алена да галстук алып килде. Вожатый апасының класска керүен ул да түземсезләнеп көтте. Ишләп көтмәсен, укытучы апасы аңа, сине дә пионерга алырбыз, диде ич. Тырыш, диде. Тырышты Алена, әйткәнне тыңлады.

— Пионерга керүчеләр! Галстукларыгызны алып, пионер булмаганнарга кирә башлагыз! — диде вожатый кыз.

Алена да аларга иярде. Вожатый апасы аңа да галстук бәйләде. Шатлыкларыннан башлары күкнең җиденче түбәсенә җиткән балалар класска кергәч сикергәләшкән чакта, арадан берсе әйтеп салмасынмы:

— Алена, синең рекомендацияң юк иде бит!

— Салсын галстугын! Ул әле пионер булырга лаек түгел! — диде икенчесе.

Класс бер мәлгә тынып калды. Әле яңа гына йөзләрендә елмаю балкыган иптәшләренең карашлары усал, алар Аленаны теткәләп ташларга әзер торалар. Миһербан, шәфкать эзләп, Алена әле бер иптәшенә, әле икенче иптәшенә карады, тик аны яклаучы табылмады...

Рәхимсезлек, үчлеклелек менә каян сеңеп кала ул балала күңеленә?

Халидә Барыевна узган көннәргә кабат-кабат кайтып шул сорауга җавап эзли.

Узган атнада гына балалар инша язды.

— Аерым бер бит кәгазь алыгыз да, фамилияләрегезне куеп тормагыз,— диде апалары.— Иншаның темасы:

«Ачыктан-ачык сөйләшү». Һәрберегез үзе турында, әти-әнисе, иптәшләре турында күңелендә ни бар — шуны яза ала.

Кырык пар күздән уйчан караш таралды. Озак та үтмәде, ак кәгазь өстеннән каләмнәр йөгерде. Укытучы йомшак кына басып, парталар арасыннан үтте, балаларның эшенә күз салды.

— Костя, дорфа сүзенең дөрес язылышына игътибар ит әле,— диде ул аксыл чәчле, чандыр гына малай янына килеп баскач. Тегесе: «Ничек языла соң ул? — дигәндәй укытучысына күтәрелеп карады. Шул чакны аннан тәмәке исе килгәндәй булды. Малайның болай да аксыл йөзе кечерәеп, саргаеп киткән шикелле тоелды аңа. Бу балага гаиләсе җылысы тими. Әтисе эчә. Өйдә тавыш-гауга. Инде менә уллары тәмәке тарта башлаган. Сабый гына лабаса үзе... Моннан егерме-утыз ел элек берәр укучы тәмәке тартса, ул мәктәп өчен «чп» була торган иде. Хәзерге өлкән класс укучыларына элеккеге мәктәп тормышы турында сөйләсәң: «Заманасы бүтән!» — дип кенә җибәрәләр. Мәктәпне моннан ун-унбиш ел элек тәмамлаучылар укытучыларыннан качып, күрсәтмичә тартырга тырышалар иде. Хәзер әнә бәдрәфләр тәнәфес саен тәмәке төтене белән тула. Малайларныкында гына түгел, кызларныкында да шулай. Укытучыларның күбесе моны күрмәмешкә салына.

Халидә Барыевна уйларына уралып, балаларның язмаларына күз салгалап кабат парталар арасыннан үтте.

Костя исә: «Минем әти нишләп болай дорфа, нишләп көндә эчә икән?» — дип бер генә җөмлә язган да уйга калган. Малай үз соравына үзе җавап эзли...

— Костя, тәмәкеңне ташларга кирәк бит.— Пышылдап кына әйтелгән шушы сүзләр малайны сискәндереп җибәрде. Колак яфракларына кадәр кызарды. Гаиләдә гел кычкырыш, талаш, тупас сүз ишетергә күнеккән Костя йомшак мөгамәлә каршында югалып калды.

— Ярар,— дип башын иде ул.

«Сүзендә торыр микән,— дип уйлады укытучы.— Биргән вәгъдәсен үтәрдәй көч табар микән?»

Һәрбер бала үзе бер дөнья. Ул дөнья эчендә һәркайсы күп билгесезле, катлаулы әллә ничә мәсьәлә. Әнә шуларның барысын да үз чорында хәл итә бару, күңелләрдә туган аңлашылмаучылыкларга, сорауларга үз вакытында җавап таба бару өчен бала гомеренең һәр этабында аңа зирәк акыллы иптәш, эчкерсез дус кирәк. Ярый ла әти-әниләре ярдәм итәрлек булсалар. Халидә Барыевнаның

күз алдына үз эниссе килеп төште. Әтисез үстеләр алар. Өч малай, бер кыз. Халидә төпчеге. Әтисен хәтерләми ул. Барый ага сугышка киткәндә аңа бер яшь тә тулмаган була әле. Әниләре Кәримә апа берьялгызы тәрбияли дүрт баланы. Гап-гади авыл хатыны гына булса да бик зирәк, бик акыллы булган икән аларның әниләре. Йортта һәр баланың үз вазифасы, үз эше бар иде. Һәркем тормыш алып баруда үзен җаваплы тоя. Малайлар печәнен, утынын әзерли. Кызларга өй җыештыру, кер юу кебек эшләр төшә. Әле барысы да әниләренә кыр эшләрендә ярдәм итәргә дә баралар балалар. Хезмәт яратып үсәләр. Ә хәзерге балалар турында алай әйтә алабызмы соң? Кызганычка каршы, юк, әйтә алмыйбыз. Халидә Барыевна күңеленнән генә менә дистәләгән мисаллар уйлый. Балаларыннан элек, хәзер күп кенә ата-аналарның үзләрен эшкә өйрәтергә кирәк.

Реформа, реформа дип тә ничә ел эшлибез инде. Менә, тик әлеге реформа мәктәпкә нинди үзгәрешләр кертте соң? Бердәнбер үзгәреш — укытучыларның хезмәт хакы күтәрелү булгандыр, мөгаен. Мең ярым, ике мең укучыга исәпләнгән кысан мәктәпләр. Балалар берсен-берсе белми, танымый. Бер кабинеттан икенчесенә күчкәндә коридорларда этеш-төртеш, тавыш... Кырык биш минут буе киеренке хәлдә акыл хезмәтендә булган бала тәнәфестә бераз хәрәкәтләнсен, уйнасын иде дә бит... Кая инде ул андый урыннар безнең мәктәпләрдә?.. Казан мәктәпләренең кайсысына гына керсәң дә бер үк күренеш: һәммәсендә бер кечкенә спорт залы. Бала-чага атнага бер тапкыр физкультура дәресендә шул залга керү бәхетенә ирешә. Монда тагын фәкыйрьлек: спорт инвентаре юк, хәтта чаңгыларга кытлык — бөтенен әйтеп тә торасы түгел. Әнә шул, әле үз-үзләрен дә әзерләп йөри алмый торган башлангыч класс укучылары, дәресләргә өйдән чаңгы күтәреп йөрергә мәҗбүрләр. Бу яктан караганда авыл укучылары шәһәр балаларыннан бәхетлерәк шикелле. Ни дисәң дә, анда балалар аз, чаңгылар җитә... Монда тагын бер өстенлек — һәр авылда клуб бар. Балалар өчен әллә нихәтле түгәрәкләр ачып җибәрергә була дигән сүз. Ә шәһәрдә!? Клуб, культура йортлары дигәнең районына бер яки ике генә туры килә. Исәпләп карасаң, ничә бала урамда кала икән?..

Халидә Барыевна урыныннан кузгалып, балаларның класс шкафындагы дәфтәрләрен кулына алды. Әле кайчан гына үз кызы Лилия дә башлангычта гына иде бит. Мәктәпне бик яхшы билгеләренә тәмамлап институтка

кердс. Хәзер инде яшь белгеч... И, бу гомер дигәнең... Ире Рәшит белән бергә акыллы кыз, үзләренә лаеклы бала тәрбияләделәр.

Лилиянең балачагын хәтерләткән дәфтәрләрне берәм-берәм барлап, иң өстәге киштәгә урнаштыра башлады. Дима, Марат, Светлана, Петя дәфтәрләре... Кулына Петя Гавриловның дәфтәрен алгач, укытучы үзалдына елмаеп куйды. Укуның соңгы көнендә апалары балалар белән озаклап сөйләшеп утырган иде.

— Сезне инде башка укытучылар кулына тапшырсам да, сез барыбер минекеләр,— диде ул.— Унынчыны тәмамлагач та, эшли башлагач та минеке. Мин гомерем буе сезнең шатлыгыгызга шатланып, сезгә кайгы килсә, кайгырып яшәячәкмен. Һәммәгез дә миңа бик якын, кадерле. Һәммәгезне дә бик яратам,— дигән иде. Укытучы сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, Петя сикереп тә торды.

— Мине дә яратасызмы, Халидә Барыевна?

— Сине дә яратам, Петя. Син дә минем укучым бит.

...Аларның беренчедә укый гына башлаган чаклары иде. Петяның үзенең көчсезләрне кимсетүе, кыерсытуы билгеле булды. Тик торган кызларга тибеп китү яки төртеп егу аның өчен берни түгел икән. Укытучы аның белән ничәмә-ничә тапкыр сөйләшкәч, берсендә әйтеп куйды:

— Сугыш чукмарын бер кеше дә яратмый.

Ул вакыттан соң малай күп үзгәрде инде, яхшы якка үзгәрде, укытучысының сүзен дә онытмаган.

Халидә Барыевнаның эш алымы нигезендә бала күңелендә игелек, яхшылык хисләре яту ята. Аның өчен һәрбер бала бертигез, һәммәсе шәхес. Ә бала гаделлекне тиз тоя.

Казандагы 111 нче мәктәп укытучысы Халидә Барыевна Кадыйрова быел тагын беренчеләр кабул итте. Аның йөрәгендә тагын никадәр борчылулар, уйланулар. сораулар кабатланачак. Һәрбер бала үзе бер дөнья. Аның үз шатлыгы, үз кайгысы. Укытучы әнә шул дөньяның матур, кешелекле, игелекле, шәфкатьле булуына ирешергә тиеш. Кешенең күңел дөньясын баскычтан баскычка атлый-атлый үскә, югарыга күтәрү — чиксез четерекле, авыр хезмәт.

Сәйдә Зыятдинова

МЕҢ РӘХМӘТ СЕЗГӘ

Аның идеалы — Антон Семенович Макаренко, ә өстәл китабы — шушы күренекле совет педогогының сайланма әсәрләре. Үсмер чагында «Педагогик поэма», «Башнялар-да флаглар»ны яратып укыды. Тәтеш педагогия училищесына алып китүче хыялын да шул әсәрләр канатландырган иде бит. Ә анда укыганда чын педагог образы итеп география укытучысы Касыйм Шәрәпович Юнысовны кабул итте ул. Дәресләре — могҗизалы җиһан серләре иде аның. Ә өстәлләр арасыннан йөрешләре, хәрәкәтләре... Әйтерсең ул гадәти кеше генә түгел, табигатьтән укытучы булып яралган изге бер җан иясе.

«Баренц дингезендәге Кильдин утравында булган идем. Анда бит җир йөзендә берդәнбер биш катлы күл бар...» Класс бүлмәсе тып-тын кала. Укытучы түш кесәсеннән пөхтә итеп төрелгән кулъяулыгын алып маңгаен сыпыра да аны әкрен генә төреп яңадан кесәсенә сала. Ә класс тын да алмый аның хәрәкәтен күзәтә, биш катлы күлнең соңгы катындагы кар сыман салкын, кристаллдай саф суда кулын-битен юуы турында сөйләвен көтә. Укытучысының тәфсилле сүзеннән, кулларыннан, битләреннән әнә шул сихри күлнең салкынча җиле йөгереп үткәндәй була. Хыялый яшьлеккә тагын ни кирәк соң?! Укып чыгып, тизрәк дөнья гизәргә ашкына ул.

Сәяхәткә чыгып китүләре алай җиңел генә түгел икән шул. Укытучыларының Баренц диңгезендә булмаганын соңыннан аңладылар 40 нчы ел яшьләре. Әмма һәркайсы аның хәйләле кыйссалары белән сихерләнеп өлгергәннәр иде инде. Егетләр иңнәренә корал салып ил өчен утка керделәр. Кызларга ятимлектән, сугыш афәтләреннән сулган сабыйлар белән эшләргә туры килде. Әмма беркемнең дә училищеда кабынган өмете, хыялы сүрелмәде.

Р. Ярмөхәммәтов, «Спартак» колхозы председателе:

— Малай чак, үсмер елларда аңа охшарга тырышу хисе көчле иде. Безнең шуклыкларны тыныч кына уздырып, сабыр киңәшләре белән битне кызарткан чаклары әле дә истә. Икенче тапкыр тәртипсезләнеп, аның каршына басып буламы?! Беркатлы гына булса да, укытучыларның теңкәсенә тия торган усал шаярулардан шулай биздерде ул мине.

Гомеренең утыз елын Апас урта мәктәбендә география укытты Әнвәр Каюмович. Шуның 24 ендә мәктәп директоры да. Район үзәгендә укытучылар коллективын җи-

тәкләү җиңел түгел. Район җитәкчеләре алышыну, яңа белгечләр килү күп очракта директорга яңа мәшәкатьләр өсти. Гаиләсе белән күчеп килүче-китүченең дәресләрен җайга сал. Гомер буе шушы мәктәптә укыткан хөрмәтле укытучыны да рәнҗетмә, килүченең дә хәтере калмасын. Ә бит коллектив кечкенә түгел, 50 педагог. Һәркайсында бер холык. Йомыш-гозерләрен үтә, программага да зыян килмәсен. Монда инде Әнвәр Каюмовичка сабырлыгы һәм аннан да бигрәк кешеләргә олы ышанычы ярдәмгә килә.

Р. Коновалова, башлангыч класс укытучысы:

— Әле дә хәтеремдә: Минзәлә педучилищесын тәмамлап эшкә килгән көнем, Апастан шактый читтәге мәктәпкә эшкә җибәрергә җыеналар. Ә минем үзәктә каласым килә. Шунда мине Әнвәр Каюмович үз мәктәбенә сорап алды. Квартирага урнаштырды. Интернаттан урын-җир әйберләренә хәтле китертте. Һәрбер яшь укытучы турында шулай кайгырта ул.

Ә аның дәресләргә ясаган анализы үзе бер методик җыентык. Уңай якларының санап кына калмый, аларны үстерү-киңәйтү юлларын да аңлатып бирә.

Әнвәр Каюмовичның урта мәктәп директоры булып эшли башлаган еллары. Балаларның физик хезмәткә мөнәсәбәтен, эшкә ни дәрәҗәдә осталыгын өйрәнә. Авылда үскәч, әлбәттә, күбесе тырышалар, беренчедән эштән курыкмыйлар. Әмма арада көрәк тота белмәүчеләр дә бар. Болары инде гаиләдә иркә үскән балалар. Аларны ничек «дәваларга?» Бары тик хезмәт, хезмәт аша гына, дигән фикер туа директор уенда. Мәктәп яны участогында укучылар ул елларда бишенче класстан гына эшләргә тиеш булалар. Ә директор тәвәккәлләп, бөтен җаваплылыкны үз өстенә алып, җиләк-җимеш, яшелчә үстерү эшенә беренче классны тәмамлагач ук өйрәтә башлауны традициягә кертә. Һәм ялгышмый. Бүгенге хезмәт тәрбиясе программасы нәкъ шул нигезгә корылган да.

Марсель Сафиуллин, Апастагы авыл профессиональ-техник училищесы укытучысы:

— 1975 елда оешты безнең училище. Беренчедән база юк иде. Апас урта мәктәбе яңа бинага күчте, ә без искесенә. Бөтен теоретик һәм практик дәресләрне мәктәп классларында башлап җибәрдек.

— Профтехучилищеның техник базасы мәктәпнекенә караганда тизрәк һәм баерак тупланачагы билгеле ич.

Кичә без аларны ишекләрне киң ачып каршылаганбыз икән, аның каравы, бүген укучыларга авыл хуҗалыгы нигезләрен училищеның машина-трактор паркында тирән итеп өйрәтүгә юл салдык,— соңыннан директор шулай дип җиңел генә җавап бирә. Ә бит ул көннәрдә аңа училище үтенечен кире кагарлык сәбәпләр бар иде. Яңа мәктәп искесенә исәп тотып төзелгән иде. Шуңа күрә укулар әле дә ике сменада алып барыла. Бу очракта да директор Юнысов тормышның социаль проблемаларын хәл итә, перспективаны күрә белүен исбатлады.

Хиссез, тойгысыз бала буламыни? Тик аның әнә шул нәфис кылларын тибрәтә торган мизгелен, темасын гына сайлый бел.

Р.ны чит тел укытучысы дәресеннән куып чыгара. Нәкъ шушы вакыт директор коридордан үтеп бара. Дәрестә туган конфликт аңа һичшиксез килеп җитәчәген белә ул. Р.га үз артыннан иярергә куша. Билгеле, нинди генә усаллыклар эшләргә кыюлыгы җитсә дә, директор бүлмәсенә кергәндә шүрләп кала малай. Каршына бастыруга, күзеннән күрә педагог моны. Һәм сүзне дәрестән түгел, ә Р.га задание бирүдән башлый. Күңелсез сөйләшүне көткән укучыга класс почмагы өчен рейкалардан планшет ясау мең мәртәбә җинелрәк тоела.

Нурия Зиатдинова, почта бүлеге хезмәткәре:

— Улларым бик яшьли әтисез калдылар. Өчесендә өч холык. Әти тәрбиясенә бик мохтаҗ чакларында Әнвәр Каюмович янына киңәш сорап килә идем. Турыдан-туры бәйләнешең булмаганда, кешене белмисең бит. Мин директорны бик җитдидер дип уйлый идем. Балалар белән директор бүлмәсендә бер-ике сөйләшкәч үк, аннан да олы җанлы, кече күңелле кеше юктыр дигән фикердә калдым.

Болытлы, яңгырлы көннәр еш булса да, көз күңелләргә канат куйган, рухыбызга илһам биргән чак. Сөенәсөенә хезмәтебез җимешләрен җыйган чак. Алдагысы өчен татлы план корган чак. Юкка гына олыгайган кешегә без, гомер көзенә аяк баскан, дип әйтәбез икән ич. Төз, мәһабәт гәүдәле, җиңел адымнар белән мәктәпкә ашыгучы Әнвәр абый Юнысовка шулай дия аласыңмы? Ә кичләрен ул мелиораторлар янына ашыга. Тирән белемле пропагандист авыл хезмәтчәннәре күңеленә партия һәм дәүләтебез куйган бурычларны тормышка ашыруның илебез экономикасында, тынычлык политикасында нинди көч чыганагы икәнлеген аңлата.

Әни кеше авызыннан:

— Улым Дәвеш мәктәбендә сигезенче классны тәмамлагач, кая урнаштырыйм икән дип хәсрәткә калдым. Чөнки укуы да әйбәт түгел, ә тәртибе тагын да борчулы иде. Шунда киңәш бирделәр: малаеңны кеше итәсең килсә, тугызга Апас урта мәктәбенә илт, диделәр. Директор Юнысовка үзем кереп малаемның хәлләрен сөйләдем. Авырсынмады. Аны үз контроленә алырга вәгъдә итте. Улымның тәртибе көннән-көн әйбәтләнде. Инде гаиләсе, балалары бар. Колхозда иң алдынгы тракторчы.

Мәктәп, укыту-тәрбия эше турында сүз чыкканда директор Рәхимә Гыйниятовна Сибгатуллина, Лидия Викторовна Устинова кебек чал чәчле өлкәннәрдән эстафетаны ышанычлы кабул итүче Эльмира Гыймадиева, Гөлшат Нуруллина һәм башка яшь укытучыларны зур горурлык белән санап китә Әнвәр Каюмович. Мөгаен, бу тыйнак һәм житди, зирәк фикерле педагогның лаеклы юлдашларын да, шәкертләрен дә санап бетерерлек түгелдер инде хәзер.

...Алар еракларга таралган. Тик күңелләре, киңәшле уйлары һаман остазлары белән янәшә икән. Бәйрәмнәр якынлашуга иң җылы, иң изге теләкләр булып Әнвәр абыйларына аларның хатлары, котлаулары юл ала. Менә бүген дә тормыш иптәше Әминә апа аның кайтуына өстәлгә кочагы белән котлау хатлары алып кереп куйды. Инде лаеклы ялга чыккач та җаны тынмый үзенең. Һаман мәктәп, һаман балалар...

Я. Абдулкадыйрова

БАРЫСЫ ДА АНЫҢ ТУРЫНДА

Үзенең бер генә туганы да булмаган аның...

Ул әби белән бабайның бердәнбер кызы булып үскән, иртә атадан калган, әби дә, бу авылда җанына урын таба алмыйча, туган якларына китеп барган. (Әби үзе Шөгер якларыннан булган.) Һәм Сабай авылында әни бөтенләй чит кешеләр кулында торып калган. Соңыннан әби, Ленинградка урнашып, әнине алырга кайткан. Укымышлы мишәр әбиебез аны бу кечкенә авылда калдырырга теләмәгән. Әнинең тавышы бик матур булган, әби аны Ленинградта җырчылыкка укырга урнаштырырга уйлаган. Ләкин әнинең авылдан китәсе килмәгән, әллә күз күрмәгән җирләргә чыгып китәргә курыккан, әллә башка берәр сәбәбе булган, әни авылда калган. 16 яшеннән әтигә кияүгә чыгып, Саба районының Сабай авылында тормыш итә башлаганнар. Шушы авылда әни безне — 10 баласын табып үстергән, шушы авыл зиратына әбине җирләгәннәр (әби барыбер Ленинградта да, Шөгер якларында да кала алмаган — барыбер кызы янына кайтып күзен йомган). Әни исә һаман шушы авылда яши. Әти белән икесе генә тормыш итеп яткан көннәре.

Мин хөкүмәтебезнең кайбер акыллы, зирәк карарларына таң калам. Ил өчен яуда катнашкан солдатлар, бөтен гомерләрен хезмәткә багышлаган кешеләр белән бергә аналарга да Герой исеме бирелә. Хөкүмәтебезнең аналарга карата иң зур игътибары, иң олы бүләге бит бу исем.

Әнигә «Герой-ана» ордены тапшырган көнне мин көтүдә идем. (Әти сугыштан сыңар кул белән кайткан, һәм безгә, ун балага, җәйләрен көтү көтеп үсәргә туры килде.) Тананаларны фермага ябып өйгә кайтсам — өй тулы кеше. Өстәлдә самавыр гөжләп утыра. Әни сандыктан яңа күлмәген алып кигән. Майда гына пешкән тәмле ризык исләре килә. Рәхәтлектән,ниндидер шатлыктан, җиңеллектән елап җибәрермен кебек. Көне буе кырда йөреп, ут булып янган бит-кулларымны салкын су белән юам да өстәл янына килеп утырам. Әле яңа тәпи баскан сеңлем Гөлзада аякларыма килеп сарыла. Кулында — ялтырап торган әллә нинди әйбер. Мин аны башта брошкадыр дип, аннан әтинең берәр медаледер дип белдем. Гөлзада, беркемгә дә күрсәтмәс, бирмәс өчен, ул әйберне учына яшерде дә олы якка үрмәләде. Әни аны җиңел генә күтәреп алды да: «Кая, кызым, апаңа да күрсәт инде тәтине»,— дип, юмалый-юмалый ул әйберне кулыннан алды...

Алтынны мин иң беренче мәртәбә шул вакытта күрдем. Алтын безнең йортка уныччы бала тәпи баскач кына килеп керде. Анда да ул безгә алтын буларак түгел, әнигә бирелгән орден буларак кына кадерле иде. Бу йортта гомер буе бәхет байлык, алтын белән түгел, балалар белән, аларның сәламәтлеге, акылы белән үлчәнде.

Яз. Күк йөзе зәп-зәңгәр. Кояш нәкъ безнең өй турында. Әни белән тәрәзә юабыз. Әни урам якта, мин өйдә. Юган саен әнинең йөзе ачыграк, матуррак күренә. Ул миңа рамдагы рәсем кебек тоела: кап-кара кашлар, апак маңгай, ап-ак тешләр. Тәрәзә аша көлеп миңа карап тора. Рәсемгә зәңгәр күк тә, кояш та сыйган. Тирәсен ямь-яшел нәни яфраклар каймалап алган.

Бу — минем хәтеремдәге язгы сурәт.

Әти-әни үзләре дүрт класс белемле генә булсалар да, гомер буе безгә укырга куштылар. Бигрәк тә әни. Телендә гел бер сүз була иде: «Балам, укыгыз». Безнең авылда башлангыч мәктәп кенә, ул вакытта җидееллык мәктәп күрше Олы Шынар авылында, урта мәктәп — район үзәге Сабада гына иде. (Хәзер инде унъеллык мәктәп Шыңарда да ачылды.) Иртә белән 6 дан ук мәктәпкә җыена башлыйбыз. Әни мичтән киптерергә куйган итекләрне бушата — әллә 10—15 итек чыкты инде мичтән? Идән уртасындагы өемнән һәркем үзенекен табып ала — кайсының астына олтан салган, кайсының артына, әчләренә әле буталмасын өчен тамгалар да тегелгән. Әни барыбызны

да ашатып, киендереп, мәктәпкә чыгарып җибәрә. Ераграк бара торганнар иртәрәк чыгып китә, авылдагылар — соңрак. Төштән соң берәм-берәм тагы җыелышна башлыйбыз. Без кайтканда әни өйдә күренмәсә, барыбыз да: «Әни кайда?» — дип сорыйбыз. Әни гел· өйдә булырга тиеш кебек тоела иде безгә. Әни өйдә булмаса, без ашый да алмый идек. Әллә нишләп рәте булмый иде ул ашауның, ямь булмый иде. Почмактан-почмакка бәрелеп-сугылып йөри идек тә ачлы-туклы барып ята идек. Мондый көннәр әни больницада ятканда еш була иде. Ә әни больницаларда күп ятты — Сабада да, Казанда да. Безнең барыбызны да сау-сәламәт итеп үстердe, ә үзе кырык яше тулганда ук бөкте, кечерәеп калды. Менә бит ул тормышның законнары нинди кырыс — синнән барысын да суырып ала да башкаларга — балаларына тарата. Шулай дисәң: «Әни, без бигрәк күп булганбыз инде, без синең сәламәтлегеңне бетергәнбез», дисәң,— әнинең җавабы гел бер булыр. «Ялгыз кеше дә картая,— ди ул.— Ялгыз кеше дә чирли. Әле шул кечкенә чакларыгызны сагынам. Бөтенегез янымда идегез ичмасам...» Шулай дип әйтә дә елап җибәрә. Олыгайган саен әни ешрак елый. Ә элек мин аның елаганын бер дә хәтерләмим. Ул минем хәтеремдә гел ап-ак тешләрен ялтыратып, елмаеп тора. Чәче чем-кара. Тигез итеп, ыскиткеч матур итеп уртадан ачылган. Үзләре шундый шомалар, озыннар. Минем андый чәчләрне дөньяда башка беркемдә дә күргәнем булмады.

Җәй. Печән өсте. Арбага төялеп, болынга печән җыярга төшеп барабыз. Барыбызның да кулында ап-ак тырмалар. Аларны өскә каратып тотканбыз. Барыбызның да өстендә чәчәкле матур күлмәкләр. Әни безнең уртабызда. Аның да өстендә бик матур бизәкле күлмәк. Ап-ак яулыгын артка чөеп бәйләгән. Без, арба дыңгырдавын да уздырып, кычкырып җырлыйбыз. Әни елмаеп тыңлап бара. Без аның саен ныграк тырышабыз.

Балачакның ул бәхетле авазларын меңләгән чакрымнар, таш стеналар аша мин әле бүген дә ишетәм. Болын. Әни. Без...

Бу — минем хәтеремдәге җәйге сурәт.

Әни бер дә зарланмый иде. Аның гадәте — булганына гел шөкрана итү иде. Мин аның бер дә чәүчәләкләнеп, бәргәләнеп, ах-вах килеп йөргәнен хәтерләмим. Ә борчылырлык чаклары булгандыр инде, булгандыр. Ун бала бит! Барыбыз да диярлек, унышар сум акча алып, бер

чемодан китап төяп, берәм-берәм Казан ягына таба чыгып китә башладык. Хәзер безнең балаларыбыз, әти-әниләре җитәкләмәсә, урам аша да чыга белмиләр. Ә без, ялгыз башыбыз, коры тәвәккәллек, хыял белән әллә кайда, урманнар артында булырга тиешле Казан каласына чыгып киттек. Үзенең берәрсә белән дә ярдәм итә алмасына чарасызланып бетеренгәндер әни ул көннәрдә. Ул теләр юкка гына кослмагандыр, ул йөрәк юкка гына туктыйм-туктыйм дип тормагандыр.

Казан университетын әни иң беренче мәртәбә республика больницасында ятканда күрә. Шушында алты кызым укыр дип уйламагандыр инде ул. Аннан соң балалар аша шушы университет белән аның күпме гомере бәйләнде бит. Иң башта, унбер класс бетереп, Тәслимә чыгып китте. Әле ул вакытта Сабай авылыннан югары уку йортына беркемнең дә барганы юк иде. Инде авылда: «Сәлимә кызлары укырга киткән, ай-һай, керә алырлармы икән?» — дип сөйли дә башлаганнар иде. (Ул вакытта мин дә, очучы булам дип, сигез классны «бишле»кә генә тәмамлап, Тәслимә апама ияреп, Казанга чыгып киткән идем. Ләкин алай тиз генә очучы булып булмый икән әле. Сабага кайтып ун класс бетерергә, эшләргә, аннан Казан театр училищесының режиссерлык бүлеген тәмамларга туры килде. Университетка да соңыннан гына әйләнеп кайтылды.)

Тәслимә апам беренче барган елында ук университетка керде. Беренчә елдан, китап белән шыплап тулган чемоданын күтәреп, шушында ук сеңлебез Нурания килеп җитте. Нурания төсе-кыяфәте белән дә, көләчлеге, моңлы матур тавышы белән дә әнигә охшаган. Безне күргәндә елап җибәрүләренә кадәр әнинеке кебек. Әнине иң нык яратучы да улдыр дип уйлыйм мин. Университетны тәмамлагач, ул ире, балалары белән Зәй шәһәрендә яши башлады. Менә шул Нурания, кар яуса да, боз яуса да, бер баласын кулына күтәреп, берсен җилкәсенә утыртып, дөнья хәтле күчтәнәчен алып, Зәйдән Казаннар аша урый-урый, мең газап белән елына берничә тапкыр әниләр янына кайтып килә. Әле без Казанда торып та авылга кайтырга чак көч, вакыт табабыз, балалар дибез, эш дибез. Ә ул жаен таба да гел әниләр янына кайтырга ашыга. Үзе гел елмая. Бер дә зарланмый. Тик юл уңае туры килеп, Зәйгә, Нурания янына кереп чыкканда, ул, кулына гармунын ала да, башын гармун өстенә кыңгыр салып, елый-елый уйнап җибәрә. Әнине сагына, безне сагына инде ул. Әйтми генә, түзә генә.

Аннан университетка ике игезәк сеңлебез килде. Без аларны гел шулай дип йөртәбез инде. Рузалия белән Гүзәлия сигезенче, тугызынчы балалар. Алары читтән торып укыдылар. Әни читтән торып укучы студентларның да графигын үзләштерде. Кыш бер, җәй бер, аларның сессия, имтихан вакытларында ут йотты. Казан ягына карап, һаман теләк теләде, теләк теләде. Әнә шулай итеп, әни безнең белән бергә укыды, бергә имтиханнар бирде, бергә сөенде, бергә кайгырды.

Көз. Томанлы иртә. Өй каршында үскән өянке, тупыллардан шаулап яфрак коела. Шәрә ботакларны каргалар сырып алган. Шыгырдап капка ачылган тавышка алар салмак кына күтәреләләр дә ераграк агачка күчеп утыралар.

Капкадан, кулына чемодан тотып, тагы беребез чыга. Ничәнчебез бу! Бишенчебезме, җиденчебез, әллә унынчыбыз укмы? Аның артыннан йөгерә-атлый әни килә. Аягына киярге дә оныткан, оекчан гына сап-сары яфраклар өстеннән йөгерә. Чат башына хәтле шулай килә дә, коймага сөялеп, ялгыз басып кала. Бала борылмый, борылса күзендәге яшьләрен әнисе күреп алыр дип курка. Мең төрле хәвеф, өмет, билгесезлек белгән томан арасына — киләчәгенә китеп югала.

Кайсыбыз бу! Бишенчебезме, җиденчебез, әллә унынчыбыз укмы?

Бу — минем хәтеремдәге көзге сурәт.

Иң нык борчылганы, мөгаен, төпчегебез Гөлзада (шул алтын орденны беркемгә дә бирмичә елаган кызыбыз) университетка кергәндә булгандыр. Гөлзада башкалар кебек татар теле бүлегенә килмәде, журналистиканы сайлады. Әни инде, безнең сөйләүләр буенча, татар теле бүлегенең укытучыларын, нинди фәннәрдән ничегрәк сорашуларын ун ел буена үзе дә ятлап бетергән иде. Гөлзада журналистика бүлегенә барам, дигәч, бөтенләй куркуга төште. Әллә нәрсәләр нәзер итеп бетерде, ябыкты, ашаудан калды. Гөлзада инде менә укырга да керде, инде университетны тәмамлады, ә әнинең телендә әле һаман Гөлзада укырга керән ел. Ул хәзер еллар санын да Тәслимә укып бетергән ел, Нурания укырга кергән ел, игезәкләр барган ел, Гөлзада укырга кергән ел, дип, үзенчә барлый, үзенчә саный.

Ә хәзер кайвакытта әнидән сәер-сәер сүзләр дә чыккалап куя. «Нишләп укы дип әйттем икән,— ди ул уйла-

нып утыра-утыра да.— Укымасагыз, ичмасам, яныбызда калыр идегез...»

Мин андый вакытларда ни әйтергә дә белмим. Укымаган кешеләр дә китә бит авылдан, дип, исбатлый да алмыйм. Чөнки әнинең сүзләрендә дә дөреслек бар бит. Бөтенебез таралдык та беттек. Гаилә тормышына уралып, авылдан, төп нигездән ерагайдык. Аларның да шәһәргә күченеп киләсе килми. Әле ярый олы апабыз Вәсилә, Шыңар авылы егетенә кияүгә чыгып, шул якта калды. Әнигә ул иптәш хәзер.

Энем Нурулла Ливиягә эшкә киткәч (ул — тәзүче), әни тагы әчтән генә сызды. Әти белән телевизор каршыннан китмәделәр. Ливия турында берәр сүз әйтмәсләр микән, Нурулла күренмәсме икән дип, телевизор сүнгәнче каршында утырдылар. Аннан әти газеталардан эзләнә башлый. Әни сизенә инде, сизенә — кырык елдан артык бергә торгач, ул әтинең төрле рәвешен күргән. Энемнән хат килгәнче шулай өйнең икесе ике башында шәүлә кебек йөриләр. Хат килгәч, инде аның һәр хәрефен, һәр нокталарын, һәр җөмләсен җентекли-җентекли башта бергә укыйлар, аннан бер-берсеннән яшерә-яшерә тагын әллә ничә тапкыр укып чыгалар.

Нурулла, җиде кыз арасында үскән бердәнбер малай булгангамы (ике олы абый — Нургали белән Альберт инде без үскәндә үк читкә киткәннәр иде), әти-әни Нурулла өчен бигрәк тә үлеп торалар. Нурулла үзе дә авылга кайтканда сагынып, кибет тирәсендә йөрүне белми, баш күтәрми ташын чыгара, базын казый, коймасын утырта, абзар-кураны яңарта. Кулыннан килмәгән эше юк аның. Әле шуның өстенә энебез спортсмен да. Ул татарча көрәш буенча төрле шәһәрләрдә оештырылган ярышларда катнаша, чаңгы, велосипед ярышларында да призлы урыннарны яулаганы бар. Авыл һәм район сабан туйлары батыры. Ул Казаннан авылга да җәйләрен велосипед белән (110 чакрым араны), кышларын Арча аша чаңгы белән кайтып керә. Әни аның шушылай көч түгеп йөрүен бик кызгана. Ә үзенең сугыш елларында Арчага да, Казанга да җәяүләп, чабата киеп барып кайткан чакларын оныткан...

Сугыш елларында әни колхозның сыер фермасында эшли. «Атлар кырда да бик кирәк,— дип искә ала әни хәзер.— Шуңа күрә еш кына сауган сөтне, кул арбасына утыртып, Сабага хәтле җәяү тартып менә торган идек». (Саба безгә ун чакрым.)

Сугыштан соң әни, унбер ел буе, авылда сөт җыючы

булып эшли. Сөт белән тулы бидоннарны арбасына бер төйи, бер бушата, бер төйи, бер бушата. Җәйнең чиләсендә дә, яңгыр-бозында да, чатырдап яшен яшьнәгәндә дә, арбалар янтаеп аварлык пычрагында да — ул юлда, Саба белән ике арада. Кулда — дилбегә, уйда — без. «Өйләнеп төшкәнче исән-сау торырлармы икән? Ут-күз чыгармаслармы? Тавык-чебешкә ашарга бирергә онытмаслармы?..»

Ә без — исән-сау. Эшләп-эшләп тә, уйнап-уйнап та арыйбыз да, өйне ташлап, Саба юлына, әни каршына чыгып йөгерәбез. Әле Нурулла алга чыга, әле мин. Әнинең аты күренгәнче шулай үргә таба йөгерәбез. Әни каршына, әни янына ашыгабыз...

Менә шул Нурулла әнем хәзер сабан туйлар батыры иде. Тик аның көрәш белән мавыгуына әни хафалана. Имгәтеп ташларлар, дип курка. Ул сабан туе көнне безнең өйдә нәрсә булганын күрсәгез иде! Башта әни, барысын да әзерләп, җыйнап, сабан туена озата. Нурулла көрәшә башлаган еллардан бирле әни үзе сабан туена бармый. «Тәннәрен сыдырып тотуларына хәтле йөрәгемә ярамый»,— ди. Көне буе өй буш тора. Әти бара әле сабан туена. «Улым, улым...» — дип, елап җибәрерлек булып, түгәрәк янында утыра.

Мина гаиләм белән бергә берничә ел Монголия Халык Республикасында яшәргә туры килде. Шул вакытта, сагынуга түзә алмыйча: «Шушы сопкалар арасыннан яланаяк чыгып йөгерер идем сезнең янга»,— дип, әнигә хат язып җибәргән идем. Әни бу хатны алгач бик борчылган. Шул чакта бик яхшы зиһенемә сеңдереп калдым: юк-бар хәбәрләр белән кайгыга салмаска кирәктер әниләрне. Ананың йөрәге өзгәләнүдән балага барыбер җиңел булмый бит. Белмәсеннәр кайбер кайгы-хәсрәтләребезне, тормышыбызның да бары тик сөенечле яклары турында гына әйтик аларга.

Безнең әни, бәйрәмнәрдә котлап, телеграмма җибәрергә дә кушмый. «Телеграмма күрсәм, «кайсыгыз?» дип уйлыйм,— ди әни без кайткан саен.— Йөрәгем лепердәп кенә тора, гел берәрегезгә берәр нәрсә булгандыр кебек тоела...»

Зиһенендә, хәвеф сигналлары биреп, үзе беркайчан да булмаган, ләкин аның балаларын бикләп тоткан шәһәр сурәтләре кабынадыр. Находка һәм Фрунзе, Новгород һәм Бөгелмә шәһәрләре, Ливия һәм Монголия чүлләре, инде килеп — Татарстан, Зәй, Чаллы шәһәрләре һәм... Казан. Ә үзенең Казаннан ары чыгып китә алганы

юк. Казанга да елына бер генә килеп китә әле. Һаман йорт, ди, атагыз ялгыз, ди, сыерны кем савар, ди. Сыер асрап, тавык-каз тотып, ел буе без кайтып китәсе бер айны — җәйнең бер аен көтә. Ирләребез, балаларыбыз белән бер табын янына гына сыймасак та, әни һәммәбезнең җаен, көен таба. Һаман без торганчы торып, таба ризыгын пешереп өлгергән була. Әле һаман кемнең нәрсә яратканын хәтерли, кемгә сумса, кемгә әчегә пешкән коймак, кемгә төчесе... Минем әле дөньяда ризыкны безнең әни кебек тәмле итеп пешерүчене очратканым булмады.

Буш вакытында әни каба төбендә. Җебен жегерли, ооскбаш-бияләсен бәйли, шәленә дә вакыт таба. Әнинең эшсез торган чагын күргәнем юк. «Әни, бераз ял итеп ал инде»,— дисәң, «Кул эше тоту үзе ял бит ул»,— ди. Без үскәндә дә шулай иде, хәзер дә шулай. Әле эшли алганына куанып йөри. Эш сөю. сабырлык, түземлелек, гомумән, күп татар хатын-кызларына хас сыйфат. Үскәндә әни безнең дә кулны буш тотмады. Кышкы кичләрдә, идәнгә тезелешеп утырып, кайсыбыз итеккә йон яза. кайсыбыз оскбаш бәйли... Әни дә гел безнең арада. Җиде хатын-кыз җыелган жиргә женияләшә, диләр, шуна күрә Нуруллаңы яныбыздан җибәрмибез. (Әти төннәрен күбрәк каравыл өендә була.) Менә шундый кышкы кичләрдә әни безгә җырлый иде. Тик, нигәдер, ул гел бәетләр җырлый иде. Сак-Сок бәетен дә көе белән минем бары тик әнидән генә ишеткәнем бар. Ул аны безгә бик еш җырлый иде. Шул бәетне белгәннән соң, мин гомер буе әнинең каргышыннан курыктым, әнинең моңлы авазы һәм кавышa алмыйча тилмергән Сак-Сок кошлары мине балачактан әле һаман да озата килаләр кебек...

Аның үзенең бер туганы да булмаган.

Ә без — уп туган.

Кайсыбызда әнинең күзләре, кайсыбызда — тавышы, гадәтләре, моңы. Рәхмәт әйтеп кенә түләп бетерә алмаслык уп кеше гомере... Һәм шул гомерләр башында кечкенә генә әнисебез... Дөньяда иң кадерле, иң изге кеше...

Хәтердәге кышкы сурәт. Кыш. Төн. Урамда җепшек буран котыра. Җәяүле дә, атлы да юлга чыгарлык түгел. Мондый көнне хат-хәбәргә дә өмет юк. Буран басылганын көтәргә кала. Кыш үтүен, юллар төшүен...

Әни кабасы төбенә утырган да шундый уйларга чумган, ахры. Тәрәзәләрне буран күмгән, урам да, дөнья да

күреңме. Ә хәтереңдә язлар микән, җәйләр микән, безме икән?

Мин, ишек яңагына сөялеп, аны күзәтәм. Мин бу юлы әни янына кышын кайттым. Үрмәләп, шуышып, кар көртләрен ерып кайттым. Менә барыбер кайттым... Өлгердем...

— Исәнме, әни?!

Әле ярый син бар, әни...

Фәүзия Бәйрәмова

УРМАН ШАВЫ

Урман. Нинди хозур урын ул. Беркайчан да ялыктырмый кешене. Алай гынамы, тыңлый белсәң, әкрен генә нскән җилдә синең белән сөйләшә дә урман. «Саумы, кеше,— ди ул үзенчә пышылдап.— Ни хәлләрең бар?» Урман хәтерли: әле кеше балта да ясый белмәгән, куышы да булмаган заманда ук урманга сыенган, аңардан җылы эзләгән. Урман кешене йоклату өчен йомшак яфракларын түшәгән, усал җәнлекләрдән рәнҗеттермәү өчен агач куәсәсенең очыннан урын биргән.

Әйе, урман игелекле. Аның үзенә дә игелекле булу кирәк, әлбәттә. Әнә, Азат, Әнвәр, Мизхәт, Мөдәррис, Мөгътәсим кебек урманчылар моны яхшы аңлыйлар. Рәхмәтләр, кулларыннан килсә дөньяны яшел урман белән төреп алырлар иде.

— Урман үссен дисәң, иренмәскә кирәк,— диләр алар. Шуңа күрә әледән-әле авыл Советларында, колхоз идарәләрендә булалар, авылларны, аларның тирә-якларын карап йөриләр; кайда нинди агач утыртырга мөмкин — өйрәтәләр, киңәш бирәләр, алар өчен үсентеләр әзерлиләр.

Урман һәр яңа буыннан зуррак тәрбия өмет итәргә хаклы. Наилә, мәсәлән, мәктәп балалары белән элемтәдә тора. Һаман урманга йөртә үзләрен, өйрәтә. Укучылар үзләре дә анда бик теләп, бик яратып йөриләр. Яшь үсентеләрне утырткан вакытта Наилә тирәсендә бөтереләләр, сорау артыннан сорау яудыралар: «Менә бу үсентеләр агач балаларымы?», «Йөз метрлы имән буламы?», «Яз көне киссәң, каен ни өчен елый?»

Наилә мондый чакларда каенны — 50, наратны — 80,

чыршыны — 70, усакны 40 ел үткәч кисә кисәргә яравы турында да сөйли. Балалар нәни куллары белән яшь үсентеләр төбеннән чүп утаганда, агач утыртканда, урман бертуктаусыз куанып, үзенчә сөйләшеп тора кебек. «Дөрес, дөрес...— дия сыман ул.— Апагыз белеп әйтә. Ерак бабаларыгызга кирәк булган кебек, сезгә дә гомер буе кирәк булачакмын. Тырышыгыз, тырыш...»

Күпме көч, күпме хезмәт куеп утыртылган мәйданнар икс-өч сәгатьтә харап була кайчак. Әле менә узган җәйдә генә Краснояр авылы тирәсендә ике көтүче меңнәрчә яшь үсентене маллардан таптатып әрәм итте.

Ничек кенә горур шауламасын, кайбер бәндәләрдән сагаеп һәм куркып та кала урман. «Син көчлерәк инде хәзер, кеше! Күрәм, кулыңда балта гына түгел синең, минем йөз ел үскән агачымны да йөз секундта аударырлык куәтле коралың — моторлы пычкың бар! Мине һәр тарафка ярып үтәрлек гайрәтле тракторың бар! Ләкин, акылыңа кил, адәм баласы: мин сиңа әле хәзер дә җылы бирәм, яшәргә йорт бирәм, үпкәләрең сау-сәламәт булсын өчен һаваңны сафландырам. Менә син, як-ягыңа шикле карап торасың, кисәргә, аударырга, таларга ниятлисең. Ниятеңне гамәлгә ашырганчы уйла: киләчәгеңә, баларың өлешенә кул сузасың син». Урманның бу ялваруын бөтен кеше дә аңлый, тыңлый белми шул әле.

Ерак барасы юк. Урманчылар коллективының үзенә кереп оялады шундыйларның берсе, эшләгән кебек йөри торды, аск чагы күренмәде. Агач сату хәбәре килде. Бер кисәтте Наилә, ике кисәтте — файдасы тимәде. Шуннан соң өзгәләнеп:

— Урманчы булып эшләү түгел, урманга керергә дә хакың юк синең, абый,— диде.— Каргыштан куркыр идең, исмасам...

Туктале, ни өчен килеп керде соң аның теленә «каргыш» сүзе ул чакта? Юк-барга ышануы түгелдер бит? Түгел икәнен яхшы белә белүен, ләкин урман булып урманга кул күтәргән кеше җәзасыз калмаска тиеш дип саный. Теге урманчыга да тиде урманның каһәре. Гомере буе тормышының куанычы булмады.

Кызы Ләйлә белән улы Илдарның урманчы һөнәрен сайлауларына гаҗәпсенмәде Наилә. Ник дисәң, тәпиләренә баса башлау белән үк урман юлында булдылар. Рухлары-җаннары белән урманга береген үстеләр алар.

Бүгенгедәй хәтерендә Наиләнең. Моннан 25 ел элек, шушы коллективка лесничий ярдәмчесе булып килгәч, яна питомник өчен Ташъелга буенда урын сайладылар. Кая

нide ул чакта хәзерге кебек техника!.. Азат абыйсы, Наилә үзе һәм тагын ике хатын-кыз питомник мәйданын үзләре казыдылар. Эшли торгач, беләкләре арыды кызның, уч төпләре сөялләнеп чыкты. Ә Азат абыйсы, аларга карап елмая да, эшләвен белә. Ниһаять, түзмәде, сорап куйды Наилә:

— Бер дә арымыйсың, Азат абый. Әллә арытмый торган берәр даруын беләсеңме?

— Урман эшләтә, Наилә, урман.

Урманга матур язмыш килсен дип тырышкан Наилә бу вакыйганы еш искә алды, балаларында да шундый олы күңеллелек тәрбияләргә тырышты. Пенсиягә чыкканчы урманда эшләгән әбиләре Саимә дә:

— Урманда эшләү өчен гыйлемнән, тырышлыктан әүвәл мәрхәмәтле булу кирәк, оланнар,— дип әйтә килде.

Наилә улыннан килгән хатны икенче кабат укып чыкты. «Кош сайрауларына хәтле сагынам, әни... «Юк икән, мондый җылы хатка әбәт вакытында гына җавап язып булмый икән. Әбисе дә, апасы да кайтсын әле Илдарның...»

Ә эш дигәнең берчакта да бетеп тормый. Көн туды исә 9 мең гектардан артык мәйдандагы урман үзенең бүгенгесе белән генә түгел, киләчәге өчен дә урманчыларга берсеннән-берсе җаваплы һәм тынгысыз мәшәкатьләр тудырып кына тора. Киңәеп, тирәнәеп баручы яр һәм чокырларны да бары тик агач утырту белән генә ишелүҗимерелүдән саклап була. Алары да ел саен күпме хезмәт сорый. Сер түгел, техника да җитеп бетми әле. Урман эше өчен яңа техника сирәк кайта. Шулай да Мөслим урманчылары яшеллек сагында уяу торалар.

Табигатькә игелекле кеше бәхетле була, дигән борынгылар. Урман тәрбияләүдә утыз ике ел эшләгән Азат Бәдретдиновның күтәренке күңел белән эшләве бүген дә күпләрне сокландыра. Гомерләрен, хезмәт юлларын урман белән бәйләгән Мөдәррис Хаҗипов, Әнвәр Хәкимуллин, Мизхәт Нурахмәтов, Мөгътәсим Хафизов та үз һөнәрләренә тугры кешеләр. Әнә шул үз хезмәтләрен яратып башкаручылар куандыра Мөслим лесничиеның ярдәмчесе Наилә Шәрәфетдинованы. Үзен дә зурладылар әле Наиләнең — «РСФСРның атказанган урманчысы» дигән мактаулы исем бирделәр.

Хатны кич белән бергәләп, киңәшеп яздылар. Эчтәге хисләрне, искә төшкән вакыйгаларны, бөтен яңалыкларны бер хатка сыйдырып булмый, билгеле. Шулай да сәламнән соң үзләренең хәлләре, эш-мәшәкатьләре, шат-

лыклары турында тулырак яздылар. Инде язган хатны конвертка салам дигәндә генә Наилә бер җөмлә өстәп куйды: «Кошлар сайрап торган урман үзеңне дә бик сагына, улым...»

Фәнзаман Баттал

ҮЗЕҢ ӨЧЕН ГЕНӘ ЯШӘМӘ

Зәбидә Фатыйхова шигырьләр язарга ярата: балачак, үсмер чор хисләрен канатланып көйле юлларга салып йөргәненә әле кайчан гына кебек иде... Гомер дигәнең шулай сизелми дә үтеп бара. Әнә шул шигырьләрен укыган чакларда ул тагын бер кат яшьлегенә кайткандай була. «Кара син бу кызыйны, җыентык туплаган бит...»,— дип көлеп куя Зәбидә.

Зәбидә Фатыйхова эшли торган «Татхимфармпрепараты» берләшмәсе элек сәламәтлек саклау учреждениеләреннән санала иде, хәзер ул химия промышленностена карый. Зәбидә — фармацевт, безнеңчә әйткәндә, дару ясаучы.

Зәбидә монда очраклы рәвештә килеп эләккән.

1967 елда урта мәктәпне яхшы билгеләренә генә тәмамлагач, ул Казанга укырга килә. Теләге — татар әдәбияты укытучысы булу. Укый да башлый, ләкин сәламәтлеге аркасында укуын ташларга туры килә. Химфармзаводка эшкә урнаша.

Аннан соң унсигез ел вакыт узган. Казан фармацевтларының, кетгутчыларының даны зур.

Зәбидә Фатыйхова да ил күләмендә танылган эшче булып күтәрелде.

Кызлар кулында бәләкәй үлчәү, берсеннән-берсе вак герләр. Таблеткаларның калынлыгы — миллиметрларның, авырлыгы граммнарның өлешләре белән үлчәнә. Таблетка төрләре алмашынып тора. Монда чамалап эшләргә ярамый. Монда продукцияне сортларга аеру да була алмый. Дару бары тик югары сыйфатлы гына булырга тиеш.

Мондый шартларда кемнәрдер бөтенләй эшли алмый. Кемнәрдер әкрен алдыра. Зәбидә исә үз нормасын биредә бер атна эшләгәннән соң ук тутырып бара башлаган иде

иide. Бу хакта ул бригадасындагы яңа бер эшчеңең кыланышларына сәерсенеп сөйләгәндә искә төшерде.

— Галина Агашина кебек оста да өйрәтә алмый. Яшь кеше дә түгел үзе. Үзе булдыра алмый, кешене тыңламый. Нормасын без эшләп тутырабыз. Хезмәт хакын ул да эшләп алсын, дибез.

— «Бөтен кеше — бер кеше өчен» — бригада шундый принцип белән яшидер бит, ул иптәш шуны яхшы беләдер?

— Ул принципның «...бер кеше — бөтен кеше өчен» дигән өлеше дә бар бит,— Зәбидә үзенең бригада җыелышында түгеллеген онытып җибәрә.

Шундый булганы өчендер, бер ел эшләгәч үк Зәбидә Фатыйхованы профорг итеп сайлыйлар.

— Взнослар түләүдә тәртип урнаштырудан башладым,— ди ул, ул чакларын искә алып.— Ошатмаучылар да булды, ләкин булды да бетте. Иң кыены ул түгел. Профоргның мәшәкатьләре, кем әйтмешли, тавык чүпләп бетермәслек...

Кемдер авырып китә, кемнеңдер бәбие туа, кемнеңдер үз туе, кемнеңдер якынын иң соңгы юлга озатырга кирәк... Әй, азмыни кеше итүнең хәлләре... Тетя Тосяның ире үлгән, ярдәмчеләре җитми. Барырга кирәк. Рус кешесен күрмичә, чиркәү, христиан дине турында җыен юк-барны ишетеп үскән кыз баштарак тартынып тора. Барыбер бара Зәбидә, Тося түтие белән янәшә була, булыша.

Зәбидә һаман шул хезмәттәшләре мәшәкате, йомышы белән йөри, алар шатлыгы, алар хәсрәте белән яши. Шуңа күрә дә коллективта аны үзләренең иң якын сердәше, ярдәмчесе, яклаучысы итеп саныйлар. 16 ел инде аны профкомга сайлыйлар.

Гомумән, бирегә килгәннән бирле Зәбидә Фатыйхова — профсоюз эшендә. Ә шушы җәмәгать эшләре өчен бүленгән эш вакытын ул ял сәгатьләре белән кайтара: өстәмә сменаларга кала, шимбә көннәрендә эшкә чыга.

Бервакыт аларны җыялар да:

— Бригадаларга берләшеп эшләргә кирәк,— диләр.

Булдыклы, тәртипле эшчеләр ялгыз эшләргә мөмкин булган урында башкалар белән берләшергә атлыгып тормыйлар. Аларны аңлап кына түгел, аклап та була.

Зәбидәгә дә үзенчә генә эшләү начар түгел иде. Ватылса, машинасын да үзе көйләргә өйрәнде. Бер эш бетеп торганда икенчесенә тотына ала. Участокта гына түгел, цехта, заводта аның кулы ятмаган эш юк. Кирәге чыкса, эшкә иртәрәк килеп, соңрак кузгалырга да әзер ул.

Ә шулай да ул яңалыкны хуплап каршылады. Аңа Зөлхия Закирова, Галина Агашина, Фәүзия Садриева, Людмила Маркина, Роза Минигалиевалар да кушылды. План ярым, ике план күләмендәге эшне ялт иттереп куя торган эшчеләрнең мондый омтылышы, бер карасаң, гаҗәпләнерлек тә бит. Ә төптәнрәк уйласаң?

— Элек шулай булгалый иде,— дип искә ала Зәбидә.— Таблетка барыбызга да смена буена эшләргә җитмәслеген белеп алып, берәү үзенә запас ташып куя... Ә берсе берәүнең машинасы туктап кала, аны тиз генә көйләп булмаган чаклар сирәк түгел... Кемнеңдер баласы белән пидер килеп чыккан, эшкә соңлап киләчәк... Кемнеңдер бүген кәефе бик үк яхшы түгел... Дөнья бу! Берәү дә берәү өчен дә җаваплы булмаса? Хезмәтең керүенә карап, хакы дигәндәй, башкасы...

Җитәкчеләр бригадирлыкка кеше сайлый башлагач, иптәшләре Зәбидә Фатыйхованы тәкъдим итәләр.

— Кыюсыз бит ул,— диләр кайберәүләр.

— Кыюсыз түгел, тыйнак, әдәпле,— диләр кызлар.— Унбиш ел инде ул — безнең өчен алыштыргысыз җитәкче.

Соңгы дәлил — каршы торып булмаслык дәлил.

Зәбидә үзе бу вакытта өендә авырып ята торган була.

Шулай да аны бригада җитәкчесе итеп сайлыйлар. Әйбәт эшли, тату яшь бригада. Аны киң күңеле белән Зәбидә үзе дә җылытып, беркетеп тора.

Яшен яшьнәп күк күкрәми,
Бик тыныч кына явар.
Һәр җирдә шифасы тияр,
Ул бит кояшлы яңгыр.

Үсмер чагында язган шушы шигырь юллары миңа аның үзе турында сөйли сыман.

Тормыш, ягъни аны югары урыннарга сайлап куйган эшчеләр өйрәтәләр нечкә күңелле Зәбидәне. Беркөнне таблеткалар цехына кергән иде. Монда дару гранул рәвешендә килә. Апалар аны тиешле дәрәҗәгә китергәнче эшкәртәләр, аннары таблетка итеп «коялар». Бүлмәдә гел дару тузаны тора. Кызлар көн буе, еллар буе күпме тузан йоталар.

— Врач авыруларга даруны ярты таблеткалап бирә, артыгы зарарлы булганга шулай итә, ә безне нишләтәсез? — Апалар Зәбидәне уратып алдылар. Алар эштән баш тартмый. Үз эшләренең «Сәламәтлек өчен зарарлы»лар исәбенә кертелергә, үзләренә шуңа бәйләнешле льготалар бирелергә тиешлеген таләп итәләр. Зәбидә белә:

алар хаклы! Мәсьәләнең унай чишелеше артыннан завод җитәкчелегенә йөри башлый...

Яки менә ашханә мәсьәләсе. Яратмыйлар эшчеләр үзләренең ашханәләрен. Андагы кимчелекләр күптән һәм һәр кешегә билгеле. Профсоюз, халык контролерлары белән берләшеп, рейдлар оештыра. Ашханә мөдире рейдчыларны санга сукмый, эшен яхшыртмый. Берләшмә җитәкчеләренә генә ошарга тырыша.

Эшчеләр турында кайгыртуга бәйләнешле нәрсәгә генә тотынсаң да канәгатьләнерлек эш күрмисең.

Июнь ахырлары иде. Мәскәүгә профсоюз Үзәк Комитеты Президиумы утырышына чакырып хат килде. Бик күп сораулар җибәргәннәр. Президиумда эшчеләрнең торак шартларын, культура-көнкүрешен яхшыртуга, сәламәтлеген саклауга, ялын оештыруга бәйләнешле хәлләрнең торышы тикшереләчәк. Зәбидә Фатыйхова мәсьәләне үз предприятиеләре мисалында өйрәнергә, Президиум карамагына кертергә тиеш. Аңа шул йөкләнгән.

Зәбидәнең бит алмалары яна башлады: хурга калыр көннәре алда булган икән. Кайсы сорауга төртелсә, шуна җавабы кире.

— пионер лагере — юк.

— поликлиника — юк.

— культура сарае түгел клуб та юк, цехларда, участокларда кызыл почмакларны да бетерделәр.

— тулай торак — юк.

— санаторий-профилакторий — юк.

— квартира төзелеше юк дәрәҗәсендә.

Хатны алгач та үзәккә тагын жалоба язганнардыр дип уйлаган иде. Язарга җай бар. Фания Шәмсетдинова, мәсәлән, заводта күренекле кеше. Цех комитеты председателе булды. Тармак профсоюзы съездында катнашты. Карт әнисе, кызы, кияве, оныгы белән биш җан бер бүлмәдә яшиләр иде. Чиратта аңардан соң торганнар, бөтенләй чиратта тормаганнар квартира ала килә, ә ул кала бирә. Түзми шундый хурлыклы хәлләргә, язып җибәрә. Нәтиҗәсе тиз булды:

— үзенә ашыгыч рәвештә өч бүлмәле квартира таптылар;

— квартирага торучылар чиратында тәртип урнаштырылды.

Тукай сүзләре искә төшә: «Тотса мәскәүләр якаң...» Яхшы булды анысы, әмма үз өендә үзәк органнар аркылы гаделлек урнаштырырга калгач, хурлыгы зур.

Бервакыт участок начальнигы Валентина Ивановна

Егорова өченче сменага чыгарга куша. Мондый йөрүләр ешка киткәч, Зәбидә сорап куя:

— Өченче смена итеп язабызмы соң? — ди.

— Юк. Нарядны карандаш белән генә тутырасың,— ди начальник.

— Алайса, әйдәгез, безнең кызлар янына бергәләп барыйк, ихтыяҗ булгач, өченче смена оештыру хакында сөйләшик,— дип тәкъдим ясый бригадир.

Сөйләшү начальникның янавы белән тәмамлана:

— Бик күпне белә башладың,— ди ул, бу шул тыңлаучан, кыюсыз Фатыйховамы соң дигәндәй, сынап карап тора.

Әйе, гел башын түбән иеп эшләргә күнеккән эшчеләрнең бер генә каршы сүзен дә күтәрә алмый җитәкчеләр. Тик бүгенге эшче — моннан 25 ел, хәтта 5 ел элеккеге эшче дә түгел шул инде. Ул кыю фикерле, эш нәтиҗәләре белән җитәкчеләргә караганда да ныграк кызыксына хәзер. Зәбидә Гатаулловна да Егорова кебек начальниклардан куркып эшләми. Ул гади эшче хатын-кызлар мәнфәгате өчен көрәшә.

Хәмзә Зарипов

АРЕНДАТОР НӘФЫЙК

Нәфыйкның Минзәләгә якынлашып килүен милиционер ерактан ук күзәтеп торды. Дөресен генә әйткәндә, башта ул безнең якларда күренгәне булмаган кечкенә генә тракторга игътибар итте. Бу техниканы бишекле мотоциклга охшаткан иде башта. Әмма якынлашкан саен уенчыктай бәләкәй трактор икәнлеген күреп гаҗәпләнде. Тамаша кылу күңелле-күңеллесен дә, иллә дә мәгә руль артындагы бу кеше ни өчен соң әле юлның бер ягыннан гына килми? Алай-болай исерек түгелдер бит? Трактор тәмам якынлашкач, тагын бер нәрсәгә игътибар итте тәртип сакчысы: килүченең, кем әйтмешли, авызы колагына җиткән — йөзеннән һич кенә дә елмаю галәмәте китми. Түзмәде, туктатты:

— Яле, егет, сулышыңны тикшереп карыйк. Градус хикмәтләре сизелми микән?

Тыелырга тырышса да, булдыра алмады Нәфыйк —

гажәп кызык сүз ишеткәндәй көлеп җибәрде. Инде дә бераз аңлашкач, әйтеп куйды:

— Хәмерне йоту түгел, аның турында уйларга да вакытым юк минем, туганкай. Заманасы ул түгел.

Районлагы май комбинатында аертылган сөт тутырып кире кайтканда, шушы сөйләшүне искә төшереп, берничә мәртәбә көлемсерәде Нәфыйк. Ихатасына кайтып кергәч, хатыны Бәрнягә дә кызык итеп сөйләде. Беренчедән, чокыр-чакырлы юлның тигезрәк урыннарын сайлый-сайлый бармасаң, тәгәрмәчләре иләктән әллә ни зур булмаган бу тракторны ничек йөртмәк кирәк? Икенчедән, бар, эчеп кара үз җаваплылыгыңа шушы кадәр малны кабул иткәч! Бер-ике сәгать кенә ялгыш юлда йөрсәң дә, бөтен уй-хыялларың, өметең, абруең юкка чыгачак бит. Әле ул һәр адымыңны чамалап, һәр минутыңның кадерен белеп яшәсәң дә, әллә ниләр килеп чыга тормышта. Әнә бит, колхозның егерме сигез баш дуңгыз баласын кабул итеп үз ихатасында симертергә алып кайткан көннең икенчесендә үк нинди хәл килеп чыкты!

Иртән абзарны ачып керсә, ни күрсен: ике дуңгыз җан биргән. Сизенүе, шикләре юкка булмаган икән. Шуларны алырга дип фермага баргач, малларның туктаусыз ютәлләвенә игътибар иткән иде. Председательгә, баш белгечләргә барып зарланыргамы? Чирле терлекләр әлеккән, гамәлдән чыгару мәслихәт булыр, дип, гаугалашыргамы? Дипломлы зоотехникка эшнең нәрсәдә икәнен аңлау кыен булмады: үпкәләре чирле. Бу хакта беркемгә дә сүз ычкындырмады. Менә бит гөнаһ шомлыгы — икенче көнгә тагын алтысы кырын яткан. Утка баскандай фермага йөгерде Нәфыйк. Әмма тиешле дарулар табылмады...

Шул көннәрдә аны «арендатор Нәфыйк» дип йөртә башладылар. Яшерен-батырын түгел, усал телләләр ачырак, тозлырак сүзләрне дә тиз таптылар: «Замана кулагы», «Хыялый Нәфыйк»... «Кулак» дигәнен Нәфыйк беренче ишетүдә үк ошатмады. Ник дисәң, исеме җисеменә туры килми. Мәктәптә, аннан техникумда укыган елларында да кулакның бары тик үзе өчен генә тырышучы, башкаларның хезмәтен сыгучы зат икәнен аңлап үсте. Ә хәзерге заман тудырган арендачылар бөтенләй башка — алар турыдан-туры колхоз белән төгәл килешү нигезендә эшлиләр, илне халык өчен зарури азык-төлек белән тәэмин итүдә социалистик законнардан тайпылмыйлар. Арендачы башка крестьяннан бары тик бер нәрсә белән — үз җилкәсенә зуррак йөк һәм җаваплылык алуы белән аерыла. Хезмәт хакы да үзе китергән хезмәт бәрабә-

ренә түләнә арендачыга. Бушлай бер тиен дә бирмиләр...

«Хыялый» дигән сүзгә үпкәләми Нәфыйк Гатин. Һәркем сизеп, күреп тора хәзер: илдә кузгалган үзгәртеп кору хыялый кешеләрне көннән-көн ишәйтә. Аларның хыяллары нәрсәдән гыйбарәт соң? Бу сорауга җаваплары ачык: ризык мәсьәләсендә халык кытлык кичермәсен, барысы да җитешле булсын. Яңача эшләүнең икенче ягы да кызыктыра. Бу очракта кеше вакыт үтсенгә, җитәкчеләрнең күңелләре булсынга гына эшләми. Аның хезмәте чын мәгънәсендә иҗади хәзер. Ата-бабадан килгән тәҗрибәләрне дә, кигап өйрәткән гыйлемнәрне дә кулланып, төрле әмерләрдән, боерыклардан, урынлы-урынсыз җикерүләрдән, буш сүзләрдән азат булып эшли арендачы. Түләү мәсьәләсендә дә алдый яки кимсетә алмыйлар аны.

Нәфыйк йомыш табып әле дә хуҗалыкның дуңгыз фермасына кергәләп йөри, анда эшләүчеләр белән үзен чагыштыра. Әйтик, анда дуңгызларны көнгә ике тапкыр ашаталар. Нәфыйк дуңгызларны исә дүрт тапкыр «сыйлана». Ходай бирмеш көннәрнең һәркайсы арендачыга конвейер булып тоела. Монда кешегә салына алмыйсың. Бер генә эшең онытылса да, синең өчен эшләүче юк. Каравылчы да, белгеч тә, фуражир да үзең. Башкачарак әйтсәк, галиҗәнап та син, шул галиҗәнапның әмерләрен жиренә җиткереп үтәүче дә син.

Чыннан да, күңелне әллә нинди хыялларга, ачышларга китереп тоташтыра икән бу яңа тормыш. Нәфыйкның уйлавынча, крестьян якын елларда ук үз җилкәсендә яшәүчеләрдән арынырга тиеш. Югыйсә, колак артына каләм кыстырып, башкаларның эшен тикшергән, исәбен алган булып йөрүчеләр үзләренең «Яңа юл» колхозында да елдан-ел «үрчи» баралар. Мизәлә ягындагыча әйтсәк, «үрәтүчеләр» күбәйгәннән-күбәя. Әнә шуларның барысын да продукция җитештерүгә тартырга хыяллана Нәфыйк Гатин. Менә булыр иде, ичмасам, илгә файда! Һәркайсы унар дуңгыз яки бишәр эре мал гына симертеп дәүләткә сатса да, ил халкы игкә кытлыкның нәрсә икәнен онытыр иде. Хуҗалыкның экономикасына анализ ясаучы, төгәл хисап алып баручы кешеләребез дә булмаячак, әлбәттә. Ә баш белгечләрне әйткән дә юк. Аларсыз игенчелек тә, терлекчелек тә алга бармаячак. Әле менә, бая әйткәнебезчә, Нәфыйкның карамагындагы дуңгызлар өч дистәдән артмый хәзергә. Ә бит эшнең башы гына бу. Маллар санын ким дигәндә йөзгә җиткерергә уйлый арендачы. Дәүләткә сатарлык булып симергәннәрен хәзерләүләр пунктына җибәргән саен яңаларын алып торачак. Һәр

терлекнең тәүлеклек үсеше хәзергедәй 650—660 грамм белән барса, ел саен хәзерләүләр пунктына ике йөз баш чамасы дуңгыз сатып булачак. Аларның һәркайсының тереләй авырлыгын 120 шәр килограммга җиткереп озатсаң, ил табынына елга 20 тоннага якын ит куясың дигән сүз. Шуңа ирешелә икән, колхоз чыгымнарын кире кайтарып биргәннән соң, еллык хезмәт хакы артыгы белән 20 мең сум тәшкил итәчәк. Бу кадәр акчаны кайда куяр соң Гатиннар гаиләсе? Акчага урын әзер инде. Чехословакиядән кайтартылган мини тракторның хакын, ягъни җиде меңне колхозга түләп, үзләренеке итәргә исәпләре... Бу трактор җәйге чор өчен бик уңай: сөрә дә, ура да, печәнен дә чаба, күтәрә, ташый. Һәм шул ук вакытта ягулыкны да аз «ашый». Әмма кышкы юлларда аның белән йөрү кыен булачак. Димәк, җыйнаграк йөк машинасы кирәк булу зарурлыгын тормыш үзе әйтеп тора.

Нәфыйкның яңача эшләве үзенә көнләшеп караучыларны да ишәйтте, яклаучыларны да арттырды. Күпләр хәзер аның юлын сайларга җыена. Бу вакыйганың хуҗалык тормышын тиз арада үзгәртәчәгенә колхоз председателе дә ышанып җитми әле.

— Бервакыт машинада барам шулай. Янымда — шоферым. Нигәдер сөйләшми, бик уйланып бара. Кинәт кенә машинаны туктатты бу һәм әйтә: «Әнфәс абый, миңа да илле дуңгыз бир. Минем дә Нәфыйк кебек эшлисем килә». Басуларны әйләнгәч, идарәгә кайттым. Анда мине комплекслы бригада бригадиры Рәис Әхмәтҗанов көтеп тора. Кабинетка ияреп керде дә каршыга утырды: «Әнфәс абый, мин Гатин Нәфыйк булдырганны гына булдыра торган кеше. Сүзне озакка сузмыйча гына миңа да йөз дуңгыз бир». Тауасты Байлар авылының яшьләре дә яхшы хәтерли әле: элегрәк тә колхоз тормышына, бөтен ил күләмендәге кебек үк, төрле яңалыклар, башлангычлар кертеп карыйлар иде. Кызыл сүзләрдән торган нотыклар, үгетләүләр, кочагы-кочагы белән кайтучы вымпеллар, тырышка да, ялкауга да тигез бирелә торган премияләр белән көчәйтергә тырышалар иде хезмәт дәртен. Ни гаҗәптер, шул яңалыкларның күбесе ялкыны күренмәс борын ук сүнә-сүрелә барды. Ә үзгәртеп кору китергән тәкъдимнәрне һәм алымнарны халык икеләнүсез, шиккләнүсез кабул итә. Матур өндәмәләр дә, әйдәкләп йөрүче «эшем ияләре» дә, озын-озын тәрбия телмәрләре дә кирәкми. Нәфыйкча әйтсәк, берсенең дә хаҗәте юк.

Туктале, соңгы ике-өч елда партия тарафыннан тәкъдим ителгән яңа ысулларга авыл кешеләре ни өчен күп-

ләп тартыла башладылар? Сәбәбе — кешеләрне калыпланган ысуллар туйдырды. Чөнки алар крестьянның мөмкинлекләрен чикләп килделәр. Әнә Нәфыйк та башта үз көчен чамалап бетермичә генә башлаган иде. Үз-үзенә ышану өчен зурдан кубмады ул. Тора-бара эш күләмен тагын өч тапкыр зурайтырга мөмкин булуына төшенде.

Хикмәт тагын шунда: үзең теләп алынган эш бер чакта да арытмый, күңелне биздерми. Шулаен шулай да, адәм баласына ял да кирәк бит. Бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр көн саен эшләү туйдырмасмы?.. Нәфыйкка бу сорауларны биргәч, борчылуларыбызның урынсыз икәнлеген аңладык. Җиләк-җимеш, яшелчә бакчасында эшләү өчен дә кала вакыты, гаилә белән иркенләп ял итәргә дә җай таба.

Нәфыйк Гатин үз авылы мисалында күреп тора: үзгәртеп коруны беркем дә туктата алмаячак. Идел кебек ул — аңа бихисап чишмәләр кушыла. Елга көчәя һәм үзенә яңа ташкыннарны тарта тора. Бары тик тәвәккәлләп эшкә тотынырга, мул Иделнең бер чишмәсе булырга кирәк.

Фәнзаман Баттал

КАНАТЛАРЫГЫЗ ТАЛМАСЫН, АКЧАРЛАКЛАР

Адаштыгыз мәллә, акчарлаклар? Кызганыч чыелдашып, шәһәр уртасындагы күл өстендә бөтереләсез. Нәрсә тартты соң сезне монда? Сез бит Иделнең хөр кошлары, рәхәтләнеп киң дәрья өстендә канат җилписе урында шушы тар сазлыктан аерыла алмыйсыз.

Ташчы Гарифулла төзелеш материаллары булмыйча эшсез торганда шул акчарлакларны күзәтеп торырга ярата. Тик бу кошлар аңа кызганыч булып тоела, елга, диңгездә күреп күнегелгән кошларның шәһәр йортлары янында бөтерелүләре күңелендә моңсу уйлар кузгата.

— Бүген тагын соңардылар,— дип уйлады бригадир, графикка күз төшергәч.

— Әллә алар безне көнлекчегә саныйлар инде. Измәне иртәнге 8 гә китерерләр дип көтәсең, юк, я 9 да, янсә

төштән соң гына килеп җитәләр. Анысы да әле телефоннан тресттагылар, заводтагылар беләп тамагын карлыкканчы кычкырышкач кына була. Үз вакытында йөрергә аларны берничек тә мәҗбүр итә алмыйсың. Аптырагач, аерым ташчы янсә штукатурчыны измә, кирпеч артыннан җибәрә башладылар. Төзелештә «йомышчылар» пәйда булды. Шоферларга күз-колак булсын, уңга-сулга йөрттермичә, яныңа утырып төзелешкә материаллар китерсен, янәсе. Шул да булдымы эш!

Трест кадәр трестның үз базасы булмагач, шундый мескен хәлдә яшәвең гаҗәпмени? Булдырсыннар трестта тимер-бетон әйберләр заводы: материаллар бер кулда булгач, кемнән сорарга икәнне белер идең. Югыйсә, «Главтатстрой» «Казанпромстрой» трестына төзелеш объектларын елдан-ел арттыра бара, әмма база элеккечә кала бирә. Төзүчеләр «Промстройматериалы» трестының заводлары, «Татарстройматериалы» берләшмәсенең силикат стена материаллары заводы кулына карап яшәргә мәҗбүрләр. Алар бирсә — аласың, бирмәсә — буш каласың. Ә алар беркем алдында да җавап тотмыйлар. Чөнки ике арада договор төзелмәгән. Кайчанга кадәр шулай итәр бу?..

Эшебезгә җиңеллек килмәсме, тагын да яхшырак эшләп булмасмы дип азмы тырышабыз! Кайда, нинди отышлы башлангыч туа — шуны кулланабыз. Свердловск шәһәре төзүчеләре бишьеллыкны аз составлы бригада белән үтәргә мөмкин булуын күрсәттеләр. Без дә алар үрнәгендә бригададагы уи ташчыны башка эшкә күчердек, әмма эш күләмнәрен киметмәдек. Кемнең нәрсәгә сәләтле булуы шул чакта уч төбендәгедәй күренде. Резервлар эзләп таптык. Әйтик, төрле җайланмалар куллану эшкә зур җиңеллек китерә. Баскычларны «сәнәк-электергечләр», балкон плиталәрен балкон тоткычлар ярдәмендә салабыз. Бригададагы һәр кеше ташчы һөнәреннән тыш, монтажлау, плитә, бетон җыю эшләрен дә яхшы белә. Әгәр измә, кирпеч булмаса, без тәрәзә яшьякларны утырта торабыз, идәнгә бетон җәябез.

Төзелештә бригада подряды кулланыла башлагач, бу ысулны без беренче булып якладык. Инде подряд кертелгәч, бар да җайланыр, эзгә төшәр дип көткән идек — тагын барып чыкмады. Безне гүя үз көнебезне үзебез күрергә мәҗбүр итәләр. Беркем безнең алда җавап тотмый. Ни трест администрациясе, ни безгә материаллар китерүчеләр. Бригада подряды дигәнең дә кәгазь подряды гына булып чыкты.

Ул төзүчеләрнең эшен җиңеләйтүдә, җайга салуда бер дигән метод булырга тиеш иде югыйсә. Әмма безне материал белән тәэмин итүчеләр дә үз эшләрен үзгәртеп корган очракта гына ул отышлы булачак иде. Әмма без ялгыз булып чыктык. Ташчылар, штукатурчылар, балта осталары, монтажчылар, буяучылар гына түгел, безне измә, кирпеч, башка материаллар белән тәэмин итүче завод-комбинатлар, шоферлар да тоташ подрядка күчсен иде. Договорлар төзү, ярышка йомгак ясаганда аларның үтәлешен исәпкә алу, сүзендә тормаучыларга закон көчен куллану кертелергә тиеш.

*

* *

Үзләре төзи торган поликлиниканың өченче катында очынып йөрүче бу кешене мин акчарлакка охшаттым. Бер күргәндә ул кул хәрәкәтләре белән кранчыны «эшләтә», измәсен, кирпечен күчерттерә, икенче караганда телефоннан кемнедер таптыра. Төзүче-бригадирның эше шулай инде: йорт, бина көннән түгел, сәгатьләп югарыга үрләсен өчен барысына да җитеш.

Гарифулла Хәйруллин — «Казанпромстрой» трестында эшли. Коммунист. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт Билгесе» орденнары кавалеры. 1967 елдан — ташчылар бригадиры. 1977 елдан башлап аның бригадасы аз состав белән эшләп бишьеллыкны дүрт елда үти. Унынчы бишьеллыкка да алар бер ел алдан аяк басалар. Бөек Октябрьнең 70 еллыгына ике еллык планны уңышлы үтәп, коллектив КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләнде. Әлек бер ташчыга көнлек норма 1,5 кубометр булса, Хәйруллин бригадасы аны елдан-ел арттыра бара.

— Илебездәге иң алдынгы бригадалар аны сменага 2,5—3 кубометрга җиткерәләр. Әмма бригада аларга тигезләнергә омтылып яшәсә дә, төзелештә хәлләр көннән-көн мөшкелләнә бара. «Главтатстрой» яңа елга төзелеш объектларын планлаштырганда ук төзүчеләр мөмкинлекләрен исәпкә алмыйча, саннарны «түшәм»нән алып куйды. Әйтик, быел төзеләчәк 11 объектның проект-смета документациясе былтырның 1 ноябренә генә эшләнде. Шуңа да карамастан, төзелештә планлаштыру принципларына туры килмәсә дә, алар «Казанпромстрой» тресты планына кертелде.

Аннан соң ел азагы якынлашканда «штурм»нар, авраллар башлана. Төзүчеләрне хәтта үзләре яшәячәк йортларның стеналары кипкәнне көтмичә, штукатурларга, буярга мәҗбүр иттеләр. Чөнки план «яна», планлаштырудагы хата-кимчелекләрне әнә шулай «штурм» белән «төзәтергә» туры килә. Сыйфатка зур зыян килә.

«Промстройматериалы» тресты былтыр тәрәзә блокларын тиешеннән өч тапкыр диярлек кимрәк бирде. Ишек блокларын да төзүчеләр яртылаш кына алдылар. Җыелма тимер-бетон күләме дә 90,1% кына тәшкил итте.

Шул ук трестның 2 нче тимер-бетон эшләнмәләр заводы Г. Хәйруллин бригадасын измә, башка материаллар белән өзек-өзек кенә тәэмин итте. Бригадир Гарифулла тешен кысып булса да түзә.

Килер бер көн: әнә шул Гарифулла кебек төзүчеләр төзелеш, трест эшләре белән идарә итүдә зурдан кубып катнаша башларлар. Ул чакта нигезсез, кемдер җиңел акыл белән кабул иткән планнар, карарларга урын калмас, ул чакта эшчеләр үз кадерләрен үзләре белергә өйрәнерләр.

*

* *

Мин аны үзләре төзи торган поликлиникада гаҗиз булган нәүмиз акчарлак хәлендә очраттым. Гарифулла абыйның күңел канатлары салынган иде. Ул үзенең бригадасыннан күпне көтә, коллективның күпне эшли алырга сәләтле булуына аның иманы камил — әмма аларга төзелештә колач җәяргә, иркенләп эшләргә мөмкинлек, шартлар юк. Трестта коллектив подряды, хуҗалык исәбе кертү турында зурдан кубып сөйләсәләр дә, Г. Хәйруллин бригадасы эшенә күз салсак, бу подрядның әле дә булса кәгазьдә генә калуына ышанасың. Гарифулла Хәйруллович бу хакта «Правда» газетасында да язып чыкты инде.

— Төзелештә тәмам тәртип урнаштыру өчен тулы хуҗалык исәбе кирәк,— дип саный алдынгы бригадир.— Бары аның ярдәмендә генә планлаштыруны һәм тәэмин итүне җайга салырга мөмкин, ә бу — нәтиҗәле һәм сыйфатлы хезмәтнең төп шартларыннан берсе. Без моңа әзерме? Бик үк әзер түгел. Димәк, кемнедер һәм нәрсәнедер кәтәргә кирәк? Минем уемча, иң хәтәре дә шунда: көтеп тормаска, хәрәкәт итәргә, һәр кешегә теләсә нинди мөмкинлекне файдаланырга кирәк.

Соңгы ике елда безнең эштә алга китеш бар. Төзүче-

ләрнең аңы үсә башлады. Әйтик, элек бер кирпечнең ничә тиен булуын күпләр белми иде. Җирдә тиеннәр чәчелеп ятса, аны җыеп алалар, ә кирпечне күрмиләр иде. Хәзер — бөтенләй башкача. Игътибар иткән булсагыз, безнең төзелештә тәртипсез чәчелеп, анда-монда аунап яткан кирпечне күрмәссез. Чөнки хәзер кирпечне санап алабыз, измәне үлчәп, плитәләрне тикшереп кенә кабул итәбез. Хуҗалык исәбе шуңа өйрәтә. Чөнки хуҗасызлык үзе безнең кесәгә суга. Экономияле, сакчыл эшләвебезнең нәтиҗәсен дә күрдек. Бригада эшчеләренең хезмәт хакы артты.

Бүген трестта 150 төзүче җитми. Кадрларның еш алышынып торуы Гарифулла Хәйрулловичны да еш борчыды. Яшьләр төзелештә узгынчыга әйләнде. Төзүчеләр бер әйтемдәге кебек итексез итекчеләр булып яшәде. Үзләре торак төзиләр, ә күпләре егермешәр ел квартирага чиратта торалар. Хәйруллинның киңәше гади: нигә аз гаиләләр өчен йортлар төземәскә? Шундый тәртип булсын: яшь гаилә бүлмә алганга карап гомуми чираттан төшерелми, ә чираты җиткәч, гадәти йорттан квартира ала. Шул чагында яшьләр төзелешкә берничә елга квартира алу өчен генә килмәсләр, бөтенләйгә калырлар. Нинаять, аның киңәшенә колак салдылар. Аз кешеле яшь гаиләләр өчен берсе артыннан берсе йортлар калка башлады.

Төзүчеләргә атказанган дигән исемне еш бирмиләр. Бу исемгә лаек булу өчен дистәләгән еллар намуслы хезмәт итәргә, үз алдыңа югары максатлар куярга, аларны тормышка ашыру өчен бөтен көчеңне бирергә кирәк. Андый актив тормыш позициясе белән яшәгән кешегә җиңел түгел. Ул иң авыр участокта, иң четерекле хәлләрдә утны, гүя, үзенә чакыра. Кимчелекләрне, җитешсезлекләрне кыю ача, аларны хәл итү өчен барлык көчен бирә, иптәшләрен рухландыра. СССР Дәүләт премиясе лауреаты төзүче-коммунист Г. Хәйруллинны мин шундый кеше дип беләм. Татарстанның атказанган төзүчесе исемен йөртергә лаек булуын ул 30 еллык фидакарь хезмәте белән раслады.

...Гарифулла ул көнне төзелеш янында бөтерелгән акчарлакларны очратмады. Кем белә, бәлки алар тынычрак, уңайлырак елга, күлләр эзләп башка урынга күчкәннәрдер, бәлки үз Иделләренә — хөрлек, иркенлек, киңлек кочагына әйләнеп кайтканнардыр.

Газинур Вәлиев

ИҢ ШИФАЛЫ ДӘВА

«Крутушка» санаториенда психотерапевт булып эшләүче, Татарстанның атказанган врачы Мәгаз Галиәхмәтович Галиәхмәтов турында сокланулы җылы сүзләрне күп ишеткән идем. Аның үзен күрәсе, авыруларны гипноз белән дәвалау серләре турында күбрәк беләсе килү, кызыксыну хисе белән янына очрашырга бардым. Ул чираттагы сеансны үткәргәннән соң, җыйнак кына эш кабинетында хатлар караштырып утыра иде. Киң маңгаенда бөрчек-бөрчек тир тамчылары елтырый. Шактый арганталган булуына карамастан, әле дә яшьләрнеке төсле кыйгачланып торган кашлары, яшерен уйларыңны сизгәндәй тирәнгә караучы соры, якты күзләре аның көчле, энергияле кеше булуын күрсәтеп тора.

— Беренче сеанс дәвалау алдыннан мин авыруларга шушы хатларның кайберләрен укыйм,— диде Мәгаз Галиәхмәтович.— Элек дәваланып киткәннәрнең рәхмәт сүзләре авыруларның да, үземнең дә ышанычны нygыта. Безнең эштә ышаныч аеруча мөһим.

Мин, рөхсәт сорап, хатларның берничәсе белән танышам. Алма-Ата шәһәрендә яшәүче Елена Лоскутова болай яза:

«Хөрмәтле Мәгаз Галиәхмәтович! Сездә дәваланып кайтканнан соң үземне яңадан тугандай хис итәм. Озак еллар газаплаган, дөньяны куралмаслык хәлгә китергән баш авыртуым бетте бит! Кан басымым яхшырды, әйбәт

йоклыйм. Мин гипноз белән дәвалауга һәрвакыт ышана идем. Бу ышанычымны сез тулысынча акладыгыз...»

Менә Чаллыдан Мөхәммәтшина хаты:

«Абый җаным, элек кайда гына булмадым да, нинди генә дарулар эчмәдем, берсе дә ярдәм итмәгән иде. Сезнең гипнозны алганнан бирле кәефем әйбәтләнә бара. Кызларым: «Әнием, синең чирләреңне бетергән абыйга безнең дә рәхмәтебезне яз әле»,— диләр. Сез, Мәгаз Галиәхмәтович, миңа аталарча кайгыртучанлык күрсәтеп, савыгачагыма ышаныч кузгаттыгыз, миңа тормыш шатлыгы, бәхет бүләк иттегез. Сезгә нинди генә рәхмәтләр әйтсәм дә, нинди генә теләкләр теләсәм дә, аз булыр кебек...»

Пермь өлкәсеннән Надежда Чеснакова, Казахстаннан Мария Петракова, Маңгышлактан Назирә Галиева, Чаллыдан Рөстәм Фәтхуллин һәм башкалар да үзләренең тирән рәхмәт хисләрен язып җибәргәннәр. Бу хатлардагы «әйбәт күңелле, таләпчән», «авыруларга һәрвакыт игътибарлы», «рентгенсыз-нисез кеше йөрәген күрә алучы тылсым иясе» шикелле сүзләр Мәгаз Галиәхмәтовичка бирелгән иң яхшы бәя булып яңгырый.

— Мәгаз ага, шулай да гипнозның хикмәте нәрсәдә дип уйлыйсыз?

— Һәр эштәгечә, иң әүвәл кешегә карата кешелекле мөнәсәбәт, аның хәленә керү, хисләрен уртаклаша белү кирәк. Атаклы врач Боткин әйткәнчә, беренче карауда ук авыруның хәлен җиңеләйтә алмыйсың икән, врач исемен күтәреп йөрергә дә кирәкми. Авыруның эчке халәтен аңлау, аның белән рухи бәйләнеш булдыру, чирне җиңеп чыгуда дәваланучының үзен эшкә җигү — уңышның яртысы. Дәва алганда бик күп нәрсә авыру кешенең үзеннән тора бит. Ә авыру кеше чир йоккан организм гына түгел, шул чир аркасында психикасы бозылудан җәфаланучы шәхес тә. Аны аңлау өчен чирнең ничек башлануын, көчәю тарихын белү генә җитми. Иң мөһиме: чирне китереп чыгарган психологик сәбәпләрне белергә кирәк.

— Үз эшегездән берәр мисал китермәссезме икән?

— Исеме халыкта «легенда кешесе» дип таралган Бөек Ватан сугышы каһарманы Гомәр Гыймадетдиновны дәваларга туры килде миңа. Хмельницкий шәһәре өчен барган каты сугышларда һәлак булган дип исәпләнгән бу кеше әҗәлне җиңеп, исән кала. Әмма сугышта алган тән яралары төзәлсә дә, җан җәрәхәтләре сыкраудан туктамый. Гомәр Баһаветдинович йоклый алмый, күзен йом-

ды исә, саташып-бастырылып җәфалана. Сөйләшкәндә тотлыгудан интегә. Кыскасы, санаторийга килгәндә бу иптәшнең хәле мөшкел иде. Мин аның белән башта озак кына сөйләшеп утырдым. Чирне җиңеп чыгу өчен авыруның ихтыяр көчен ныгытырга кирәк иде. Мин аңа кеше организмында үзе дә белми торган көч-мөмкинлекләрнең күплеген, савыгу врачтан бигрәк авыруның үзенә бәйле икәнен аңлаттым. Сугыш кырында үз көченә ышанмыйча куркып калучыларның күбрәк һәлак булуын, ә батырларның иңнди генә кыенлыкларны да җиңеп чыгуын Геройның үз мисалында дәлилләдем. Авыруның күзләрендә өмет-ышаныч чаткылары күренде. Беренче очрашу өчен бу бик җиткән иде. Чыннан да, ул сеанс гипноздан соң ул шактый ук җиңел сөйләшә башлады.

Гипнотерапия эшендә миңа матур әдәбиятны яратуым да ярдәм итә. Тукай, Такташ, Җәлил, Туфан, авылдашым Сибгат Хәким шигырьләре минем зур ярдәмчеләрем. Әдәбият күпмедер дәрәҗәдә үзе дә гипноз бит ул. Шул ук образлы сүз көче...

— Гипнозга төрле кеше төрлечә карый. Дәвалау вакытында бу хәл ничек чагыла?

— Гипноз ул — психотерапиянең бер тармагы гына. Шуңа күрә аны артык күпертеп, аның мөмкинлекләрен арттырып күзаллаучылар дәвалану чорында канәгатьсезлек күрсәтүчән. Мондый хәл килеп чыкмасын өчен мин сеанслар алдыннан яки сеанс тәмамланганнан соң биш минутлык әңгәмә үткәрәм. Башка дарулар кебек үк сүз белән дәвалау да төрле кешегә төрлечә тәэсир итә бит. Шунысы игътибарга лаек, әйбәт күңелле кешеләр гипноздан күбрәк шифа ала.

Борынгы грек философлары медицинаны сүз, үлән, пычак өстендә тора дигәннәр. Күрәсез, сүзне беренче урынга куйганнар... Йокымсыраган вакытта кеше сүзне яхшырак кабул итә. Ләкин бу кайбер җыелышларда йоклап утыручыларга кагылмый,— дип көлеп куя Мәгаз ага.

— Гипнозга бирелмәүче кешеләр буламы?

— Гомумән алганда, гипнозга бирелмәүчеләр юк. Тик ул төрле кешедә төрле дәрәҗәдә булырга гына мөмкин. Гипноз үзе — аз микъдардагы, уртача һәм тирән микъдардагы гипнозга бүленә. Ә кешеләр психологик яктан ике төрле: хыялый, ягъни хис-тойгылы һәм рациональ уйлы булалар. Аларны гади генә итеп лириклар һәм физиклар дип тә йөртәләр. Беренче төр кешеләр тирән гипнозга да биреләләр. Андыйларны гипноз ярдәмендә дәвалау җиңелрәк.

— Берьюлы ничә кешене дәваларга була?

— Мин дәвалау группасына ун-унбиш кеше алам. Шуннан артыкка китсә, эш кыенлаша. Безнең дәвалау бүлмәсе дә шул кадәр кешегә генә исәпләнгән. Коллектив белән эшләүнең үз уңайлыклары да бар. Бер характердагы авыруларның үзара аралашуы аларның рухи хәлен яхшырта, сәламәтләнүгә ышанычларын ныгыта. Коллективтагы микроклимат тәртип саклауда зур ярдәмче. Һәр эштәге кебек, безнең хезмәттә дә ныклы тәртип сорала. Мин авырулардан сеанска үз вакытында килүләрен, сеанс вакытында тулы тынычлык саклауларын таләп итәм. Чөнки әз генә тавышка да борчылучы кешеләр бар. Әгәр группада берәрсе йөткерә икән, димәк, калганнарга тынычлык юк, дигән сүз, ягъни дәваның шифасы да булмый.

— Сез үзегездә дәваланган кешеләргә киләчәккә нинди киңәшләр бирәсез?

— Төп киңәшем: сабырлыкка өйрәтү. Сабырлык — кешеләрдәге иң күркәм сыйфатларның берсе. «Сабыр төбе — сары алтын», дип халык юкка гына әйтми бит. Безнең чорда — тизләнеш чорында, фәнни-техник тәрәккыят чорында үзеңдә сабырлык, түземлелек сыйфатлары тәрбияләү гаять зарурдыр.

— Кызганычка каршы, күркәм холык бөтен кешегә дә тигез бирелмәгән шул...

— Әйе, кызу табигатьле, үз холыкларын тыя белмәгән кешеләр еш кына нерв авыруларына дучар була. Мәгәр теләге булган кеше, спорт белән шөгыльләнеп үз тәнен чыныктыра алган шикелле, рухын да яхшырта, үз тойгылары белән идарә итәргә дә өйрәнә ала. Үз-үзеңне гипнозлау аша да үз ихтыярыңны үзеңә буйсындырырга, күңелеңдә уңай тойгылар уятырга, организмыңдагы яшерен көчләрне хәрәкәткә китерергә мөмкин. Болар турында бүген бик күп газета-журналларда конкрет языла.

— Мәгаз ага, «Крутушка»да гипноз белән дәвалау кайчан башланды, аның хәзерге торышы нинди?

— 1969 елда, «Крутушка» ял йортыннан санаторийга әверелдерелгәннән соң, бер ел үткәч, мин Харьковтагы врачлар белемен күтәрү институтында булып кайттым. Анда гипноз буенча әзерлек курсларын тәмамладым. Шунда профессор Илья Захарович Вельвовскийдан дәресләр алдым. Мина Татарстандагы санаторий-курортлар идарәсе системасында беренчеләрдән булып психотерапияне башлап җибәрергә туры килде. Моның, әлбәттә, үз кыенлыклары да күп булды. Ул вакытта хәзерге

кебек яхшы җиһазландырылган кабинетларыбыз да юк әле.

Эшли башлаганнан бирле минем сменада гына да 3 мең чамасы кеше дәваланды. Бу — санаторийда дәваланучыларның уртача 15 проценты дигән сүз. Гипноз белән дәваланырга теләүчеләр саны безнең мөмкинлекләрдән күбрәк, әлбәттә. Бу инде киләчәктә бу төр дәвалау үлән һәм пычак белән дәвалауга караганда кинрәк кулланылыш табар диярга тулы нигез бар.

Әңгәмәне *Шамил Маннапов* алып барды.

ТАШ ГАСЫРДАН МИРАС БУЛЫП

Соңгы елларда кеше үзенең сәламәтлеге турында аеруча кайгырта. Борынгы халык медицинасына, төрле үләннәр, табигый чаралар белән дәвалануга игътибар артты. Һиндстан йоглары, аларның могҗизага тиң физик сәләтләре, борынгы Кытай табибларының инә кадап дәвалау ысуллары белән кызыксынучыларны торган саен еш рак очратасың. Шушы чаралар арасында инә кадап дәвалану (фәнни телдә ул рефлексотерапия яки акупунктура дип йөртелә) аерым урын тота. Бу хакта киңрәк мәгълүмат алу өчен без Казан ГИДУВының рефлексотерапия кафедрасы хезмәткәре Рәшит Шәкүрович Шәкүровка мөрәҗәгать иттек.

— Рәшит Шәкүрович, инәнең могҗизалы көче бик борынгы заманнарда ук билгеле булган дип ишеткәнебез бар, аның сихәт бирү көченә ия булуы безне хәтта гаҗәпләндерә дә. Көнчыгыш табиблары мирас итеп калдырган бу «могҗиза»га соңгы елларда игътибар артуны ничек аңларга?

— Инә кадап дәвалану чал тарихка барып тоташа. Риваятьләргә караганда, ул таш гасыр чорында барлыкка килгән. Аның туган иле — Кытай диләр. Шул чорда ук инде кеше акылы авыртуларны төрле чәнчүләр, көйдерүләр ярдәмендә басу мөмкинлеген яхшы үзләштергән. 5000 еллык тарихы булган менә шушы рефлексотерапия яки икенче төрле әйткәндә акупунктураның чәчәк аткан чоры да, онытылып торган дәверләре дә, дин, мистика белән бәйләнешле тыелган вакытлары да булган. Шулай

да ул безнең көннәргәчә әһәмиятен югалтмыйча килеп җитте. Меңнәрчә буыннарның тәҗрибәсе белән бастылган бу дәвалау чарасы бүген үзенең икенче яшьлеген кичерә. Ни өчен дисезме? Аның сәбәпләренә тукталыйк. Хәзерге фәнни-техник революция чорында медицина өлкәсендә дә янадан-яна ачышлар туып кына тора; авыруларны дәвалауның нинди генә чаралары, даруларның нинди генә төрләре юк хәзер. Әмма аларның кеше организмына зыянлы йогынтысы да булуы беленде. Әйтик, берәүгә шифа биргән даруны икенче берәү кабул итә алмый, ул анда аллергик реакция китереп чыгара. Ә соң моннан котылу яки химик даруларның зарарлы йогынтысын киметү юллары бармы? Шушы сорау галимнәрне борынгы халык медицинасына мөрәҗәгать итүгә, аларның тәҗрибәсен җентекләп өйрәнүгә этәрә. Инә кадап дәвалау ысулының гадилеге, төрле авырулар вакытында хәлне җиңеләйтүе, өстәмә реакцияләр тудырмавы, организмга бернинди зыян китермәве элек-электән галимнәрнең игътибарын үзенә тарткан.

— Инә белән дәвалауның файдасы нидән гыйбарәт соң?

— Бу методның файдасы бәхәссез икәнлеге күптән мәгълүм булса да, аның организмга йогынты ясау механизмы әлегә тулысынча өйрәнелеп җитмәгән. Кеше организмында биологик актив нокталар булуы да (алар 600 дән артык дип исәпләнә) фәнгә күптәннән билгеле. Авыруның төренә карап, врач менә шул нокталарга тәэсир итә. Нәтиҗәдә кеше организмында гаять катлаулы биохимик үзгәрешләр барлыкка килә, баш мие эшчәнлеге активлаша, авыруның хәле сизелеп яхшыра. Акупунктураның мөмкинлекләрен өйрәнү дәвам итә. Бу юнәлештә фәндә яңадан-яңа мәгълүматлар белән очрашып торабыз.

— Инә кадап дәвалау нинди авырулар вакытында аеруча яхшы нәтиҗә бирә?

— Төрле нерв системасы авырулары — радикулит, неврозлар, невралгия, неврит, кан тамырлары дистониясе, аллергия авырулары һ. б. авырулар вакытында инә кадап дәвалау аеруча уңышлы. Рефлексотерапия ярдәмендә чукраклыкны дәвалау, ягъни ишетү сәләтен яхшырту очраклары бар. Шулай ук остеохондрозның катлаулануы нәтиҗәсендә хезмәткә сәләтен югалткан авыруларны яңадан сафка бастыру очраклары да билгеле. Шунысы әһәмиятле: башка төр дәвалау чаралары ярдәм итмәгән очракларда рефлексотерапия уңай нәтиҗәләр бирә. Соңгы вакытларда хирургик операцияләрдә авыртуны басу

өчен рефлексотерапия киң кулланыла башлады. Көчле авыртуларны аның ярдәмендә озак вакытка туктатырга мөмкин.

— Ә бәлки, рефлексотерапия авыруны дәваламый, вакытлыча туктата торган чара гынадыр?

— Киресенчә, башта әйткәнемчә, аның дәвалау көче гаять зур. Безнең институтның берничә еллык фәнни-тикшеренү мәгълүматларына таянып шуны әйтергә мөмкин: рефлексотерапия белән дәвалау 60—95 процент очракта уңай нәтиҗә бирә. Рефлексотерапия әле ул авыруны дәвалап кына да калмый, ә бәлки организмның саклагыч функцияләрен дә арттыра.

— Рәшит Шәкүрович, халык арасында шундый сүз дә йөри: имеш, инә теләсә нинди авыруга каршы иң ышанычлы дәвалау чарасы. Аның белән бөтен авыруларны җиңәргә була...

— Әкияттәге кебек, бер селтәнү белән генә теләсә нинди авыруны җиңеп булса иде. Медицина могҗиза түгел бит ул. Мәсьәләгә чынбарлык аша, җитдирәк карарга кирәк. Инә кадап дәвалауның уңышы күп сәбәпләргә бәйле булын онытмыйк. Монда авыручы кеше организмының үзенчәлекләре, яше, чиренең нинди стадиядә булуы, ниһаять, врачның осталыгы — болар барысы да әһәмиятле роль уйный. Аннары рефлексотерапия кемгә, нинди очракта кулланыла бит. Шешләр булганда, йогышлы авырулар вакытында аны куллану зыян китерергә мөмкин. Гомумән, бу очракта ул ярамый да.

— Рефлексотерапия үзенең тамырлары белән таш гасырга барып тоташа дидек. Ул чордан бирле ул үзгәрешсез калмагандыр, мөгаен?

— Әлбәттә. Заман белән бергә бу дәвалау чарасы гасырлар дәвамында камилләшә барган. Инәләр дә шулай ук үзгәреш кичерә килгәннәр. Таштан, сөяктән, бамбуктан, тимердән эшләнгән инәләр булган. Хәзер алар махсус корычтан эшләнәләр. Кеше организмындагы кирәкле нокталарны сайлый белүдә дә, тәэсир итү төрләрендә дә элеккеге белән чагыштырганда аерма зур. Элек, мәсәлән, нокталарга тәэсир итүнең төп өч төре билгеле булган: инә кадау, көйдерү, нокта массажы. Ә бүгенге тәэсир итү ысуллары 20 дән артып китә. Алар арасында дару белән тәэсир итү дә, ультратавыш та, электр энергиясе, нурлар, төрле шартлар һ. б. әйберләр кулланыла.

(Рәшит Шәкүрович инәләренең бүгенге арсеналын күрсәтә. Алар арасында нинди генә формадагылары юк: озыны, кыскасы, нечкә инәләр... «Ә менә бусы — Кытайдан

алып кайтылган,— ди ул, бер тартмага күрсәтеп,— ә бусы — Япониядә эшләнгән әрем сигарасы, ул яндыру өчен кулланыла»).

— Рефлексотерапия буенча белгечләр кайда әзерләнә?

— Рефлексотерапия үзәкләре Союзда берничә. Шул исәптән безнең Казанда да бар. Безнең Казан институты бу юнәлештә ел саен 150 ләп белгеч әзерли.

— Безнең республикада кайсы больницаларда инә белән дәвалану курсын үтәргә мөмкин?

— ГИДУВ каршындагы махсус клиника — рефлексотерапия буенча иң зур дәвалау учреждениеләреннән берсе. Моңардан тыш, В. В. Куйбышев исемендәге «Тасма», С. П. Горбунов исемендәге авиация производство берләшмәләре больницаларында, республика, психиатрия клиникаларында, шулай ук Алабуга, Әлмәт, Лениногорск шәһәрләрендә рефлексотерапия кабинетлары эшли. Аларның челтәре киңәя бара. Якын киләчәктә бу төр дәвалануга мохтаҗ авырулар һәр поликлиникада тиешле дәвалану курсын үтә алырлар дияргә нигез бар.

Әңгәмәне *Рина Зарипова*
алып барды

ЧӘЧӘКЛӘР

Луиза үзенә яшәү өчен көч, ышаныч биргән докторына бүләк итү өчен иң матур чәчәкләрне сайлап алды.

Менә ул бер кочак аллы-гөлле чәчәкләрен күтәреп ашыгыч ярдәм күрсәтү больницасына (Казанның элеккеге 15 нче шәһәр больницасы) юнәлде.

Бара-бара уйлары, ихтыярсыздан, әлеге больницада авырып яткан көннәренә килеп тоташты. Кинәт кенә үпкәсе авырта башлаган иде. Шунда ул яткан палатага, консультант буларак, озын гына буйлы, төз гәүдәле, мөлаем йөзле врач Илдус Әнвәрович Лотфуллин чакырылган иде. Ул, Луизаны карагач, бик күп акыллы киңәшләрен бирде. Терапия бүлегенең йөрәк авырулары белгече булса да, баксаң, беренче кандидатлык диссертациясе үпкә авыруларына бәйле икән... Ул палатага килеп кергәч, авыруларның йөзе ачылып китә, аңа үз итеп мөрәҗәгать итәләр. Гадилеге, тыйнаклыгы да күңелне тарта, күрәсең. Чөнки

ул кешеләр янында үзен һәрвакыт гади, тыйнак тота. Руслар белән русча, татарлар белән исә матур итеп татарча сөйләшә. Шуңа күрә дә аны олы кешеләр аеруча якын итәләр.

Бер көнне ул палатада Хәнифә әби нәрсәгәдер кәефсезләнеп, тәрәзәгә таба карап сөйләшми утыра иде. Русча гына сөйләшкән бер татар шәфкать туташы белән иртән нидер аңлашып бетә алмаганнар, ахры. Илдус Әнвәрович палатага керүгә әбинең киеренке халәтен тоеп алды, аңа ягымлы тавыш белән татарчалап дәште:

— Әби! Сиңа нәрсә булды?

Көтелмәгән бу хәлдән әби дәррәү врачка борылып карады һәм күңеле сөенгән баладай ачылып:

— И-и, балам, татар икәнсең әле...— дип ул җанланып китте, үз хәлен сөйләргә керешге. Үзен сабыр гына тыңлап, терелтергә ышандырып чыгып киткәч, Хәнифә апаның күзләренә, куанычтан, яшьләр килде.

Ул вакытта Луиза да больницадан әби белән бер үк көнне терелеп чыккан иде. Бер ел чамасы узгач, ул шушы сукмаклардан янә әлеге больницага атлады. Күңеле сүрелеп төшкән көн иде. Аңа участок поликлиникасында, үпкә белән авыруын искә алып, бала табарга рөхсәт итмәделәр. Ә аның бер генә булса да бала үстерәсе килә бит. Тормыш иптәше дә шуны тели... Ниһаять, аның тәләкләрен тыңлап бетергән Илдус Әнвәрович: «Мөмкин,— дип телгә килде.— Әмма мин биргән киңәшләрне тотыгыз...»

...Ишекне әкрен генә шакып, рөхсәт алгач, Луиза профессор бүлмәсенә бер кочак чәчәкләрен күтәреп керде һәм чәчәкләредәй ачык елмаеп берничә адым алга атлады.

— Илдус Әнвәрович! — диде ул.— Сезгә чәчәкләр китердем... Онытмадыгызмы, бүген бит улымның туган көне...

Урыныннан җәһәт кенә купкан яшь профессорның аксыл йөзе, нигә инде шулай ел саен чәчәкләр китереп мине уңайсыз хәлгә куясыз дигәндәй, ни әйтергә дә белми, комач кебек кызарды һәм чәчәкләрне кабул итеп алды.

— Рәхмәт. Рәхмәт инде...

— Үзегезгә рәхмәт...

Луиза Нербекова белән саубуллашкач, Илдус Әнвәрович йөрәге авыртуыннан зарланып килгән кырык яшьләр тирәсендәге бер чал чәчле ирне кабул итте. Ул фәнни-тикшерену институтыннан икән. Һөнәре — математик...

Профессор каршына утырган авыруга башта берни дәшми карап торды. Ул аның эчке халәтен, характерында чагылган бар нәрсәгә игътибар итте: йөз, иреннәр төсенә,

күз карашларына... Кешенең йөзендә һәртөрле авыруның да үз билгеләре чагыла. Син аларны күрә һәм тоемлый гына бел...

Аннан профессор аның кан басымын үлчәде, йөрәк тибешен тыңлады... Шулай бик җентекләп тикшергәч, профессор үз диагнозын әйтте:

— Юк, сезнең йөрәгегез авыртмый... Сез аз хәрәкәтләнәсез, күрәсең. Остеохондроз бар, шул борчый... Мин сезгә бернинди дә дару бирмим. Акыл хезмәтендәге киеренкелекне бетерү өчен иртә-кич күнегүләр ясый башлагыз...

Бу көнгә язылган авыруларны кабул итеп бетергәч, бүлмә эче тынып калды. Илдус Әнвәрович, бераз тынычланып, Тукай рәсеменә текәлде. Шагыйрьнең бөеклеге белән рухланды, шул ук вакытта яшьли ятим калып үпкә чиреннән авырып үлгән уйлап, кызгану хисе кичерде. Хәзер булса, һичшиксез, коткарырлар иде бөек шагыйрьне!

1971 елда ук Илдус Әнвәрович «Канда һәм тәндә электролитлар балансы» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклаган иде. Аннары йөрәк авыруына кагылышлы мәсьәләләрне өйрәнергә кереште. Бик кирәкле тема. Бүгенге көндә йөрәк-кан тамырлары авырулары, ягъни кан әйләнеше бозылуы нәтиҗәсендә хасил булган миокард инфаркты, стенокардия авыруы сәламәтлекнең беренче дошманнарыннан санала. Илдус йөрәк серләрен эзләнү юлында ару-талуны белмәде. Эшен дәвам итәр өчен, чираттагы ялын алгач та Мәскәүгә китте, СССР Медицина фәннәре академиясенең фармакология институтына килде. 1985 елда Дәүләт премиясенә лаек булган профессор Наталья Вениаминовна Каверина лабораториясендә тәҗрибәләр үткәрде. Эше һаман да шул миокард инфаркты авыруы проблемаларына кагылышлы. Инде иллегә якын фәнни хезмәтләре үзәк матбугатта — «Кардиология», «Терапевтический архив», «Клиническая медицина» һәм башка журналларда дөнья күреп өлгергән. Әмма докторлык диссертациясен яклар өчен тәҗрибәләр ярдәмендә ачыклыйсы нәрсәләр дә күп иде әле. Миокард инфаркты белән авыручыларның 90 процентка якыны тискәре эмоцияләр тәэсирендә туганлыктан, ул биргә ми күзәнәкләрен өйрәнүдән башлаган эшен дәвам иттерергә килгән иде... Күп йокысыз төннәр бәрабәренә уздырылган тәҗрибәләреннән чыгып язган фәнни хезмәте китап булып басылып чыкты.

Ниһаять, ул Мәскәүдә «Миокард инфарктын өйрәнү һәм дәвалау проблемалары»на багышланган темага докторлык диссертациясен яклады. Казан галимен, яшь док-

торны Мәскәү урамнарында иң беренче булып май кояшы котлады. Ике сәгатькә сузылган киеренкелектән соң җаны җиңеләеп калды. Уй-фикерләренең тулысынча дөрескә чыгуына янә бер кат инанудан, аларны бүтәннәр алдында нигезле дәлилләп бирә алудан канәгатьлек хисе кичерде ул. Бу аның үз-үзен исбатлавы да иде...

Ә алда күпме авыруларны савыктырасы бар. Аларның моңсу күзләрендә яшәү өмете, җан гозере чагыла бит. Шунысы үкенечле, әнисе Мөнирә апа гына улының фән докторы булып ирешкәнен күрә алмады. Улының зур эш белән мәшгуль икәнен белә иде ул белүен...

...Вакыт көндезге икегә авышкан иде. Профессор Илдус Әнвәрович Луиза китереп киткән чәчәкләргә янә бер күз төшереп алды да медицина институтына — студентларга лекция укырга ашыкты. Аны инде бүтән уйлар биләгән: лекцияләрнең тематикасын үзгәртәсе иде, тирәнрәк, эчтәлеклерәк итәсе, булачак врачларның белемнәрен тирәнәйтәсе, үз һөнәрләренең җаваплылыгын аңнарына тагын да ныграк сеңдерәсе иде.

Туктальш чатында аңа кайчандыр үзе дәвалаган пенсионер карт очрады. Бакчадан кайтып килеше икән. Илдус Әнвәровичны күрүгә кабарынкы калын кара кашларын тибрәтеп елмайды:

— Исәнмесез, доктор!

— Исәнмесез!.. Сәламәтлекләр ничек?

— Йөрәк эшли, йөреп торам менә.

— Әйбәт, әйбәт...

Аерылып киткәч тә бу карт аның хәтереннән тиз генә чыкмады, моннан берничә еллар элек булган хәлне кабат исенә төшерде.

Үзен бик тә начар хәлдә шәһәр больницасына китерәләр. Врачлар диагноз куюда икеләнеп калалар. Шул вакыт лекция укырга килгән Илдус Әнвәрович белән киңәшләшеп алырга булалар. Илдус Әнвәрович авыруны карау белән: «Инфаркт алды хәлендә»,— ди. Йөрәк кардиограммасында нинди үзгәрешләр булырга тиешлеген дә әйтә. Нәтиҗәдә шулай килеп чыга да. Авыруны ул үзе эшләгән больницага озата, дәвалый. Шуннан бирле бу карт үз бакчасындагы гөлләренең беренче чәчәкләрен ел саен аңа китерми калмый.

Нурислам Хәсәнов

МЕНӘ ИЧМАСАМ МОГҖИЗА!

Без могҗизалар заманында яшибез. Хәзер инде гадәти булмаган күренешләргә дә күнегеп барабыз шикелле. Шуңа күрә Әминә Аралбаева һәм аның үзенчәлекле дәвалау алымнары хакында ишеткәч тә әллә ни гаҗәпләнмәдем. Ә менә аның белән очрашып, тылсымлы кулларының йогынтысын үземдә тойгач таң калдым. Ул, кулларын тәнгә тидерми генә, баш түбәсеннән кулбашка таба, гәүдә буйлап йөртте. Тәнем буйлап җылы дулкын йөгереп үтте. Һәм ул, һич ялгышмый, минем ни дәрәҗәдә сәламәт булуым, йөрәк-кан тамырларымның, эчке органнарның эшчәнлеге хакында әйтеп бирде. Ышанмыйм, Әминә берничә минут эчендә диагноз куйган чирләрне ачыклау өчен миңа шактый вакыт бер врачтан икенчесенә йөрергә, байтак кына анализлар тапшырырга туры килде. Юк, бүгенге медицинаның әһәмиятен кечерәйтергә, врачларның дәрәҗәсен түбәнәйтеп күрсәтергә яисә аларны экстрасенсларга каршы куярга җыенмыйм. Шулай да Әминә Сөләймановнадагы сәләт мине гаҗәпләндерде. Мөлаем, балаларча ягымлы карашлы Әминәнең тылсымлы көчен аңлау өчен аның белән якыннанрак танышу теләге биләп алды күңелемне.

Медикларга шундый инану хас: күп нәрсә кешегә геннар белән бирелә дип аңлаталар. Әминәнең дә бар булмышы шуны расларга җирлек бирә. Аның дәү әнисенең әнисе дә кеше сәламәтлегенә йогынты ясардай көчкә ия булган. Тирә-яктан төрле авыруларны алып килә торган булганнар үзенә. Карчык бигрәк тә алмашынган, ягъни медицина теле белән әйткәндә, психик авыруларга уңай тәэсир ясый белгән. Шул ук вакытта күрәзәчелек итү сәләтенә дә ия булган ул. Димәк, Әминәдәге экстрасенсор сыйфатлар буыннан-буынга килгән дияргә җирлек бар.

Әйе, без экстрасенсларга тик табигать биргән гаҗәеп күренеш итеп кенә карарга өйрәнгәнбез. Әминә Сөләймановна исә башкачарак фикердә.

— Без гаҗәп чорда яшибез, тормышның тизлегенә ияреп тырышабыз,— дип башлады ул сүзен.— Шуңа да безнең үз-үзебезне «тыңлап» карарга, эчке дөньябызның тирәлек белән бәйләнешен күзәтергә вакытыбыз юк. Ә бит якынча һәр илленче кеше экстрасенсор сыйфатларга ия. Тикшеренүләр шуны күрсәтә.

Мине иң элек Әминә Сөләймановнаның үзендә әлеге сыйфатларның кайчан беленә башлавы кызыксындырды.

Гади авыл баласы. Башкортстанның Учалы районы Ураз авылында туып-үсә ул. Соңрак аларның гаиләсе Белорет районына күчеп килә. Әнисе Камилә апа өч баланы аякка бастыру өчен көчен кызганмый. Анардагы эш сөючәнлек, ихтыяр көче кызына да күчә. Балачактагы шундый күренеш хәтеренә уелып калган Әминәнең. Әнисе эштән арып-талып кайтып керер дә кызын үз янына чакырып алып: «Балам, маңгаема кулыңны куеп тор әле»,— дияр иде.

Күрәсең ана кеше шул чакта ук кызының нәни кулларында тәненә сихәт бирердәй көч тойгандыр. Ләкин әле халыкта танылу тапкан чын экстрасенс дәрәҗәсенә күтәрелгәнче шактый катлаулы тормыш юлы үтәргә, зур көч салырга туры килә аңа. Мин аның белән булган әңгәмәдән шуны аңладым: экстрасенс булу өчен ифрат зур ихтыяр көче кирәк.

...Әминә Уфадагы художество интернат мәктәбен тәмамлагач, журналист булырга хыяллана. Ләкин язмыш киләчәкне үзенчә билгели. Ул башта фабрикада эшли. Аннан соң үзенең чыдамлылыгын, ихтыяр көчен сынау теләге аны шәһәр больницасының хирургия бүлегенә алып килә. Санитарка булып урнаша ул. Дөньядагы иң гуманлы һөнәр — медицинаны сайлау теләге дә шулчак тугандыр, мөгаен, күңелендә. Әминә медицина училищесына укырга керә һәм аны «бик яхшы»га тәмамлый. Ләкин сайлаган һөнәр кысаларында гына бикләнеп калмый ул: шигырьләр яза, рәсем төшерә, Сибай шәһәр газетасының актив эшче-хәбәрчесе була. «Ирәндек» иҗади берләшмәсендә шөгыльләнә.

Әминә медицина училищесында укыганда үзендә сәер бер хис тоемлый башлый. Күп кешеләрнең бер төрле уйлап та, икенче төрле сөйләгәннәренә төшенә. Әлбәттә, ул башта мондый сәләт бөтен кешедә дә бардыр дип уйлый. Ул чагында ни өчен соң алар кешеләрнең мондый гадәтенә гаҗәпләнмиләр? Шушы сорау аңа озак вакытлар тынгы бирми йөдәтә. Ахыр килеп аңлый: «кешене ачыктан-ачык күрү» — аның үзенә генә хас сыйфат икән ләбаса.

Училищены тәмамлап, бала тудыру йортында эшли башлагач, тагын бер нәрсәгә таң кала Әминә. Баксаң, яңа туган сабыйларның һәркайсының үзенә генә хас исе бар икән. Ул аларның исен шулкадәр ачык тоемлый һәм шул рәвешле үзләрен тиз генә таный, аера ала.

Бераздан аңа Сибайда Кызыл Хач җәмгыятенең патронаж медицина сестрасы вазифасын йөклиләр. Ярдәмгә мохтаҗ олы яшьтәге кешеләргә медицина ярдәме күрсәтү,

аларның хәлен җиңеләйтү һәм булышу өчен, иң беренче чиратта, ихлас күңелле, кешелекле булырга кирәк. Әминә нәкъ шул сыйфатларга ия дә инде.

— Балам, син килеп керсәң, дарусыз да хәлем җиңеләя,— дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә аңа.

Ул әлеге сүзләрне, әлбәттә, күңел өчен әйтелгән итеп кабул итә. Әмма үзендәге сәер бер тоемлау үзенчәлекле нәтиҗә ясарга мәҗбүр итә. Авырулар җиңеллек тойган бер вакытта, Әминә аларның авыртуын үзе кичергәндәй була.

Ә бервакыт моның, чыннан та, шулай икәненә ышандырырлык вакыйга була. Оны булырга җыенган Әминәгә врачлар больницага кереп бераз ныгып чыгарга киңәш бирәләр. Ул больницага ята. Ничәдер көн үтүгә шушы ук палатага икенче бер авыруны китерәләр. Хатынның хәле авыр, аякларын чак-чак атлап керә иңсектән. Әминәгә ул ифрат кызганыч тоела. Бар күңелен авыруның хәлен җиңеләйтү теләге биләп ала. Ул бөтен игътибарын шушы авыру хатынга туплый һәм аның бар халәтен үзенә күчергәнен сизми дә кала. Әминәне больницадан әлеге хатынның диагнозлары белән дәвалап-дәвалап та терелтә алмыйча чыгаралар. Ул урыныннан тора алмас хәлдә була. Медицина хезмәткәре буларак, врачлар куйган диагнозның үзе һәм туачак баласы өчен никадәр куркыныч булуын яхшы белә ул. Ләкин үз-үзен кулга алып, ихтыяр көчен җигеп, чир белән алыша башлый. Моның өчен шактый вакыт кирәк була. Кеше организмында зур запас көч булуын үзендә исбатлый ул. Ниһаять, аякка баса. Хәтта аңа диагноз куйган врачлар да таң кала.

Югарыда сөйләгәннәрдән чыгып шуны әйтәсе килә: Әминә үз организмының үзенчәлекләрен һәм мөмкинлекләрен тирән өйрәнә, үстерә, эшкә «куша» белә. Әлбәттә, экстрасенс булып формалашуда, табигый талантттан тыш, боларның да әһәмияте зур була.

Әминә Аралбаеваның югарыда әйтеп киткән сүзләрен искә төшерик. Экстрасенсор сыйфатлары һәр илленче кешедә дә бар, ди ул. Ләкин ни өчен соң Джуна һәм Әминәләр илдә санаулы гына?

— Чөнки әлеге сыйфатларны үстерергә һәр илленче кешенең барысы да сәләтле түгел,— дип аңлатма бирде Әминә Аралбаева бу соравыма.

Шулай да ничек экстрасенс булырга һәм үзеңнең мөмкинлекләреңне эшкә кушарга өйрәнергә соң? Күпләрне кызыксындырган әлеге сорауга җавап бирер алдыннан Әминә Сөләймановна бер вакыйганы искә алды. Ул үз тәҗри-

бәсен башкалар белән уртаклашу максатында Сибайда курслар оештыра. Аның беренче этабында ук 30 дан артык кеше йөри. Арада төрле һөнәр ияләре була. Курслар тәмамланып килгәндә, бер фельдшер хатын Әминәнең каршына килеп баса да:

— Мин ачыктан-ачык сезнең эчке органнарыгызны күрәм,— ди. Һәм ничек булса шулай аңлата да башлый. Әминә хакыйкатьне раслау өчен аның белән берничә тәҗрибә үткәрә һәм әлеге фельдшерның сәләтенә ныклап ышана. Әлеге ханым моңа кадәр үзенең шундый үзенчәлекле кеше булуы хакында башына да китермәгән. Аралбаева дәресләре аңа үзенең табигый булмышына игътибарлап карарга, талантын ачарга булышлык иткән. Хәзер остазыннан шул көчне эшкә җигәргә өйрәнә.

Гадәттә экстрасенслар турында сөйләгәндә сүз үзеннән-үзе биологик кыр төшенчәсенә барып тоташа. Билгеле булганча, биокыр һәркемдә, хәтта хайваннарда да һәм үсемлекләрдә дә, тере булмаган предметларда да бар. Ләкин һәркемдә һәм һәрнәрсәдә ул үзенчәлекле. Анда кешенең эчке халәте, эмоциясе, хәтта күңеленнән генә уйлаган фикерләре дә чагыла. Әйтик, кешенең көчле эмоциональ кичерешләре вакытында аның эчке вибрацияләре радиусы 1,70 метр булган киңлеккә кадәр тарала. Әминәнең төп дәвалау принцибы шунда — ул биологик кырны тоемлый, хәтта күрә һәм шушы тирәлек аша үзендәге энергия белән кеше организмына тәэсир итә.

Экстрасенслар үзләренең хезмәтен дөньядагы иң авыр эш дип билгели. Ни өчен?

— Чөнки пациентны «пычрак» энергиядән арындырырга һәм үзең аша саф энергия бирергә кирәк,— дип, үзенчә, гади генә итеп аңлата Ә. Аралбаева.— Бу мәлдә экстрасенсның үзендәге каналлары «пычрана». Дәвалау процессы тәмамланганнан соң, аларны җентекләп «тазартырга», савыктырырга кирәк. Чөнки пациентның халәте үзеңә үк күчүе бик ихтимал...

Экстрасенс — ачыктан-ачык күрү һәм тоемлау белән беррәттән, физик яктан сәламәт, тәмәке тарту, аракы эчү кебек начар сыйфатлардан азат булырга тиеш. Даими физик күнегүләр ясау, йөгерү, саф һавада кышын-җәен салкын су белән коену, карлы юлда яланаяк прогулкалар — Әминәнең күптән гадәтенә кергән.

Экстрасенс берсүзсез медицина белгече булырга тиеш дип фараз итә кайберәүләр. Чынлап та, ул медик яисә медицина фәне белән таныш булса, аеруча яхшы, дип

исәпли Әминә. Ләкин шундый очраклар да кабатлана: экстрасенс-медиклар стереотиплашучан.

Шушы уңайдан бер фикер әйтәсе килә. Безнең илдә экстрасенсларның роле әлегә тиешенчә бәяләнми. Мисалга Әминә Сөләймановнаны алыйк. Халыкта күптән танылу тапты ул. Башкортстанның Сибай шәһәренә илнең кайсы гына төбәкләреннән килмиләр хәзер. Кызыл Хач җәмгыятендә Әминәгә унбишәр-уналтышар сәгать эшләргә туры килә иде. Чөнки эш сәгатендә генә авыруларны кабул итеп бетерү мөмкин түгел иде аңа. Шуңа күрә ул төп эшен калдырып биш кешедән торган «Тонус» кооперативы ачты. (Аңа бу эштә шәһәр элемтә бүлеге житәкчеләре ярдәм итте.) Иң беренче чиратта балаларны кабул итү хәстәрлеген күрә. Үз мөмкинлегеннән чыгып, килүчеләрне чиратка куя. Авыруларның исемлеге 1997 елга кадәр төзелгән. Дәвалаучылар белән әңгәмә, анкета мәгълүматларына караганда, йөрәк һәм кан тамырлары, бөер, распиратив авырулар, ангина, кылый күзлелек, операция үткәрелмәгән глоукома, ашказаны-эчәк авырулары, эпилепсиянең кайбер төрләре һәм башка чирләрне дәвалауда Әминә Аралбаева үз мөмкинлекләрен уңай раслаган. Ә уйлап карасаң, бу чир белән жәфа чигүчеләр азмыни?!

Кооператив үз табышы хисабыннан «Бион» аппаратурасы сатып алды. Диагностика һәм дәвалау өчен компьютер сатып алу хакында да хыялланалар алар. Киләчәктә Урал аръягы зонасында үзенчәлекле дәвалау үзәге оештырырга исәпләре.

Кеше табигатенең һәм әйләнә-тирәлекнең серләрен ачкан бер вакытта экстрасенслар үзләре үк өйрәнүгә мохтаж. Чөнки алар — әлегә ачылмаган серле бер дөнья. Дөрес, бу юнәлештә Уфада оештырылган уфология секциясе ниндидер дәрәжәдә эш алып бара. Ләкин эзләнү һәм тикшеренүләр фәнни системага салынып эзлекле төс алырга тиеш. Бер нәрсәне хәтердән чыгармыйк. Хәзер кайбер илләрдә врач белән экстрасенс янәшә-иң торып эшләргә тиеш, аларның тыгыз хезмәттәшлеге кирәк дип саныйлар. Ә нигә бу тәҗрибәне безгә дә өйрәнмәскә?

Соңгы вакытта без экстрасенслар исемлегендә яңадан-яңа исемнәр белән танышабыз. Ләкин аларның барысы да дәвалауга хокуклымы соң? Моңа Әминә Сөләймановнаның үз фикере бар.

— Һәр очракта да пациентның сәламәтлегенә тик уңай йогынты ясаган экстрасенс кына бу хокукка ия,— ди ул.

Әминә Сөләймановна инициативасы белән Сибайда оештырылган курсларның максаты — кешеләргә табигать

законнарына тирәнрәк төшенергә булышлык итү, кеше организмының мөмкинлекләрен ачу, алган белемнәрне эштә, көндәлек тормышта кулланырга өйрәнү.

К. Гыйлаҗева

АЮЛАР, БАКАЛАР... ҺӘМ КОШЛАР ДОКТОРЫ

Казан зооботаника бакчасы ике өлештән тора. Капкадан кергә безне аллы-гөлле чәчәкләр каршылый. Алар матурлыгына, хуш исенә сокланып бара-бара, пыяладан эшләнгән мәһабәт оранжерея янына килеп чыгасың. Монда нинди генә үсемлек, нинди генә агач юк. Әйтерсең Африка джунглие, гаҗәеп бер экзотика!

Бакчаның икенче өлеше кошлар, җәнлекләр өчен. Алар биш секциягә бүленгән: тояклылар, маймыллар, кошлар, вак һәм эре ерткыч җәнлекләр, балыклар һәм сөйрәлүчеләр.

Як-яклап тезелеп киткән читлекләрдәге бу кошларны, җәнлекләрне күрергә җәйге айларда һәр көнне 500—600 кеше килә. Бигрәк тә балаларның яраткан урыны зообакча. Аларны вольердагы һәр җан иясе сау-сәламәт, тук, чиста, көр күңел белән каршыларга тиеш. Зообакча хезмәткәрләре әнә шуның өчен тырыша. Монда, билгеле, ветеринария белгеченең роле аеруча зур.

— Балачактан табигатьне, хайваннарны ярата идем,— дип сүз башлый ветеринария врачы Галина Евгеньевна Комарова.— Ветеринария институтына укырга кердем. Аны тәмамлагач, фермада эшли башладым. Ләкин, мөмкинлек булу белән, бирегә күчтем. Зоопаркта эшләүне, килеп күреп киткәндәгечә, күңелле итеп кенә күз алдыма китергәнмен. Ә мондагы эш катлаулы да, җаваплы да, житди дә икән. Колхоз фермасында 5—6 төрле хайван, 4—5 төр кош-корт белән генә эш итәсең. Ә бирегә алар йөздән артык.

Бакчада беренче кыенлык белән очрашу шул булды: Вента кушаматлы филнең табан-тырнакларындагы хроник авыруны дәвалый алмый җәфаландым. Һәм, ниһаять, Казан ветеринария институты профессоры Вера Поликарпов-

на Кибалкина минем үтенечем буенча ана дару тапты. Филне тәрбияләүче эшче белән шул майны сөртәбез дә, фил аякларына капчык кидертеп куябыз. Шулай итеп Вентаның гомерен саклап калдык.

— Эре ерткыч җәнлекләр авырганда аларга йоклаткычлар биреп якын киләсезме?

— Юк. Тынычландыручы препаратларны төрле кеше төрлечә күтәрә. Җәнлекләр дә шулай. Аны кулланганчы, башта хайванның аны ничек кабул итүен сынап карау (проба) аша белергә кирәк. Ә безнең бакча җәнлекләр физиологиясе өстендә фәнни-тикшеренү эшләре алып бармагач, лабораториябез дә авыруларга диагноз кую өчен яраклаштырылмаган.

Эре ерткыч җанварлар авырса, аларны кысан читлеккә кертеп яки бәйләп карыйбыз.

— Бакалар салкын тиеп авырыйлармы?

— Тән температурасы түбән булган бака, еланнарда шеш авыруы еш була. Ә менә ташбакага салкын тия. Һәм аны дәвалау нәкъ кешеләрдәгечә, тик дарулар дозасы гына башка.

— Галина Евгеньевна, сезгә җәнлекләрне үрчетү буенча план житкереләме?

— Җиткерелә. Тик моның өчен шартлар һәм уртак мәхәббәт кабынган парлар кирәк. Мәсәлән, соңгы үндүрт елда маймыллардан нибары бер мәртәбә үрчем алдык. Алар яр сайлауга аеруча талымлы.

Ак аюларыбыз исә бер-берсен бик яраттылар. Һәр елны бер яки ике нәни йөнтәс «алып кайталар».

Шулай ук икесе ике җирдән кайтарылган бегемотлар тиз арада «үрнәк гаилә төзеделәр». Беренче карашка шыксыз, иләмсез тоелган бу хайваннарда балага мәхәббәт көчле икән. Без моны дөньяга яңа бегемот тугач аңладык. Кызганычка каршы, саклау өчен шартлар җитешмәү сәбәпле, ул салкын тиеп үлеп китте. Ә безне, аның үлеменнән бигрәк, шушы кайгыдан аяктан егылган ана бегемотның хәсрәтләнүе тетрәндерде. Берничә көн ашамый-эчми ятты да, үзе дә үлде. Авырганда да, соңыннан да тикшереп карадык, әмма бернинди чирен таба алмадык. Ә Карлсонга (ата бегемот) шуннан бирле яр таба алганыбыз юк әле. Ул да кайгыдан арынып җитә алмый, күрәсең, үзен карарга килүчеләргә дә исе китми, моңсу-ямансу гына яши бирә.

— Димәк, парсыз яшәү җәнлекләр өчен дә шатлык түгел.

— Шул ук маймыллар, мәсәлән, депрессиягә (күңел

төшенкелэгенә) бирелэләр. Карарга килүчеләрне күрәселәре килми, артлары белән борылып утыралар. Вакыт-вакыт хәтта ашаудан да калалар.

— Моңа дәва бармы?

— Мондый очракта дару ярдәм итми. Дәва бер: иркәлибез, назлыйбыз. Яраткан ризыклары — лимон, апельсин, банан белән сыйлыйбыз. Хәер, җылы мөгамәләне, назлап дәшкәнне бөтен җәнлекләр дә ярата. Һәм киресенчә. Моннан берничә ел элек җыештыручы итеп бер иптәшне алган идек. Ул исә тупас телле булып чыкты. «Бакча халкына» бу, әлбәттә, бер дә ошамаган. Зебра булып зебра да көннәрдән бер көнне чыгырыннан чыга — аңа ташлана. Ярдәмгә башкалар килгәнче, ул эшчегә гомер онытылмаслык җәрәхәтләр ясап өлгерә.

Ак аюлар һәм юлбарыслар аек булмаганнарга бик кырын карыйлар. Аракы исе аларны ярсыта.

— Ә менә читлектән чыгып качу очраклары буламы?

— Булгалый, әмма, бәхеткә каршы, бәла-казага китергәннәре юк әле.

Үткән ел җырчы попугаебыз, тишек табып, ирекккә чыккан. Озак кудык үзен, тик тота алмадык. Бик биек күтәрелеп очты. Яшькелт-зәңгәр каурыйлары гына җемелдәп калды. Югалтуыбыз шушыдыр инде дип борчылган идек. Ике көннән читлегенең өстенә кайтып кунган.

Аннан соң юлбарысыбыз Казанның Һади Такташ урамы буйлап әйләнеп кайтты. Беркемгә дә тимәгән. Хәер, аның ычкынуын ишеткәч, урамда кеше дә калмагандыр инде.

Пантералар да парлап бакча участогы белән иркенләп «танышып» йөрделәр. Аларны читлеккә ябарга ярдәмгә солдатларны чакырттык, тик җиңә алмадык. Йөреп аргач, кичке ашау вакыты җиткәч, читлекләренә үзләре әйләнеп кайттылар.

— Сездә циркта катнашкан җәнлекләр бармы? Булса, аларның үз-үзләрен тотышында аерма сизеләме?

— Берничә генә. Гадәттә, без аларны алмау ягында. Ни өчен дисәгез, цирк җәнлекләрендә йөрәк-кан системасы авыруы еш очрый. Ә безнекеләр өчен, гел тыныч, иркен яшәгәч, бу бик сирәк күренеш. Аннан соң цирктан килүчеләр хуҗалары белән аерылуны авыр кичерәләр, күрәсең. Физик яктан да үсешләре түбән була. Алар бездә озак яшәмиләр.

— Ә үзебезнең якларда яшәүче кошларны, җәнлекләрне алып килүчеләр бармы? Аларны кабул итү ничек тора?

— Бүре, төлке, төрле кошлар, кәлтә-елан алып киләләр. Буш читлекләр булганда, йогышлы авыру-чирләре булмаса, алгалыйбыз.

— Галина Евгеньевна! Казан дәүләт ветеринария институтында алган белемегез монда эшләү өчен җитәме?

— Җитә дисәм дә ялгыш булмас. Белемнең чиге юк бит аның. Без коллективта баш ветврач. Үзебезнең генә «тешебез үтмәгән» очракларда, шул ук ветеринария институты галимнәренә мөрәҗәгать итәбез. Илебездә 30 зоопарк һәм зооботаника бакчасы бар. Алар арасында фәнни-тикшерену эшләре алып баручылары да аз түгел. Һәркайсы кирәк чакта ярдәм итәргә әзер.

— Бу язманы укучыларга, ягъни булачак тамашачыларга нинди теләгегез бар?

Кучтәнәчсез килсеннәр иде алар. Югыйсә җәнлекләребезнең режимы, рационы бозыла. Төрле авырулар килеп чыгарга да мөмкин.

Без ел әйләнә эшлибез. Килсеннәр, күрсеннәр, шатланып каршыларбыз.

Әңгәмәне *Я. Абдулкадыйрова* алып барды

ҖИҢҮ КИТЕРҮЧЕ ДУЛКЫННАР

Республикабызның иң көчле спортчылары турында сүз чыкканда, Лидия Аверьянова исеме телгә алынмыйча калмый. Дөрестән дә, Казан кызы мондый игътибарга лаек. Җиңелүне белмәгән кыз спортка ничек килгән дә, уңышларга ничек ирешкән соң?

— Зур спортка эләгү ансат та, читен дә булды. Мин Биектау районының кечкенә генә бер авылында туып-үстем. Анда мәктәп юк иде. Шуңа күрә алты яшемнән күрше авылдагы мәктәпкә җәяү йөрергә туры килде. Хәрәкәт, көч ошый иде үземә. Шуңа күрәдер дә инде, табигать миңа аларны җитәрлек биргән. Чаңгыда узышуда, җиңел атлетика ярышларында мин һәрвакыт үзсебезнекеләр арасында беренче була идем. Ә баскетбол уйный башласак, озын буйлы булуым аркасында туп һәрвакыт минем кулда иде.

Гаиләбез белән Казанга күчеп килеп, Идел буе районындагы 58 нче мәктәптә укый башлагач та спорттан аерылмадым. Ләкин киләчәктә миннән чын спортчы чыгар дигән фикер башка да килмәде.

...Бервакыт кичен автобус тукталышында торганда яныма бер ир кеше килде дә, минем гаҗәпләнүемә каршы: «Кызый, синең ишү спорты белән шөгыльләнәсең килмиме?» — дип сорады. Нәрсә әйтергә дә белмичә аптырап калган идем мин ул вакытта. Киләчәктә шул кеше миннән дөнья чемпионы ясар дип тә уйламаган идем.

Сергей Михайлович Ульянов бу очрашудан соң Лидия-

не бик күп мәктәпләрдән эзләп карый, ләкин юкка... Шулай да язмыш аларны тагын очраштыра... Шуннан соң бер ел узгач, күршедәге иптәш кызы Люда Амосова аны кыстап, карап кына кайтабыз дип, ишү спорты белән шөгыльләнүчеләр секциясенә алып китә. Лидия шунда элеккеге очраклы танышын күрә, тегесе дә аны таный. Шунда ук аңа спорт формасы табып китерә. Ләкин аңа карап кына Лидия ишү секциясендә калырга теләми. Ошамый аңа анда. Ләкин тренер ишүнең нәкъ менә аның өчен кирәклегенә Лидияне ышандыра ала. Ниһаять, бер елдан соң Лидия аның секциясенә йөри башлый.

— Озакламый миңа бу спорт төре бик якын булып китте,— ди Лидия.— Күнегүләр белән ярышлар торган саен күбрәк чиратлаша башлады. Тренерым алдыма максат куйды: чемпион булырга! Армый-талмый күнегүләр үткәрүнең, яңа экспериментлар ясауның нәтиҗәсе дә сизелә башлады. Беренче зур уңышымны бик яхшы хәтерлим. Ул 1978 елда Европаның рәсми булмаган чемпионатында булды. Экипажыбыз белән беренче урынны алдык. Аннан соң РСФСР халыкларының VII Спартакиадасында, Софиядә үткәрелгән халыкара регатада да җиңдек.

1983 ел уңышларга аеруча бай ел булды. Мине илебез җыелма командасы составына алдылар. Башта илебез чемпионы булдым. Аннары СССР халыкларының VIII Спартакиадасында, Зур Мәскәү регатасында җиңдек. Ниһаять, Дуйсбург шәһәрендә үткәрелгән дөнья чемпионатында пьедесталның иң югары баскычына күтәрелдек.

— Әйе, без бөтенебез Олимпия сулышы белән яшәдек. Реакцион даирәләр гаебе белән Лос-Анджелес Олимпиадасында чыгыш ясый алмасак та, без үзебезнең дөньяда иң көчле икәнебезне барыбер күрсәттек. «Амстердам регатасы»нда без дөнья рекордын яңартуга ирештек.

— Лидия, ярышлардан тыш вакытыгыз ничек үтә?

— Ярышлардан тыш вакытта да спортчыларның эше күнегүләр ясауда. Мин дә әле тиз генә зур спорт белән саубуллашырга җыенмыйм...

Спортның башка төрләрендәге кебек үк, ишүдә дә күнегүләр һаман саен төрләнә, катлаулана, күбәя бара. Кайберәүләр шаккатыр, безгә хәтта штанга да күтәрергә туры килә. Үз авырлыгыңны күтәрә алмыйсың икән, син ярышларда уңышлы чыгыш ясау турында уйлама да. Юкка гына ишкәкчеләр белән баскетболчылар спортчылар арасында иң «каты» куллылардан саналмый. Баскетбол дигәннән, миңа бит үз вакытында баскетболга күчәргә тәкъдим иткәннәр иде. Ләкин, күргәнегезчә, мин ишүгә тугрылыклы

булып калдым. Дөрес, баскетбол минем яраткан уеннарымның берсе.

— Һәр спортчының олы бер хыялы була диләр. Сездә дә бармы андый хыял?

— Әлбәттә. Барысын да таңга калдырырлык җиңүләр турында хыялланмаган спортчы юктыр ул. Һәм ышанып әйтә алам, күпләрнең хыялы бер төсле: ул да булса Олимпия чемпионы булу.

Әңгәмәне *Айрат Садыйков* алып барды

ШАШКАГА — ШАХМАТТАН

Якташыбыз Альберт Аксанов, СССРның спорт мастеры, халыкара шашкалар буенча РСФСР чемпионы дәрәҗәсенә иреште.

— Шашкага мин шахматтан килдем,— диде ул, әңгәмәне үзе башлап.— Әтием бик оста шахматчы иде. Мине дә бу буенга өйрәтте. 6—7 яшьләремдә мин шахмат уйный белә идем инде. Озакламый үземнән өлкәнрәк дусларымны һәм хәтта әтиемне дә җиңә башладым. Казанның 2 нче номерлы мәктәбендә укыганда Пионерлар сараена шахмат түгәрәгенә йөрдем. Тик мина анда озак шөгыльләнергә туры килмәде. Тренерым В. В. Калинин миңа шашка уенына күчәргә тәкъдим ясады. Мин бик теләп риза булдым һәм бу уенга карата миндә чын-чынлап олы мәхәббәт уянды. Шашка уенын шахматка караганда өстенрәк күрә башладым. Мәктәпне тәмамлагач, Казан төзүче-инженерлар институтында укыдым. Ул елларда инде мин разрядлы шашкачы идем, ә бераздан кандидат, аннары спорт мастеры булдым. 1967—70 елларда «Буревестник» ирекле спорт җәмгыяте чемпионы исемен алуга ирештем. Халыкара шашкалар буенча 5 тапкыр Татарстан чемпионы исемен яуладым. Шулкадәр үк рус шашкалары буенча да республика беренчелегендә җиңеп чыктым. Дөрес, ун ел дәвамында яраткан уенымны ташлап торырга туры килде. Ләкин шашка уенына булган мәхәббәтем барыбер үзенекен итте... 1980 елда мин яңадан уйный башладым. 1983 ел миңа зур уңыш китерде: халыкара шашкалар буенча РСФСР чемпионы булдым.

— Шахматны шашкага караганда популяррак дип саныйлар. Сез моңа ничек карыйсыз?

— Мин башкачарак уйлыйм. Шашка иң борынгы уеннарның берсе. Ул шахматка караганда күпкә алданрак билгеле була.

Немец халкының күренекле шахматчысы Эммануил Ласкер үз вакытында «Шашка — шахматның анасы» дип белдергән. Хак сүзләр! Олы шәхесләрнең шашканы хөрмәт итүе аның популярлыгын тагын бер кат раслый. Күп кенә шахматчылар үзләренең көчен шашкада сынап караудан башлыйлар. Мәсәлән, һәркайсыбызга билгеле булган Рәшит Нәҗметдинов бик оста шашкачы иде.

Шашка республикабызда иң киң таралган уеннарның берсе. Ул, һичшиксез, бу ягы белән шахматтан өстен. Теләсә кайсы авылны гына алып карагыз, анда шашка уйный белүчеләр шахмат уйнаучыларга караганда күбрәк булыр! Ләкин шулай да шашканы чын-чынлап аңлаучылар, белүчеләр күп түгел әле. Ә чынлыкта шашка үзенең тирәнлеге, комбинацияләргә бай булуы белән игътибарга лаек.

— Альберт, без еш кына «халыкара шашкалар», «рус шашкалары» дигән атамаларны ишетәбез. Башка төрле шашкалар да бар диләр. Менә шуларның аермаларын, үзенчәлекләрен аңлатып бирегез әле.

— Әйе, шашкалар күп төрле була. Рус шашкалары 64 (8×8) шакмактан тора. Фигуралар кара шакмакларга тезелә. Канада шашкаларында 144 (12×12) шакмак бар. Французныкында фигуралар карага түгел, ә бәлки ак шакмакларга урнаша. Төрек шашкаларында фигуралар шахматтагы шикелле ике рәт итеп куела. Англия шашкаларында «артка ашау» бар. Япон шашкалары хәзер иң киң таралган шашка төрләренең берсе. Аларның икенче төрле атамасы — го уены. Шашканың күптөрлелеге ярышлар үткәргәндә кыенлыклар да тудыра. Шунлыктан үткән гасыр ахырында ук халыкара шашкалар барлыкка килгән. Аның нигезенә Канада шашкаларындагы кагыйдәләр салына. Халыкара шашкалар 100 (10×10) шакмактан тора. Беренче чемпионат 1894 елда ук үткәрелә. Хәзерге вакытта халыкара шашка федерациясе эшләп килә. Ул шашка уенын тагын да камилләштерү буенча эш алып бара.

— Сер булмаса, әйтегез әле, сезнең өчен идеал булып саналган шашкачы бармы?

— Бар. Ул — Голландия гроссмейстеры Т. Сейбрандс, 1972—78 елларда дөньяның алыштыргысыз чемпионы.

Сейбрандс уенында минс иң җәлеп иткән нәрсә: төзек комбинацияләр, позицияне сайлый белү осталыгы. Аның тәэсире нәтиҗәсендә мин дә үз вакытында «Турига каршы комбинация» эшләдем. Тури элегрәк елларда безнең иң көчле шашкачыбыз иде. Комбинация әле дә үзенең актуальлеген югалтмады. Күптән түгел Агафонов тарафыннан төзелгән шашка дәреслеге дөнья күрде. Классик комбинацияләр белән беррәттән, анда минеке дә урын алды.

Совет шашкачыларыннан бигрәк тә дөньяның экс-чемпионы В. Шеголев һәм илебезнең 1982 елгы чемпионы А. Балякинның уены ошый. Шеголев — техник, зур теоретик. Ә А. Балякин исә үзенең эксперименталь уены белән аерылып тора. Дөньяның дүрт тапкыр чемпионы голландияле Харм Вирсма озакламый дәгъвачы, Европа чемпионы Вадим Вирный белән очрашачак. Вирсма стратег булуы белән көчле, ә менә совет шахматчысына, минем уйлавымча, һөҗүм итү осталыгы җитеп бетми шикелле. Ул күбрәк оборона тотарга ярата. Шашка — прессинг уены, исәп уены. Син 15–20 йөрешсене алдан белеп, аларга әзерләнеп торырга тиешсең. Юккамыни, шахматны — катлаулы интуитив, ә шашканы — тирән уен диләр.

— Альберт, Сез тренер да бит әле. Бу җәһәттән, республикабызда шашка уенының үсеше, яшь талантлар турында да берничә сүз әйтсәгез иде.

— Менә күп еллар инде Казанның 10 нчы номерлы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә шашка-шахмат секциясенә җитәкчелек итәм. Ул 68 нче мәктәп базасында эшли. Мәктәп командасы шашка буенча Казан чемпионы. Кызганычка каршы Казанда бу юнәлештә бары тик ике генә тренер эшли. Шунлыктан шашкачылар да аз.

— Белүебезчә, сезнең гаилә тулысы белән шашкачылар гаиләсе булса кирәк.

— Нәкъ шулай. Миннән «шашка җене» башта хатыным Таһирәгә күчте. Ул хәзер 1 разрядка ия. Аннан улыбыз Марат һәм кызыбыз Гүзәл дә әлеге уен белән мавыгып киттеләр. Марат төрле ярышларда җиңеп чыкты. Гүзәл исә абыйсын да уздырды. Минем кебек РСФСР чемпионы булуга иреште.

— Альберт, шундый сорау: шашканы ташлап шахматка күчәргә теләмиссезме?

— Һич юк. Шахматны күпме генә яратсам да (мин аны да начар уйнамыйм), шашкага мәхәббәтем көчлерәк. Бу уенны олы шәхесләр дә яраткан.

Моннан биш мең еллар элек үк шашка Мисырда киң таралган булган. Фиргавен Рамзес 1 нең каберлеген ачкач,

археологлар анда төрле байлыклар белән бергә шашка фигуралары да табалар. Ә менә Петр I дворяннарны шашка уйный белергә тиеш дип санаган. Ул Академиядә шашкага өйрәтү дәресләре дә керткән һәм аларны гадәттә үзе алып барган.

Бөек поляк шагыйре Адам Мицкевич хәтта «Шашкалар» дигән шигырь дә язган. Ә бу шахматчыларга бик үк ошап бетми. Мәшһүр философ һәм язучы Жан-Жак Руссоның иң яраткан шөгыльләреннән берсе шашка уены була. АКШ президенты Франклин Д. Рузвельт та шашка уены белән мавыккан. «Шашка вакыт уздыру гына түгел, ә бәлки кешенең характерын билгеләүче, аның логикасын үстерүче шөгыль»,— дигән ул.

Менә бит, шашка уенының абруе шахматныкыннан һич кенә дә ким түгел икән ич.

Әңгәмәне *Айрат Садыйков* алып барды

АЛИСӘ — ГРОССМЕЙСТЕР

Ул көнне Казан тимер юл вокзалына Мәскәү — Тында поездын каршы алырга Дәүләт физкультура һәм спорт комитеты җитәкчеләре дә, танылган шахматчылар, журналистлар да килгән иде. 16 яшькә кадәрле шахматчы кызлар арасында дөнья чемпионы исемен яулаган Алисә Галләмованы каршыларга җыелганнар алар. СССРның спорт мастерлары, республикабызның иң көчле шахматчыларыннан саналган Наил Мөхәммәтҗанов белән Лев Волошиннарның сөйләшүенә колак салам.

— Татарстанның бер генә шахматчысын да болай тантаналы төстә каршылаганнары юк иде әле,— ди Н. Мөхәммәтҗанов.— Хәтта Рәшит абый Нәҗметдиновны да...

— Әйе,— дип аның сүзен куәтли Л. Волошин.— Казанга беренче тапкыр дөнья чемпионының алтын медале кайта. Соңгысы булмасын иде. Молодец, Алисә!

— Рәшит абый исән булып, бу турыда ишетсә, ничек шатланыр иде! Ул бит һәр яшь талант белән горурлана, аларны үз серләренә бик теләп өйрәтә иде.

...Станциягә Мәскәү — Тында поезды килеп туктауга, спортчылар 12 нче вагон янына ашыктылар. Алисә белән аның тренеры Олег Ильясович Игъламовны вагоннан төшә-төшүләренә үк чәчәкләр белән күмделәр. Каршылау-

чылар арасында Алисәнең әнисе Гамбәрия Муллагалиевна белән энесе Ринат та бар. Шунда ук перронда, кыска гына вакытка тукталып, ТАССР Дәүләт физкультура һәм спорт комитеты председателе Хәниф Мөбарәкшинович Мортазин каршыларга килүчеләрне яшь шахматчының уңышлары белән таныштырды һәм Алисәне уңышлары белән котлады. Аннан соң Алисә белән республика Дәүләт физкультура һәм спорт комитетында, ТАССР Халык Мәгарифе министрлыгында, Профсоюзлар өлкә комитетында очрашулар булды, журналистлар катнашында пресс-конференция үткәрелде.

Ә икенче көнне аны яшьтәшләре — республика пионерлары слетына җыелган делегатлар белән очрашуга чакыралар. Ул анда шахмат сөючеләрнең сорауларына җавап бирде, берьюлы берничә тактада алар белән көч сынашты. Кайтуына өч көн үтүгә ул, көндәшләре белән чын-чынлап көрәшер өчен, тагын шахмат тактасы артына утырды. Бусы инде һәр елны танылган шахматчы якташыбыз, биш тапкыр РСФСР чемпионы, халыкара мастер Рәшит Нәҗметдинов истәлегенә Казанда үткәрелә торган шахмат турниры иде. Ул Казан командасы составында беренче тактада, ягъни башка командалардагы иң көчле малайларга каршы уйнады. Алисә монда да сынатмады — 9 уенда 8 очко җыйды һәм шулай итеп Казан командасына беренчелекне яуларга булышты.

Шуннан соң Актаныш районы Татар Ямалы авылына әбиләренә кунакка кайтып китте. Шахматтан ял итте ул анда. Рәхәтләнеп Агыйдел елгасында коенды, дус кызлары белән бергә кечкә уеннарда катнашты. Бердә аның төптөгәл биш ел булганы юк иде инде. Әбисе Тәхия дә, бабасы Муллагали дә оныкларының кайтуына бик шатландылар.

Ә июль уртасында Алисә хатын-кызлар арасында СССР беренчелегенең ярымфиналында катнашты. Ул ярышларда катнаша торсын, ә без аның шахматка ничек килү юлы белән танышып үтик. Сезнең күбегезнең, мөгаен, «Алисә могҗизалар илендә» дигән китапны (авторы — Льюис Кэрролл) укыганыгыз бардыр. Аны 1865 елда Англиядәге Оксфорд колледжының математика укытучысы Чарльз Доджсон язган. Иң башта ул үзенең 10 яшьлек кызы Алисәгә Могҗизалар илендә күргәннәре турында әкиятләр сөйли торган булган. Бу әкиятләр кызга бик ошаган һәм шуннан соң Доджсон аларны китап итеп бастырган.

Шул чордан бирле ул илледән артык телгә тәрҗемә

нтелең, миллионлаган тираж белән басылган. Китап хәзер дә кибетләрдә һәм китапханәләрдә тормый — аны бик теләп укыйлар. Хәтерләсәгез, Алисәнең Көзгеләр патшалыгындагы сәяхәте шахмат тактасыннан башлана. Һәр бүлек бер йөреш рәвешендә бирелгән. Унберенче (соңгы) бүлектә Алисә, король кыз булып, каршы якка мат куя.

Тарих безгә Алисә Лидделның шахматта ничек оста уйнавы турында мәгълүматлар калдырмаган, әмма ул Казан кызы Алисә Галләмованы барыбер җиңә алмас иде.

Алисә дә могҗизалы шахмат дөньясына әкияттәге кебек килеп эләгә. Бервакыт алар классына (бу вакытта ул Казандагы 62 нче мәктәпнең III классында укый) бер абый керә дә: «Кемнәр шахмат уйный белә?» дип сорый. Алисә дә кул күтәрә. Ул шахматны шашка уены белән бутаган икән (өйдә әнисе белән шашка уйнаганы була). Менә шундый ялгышу аны Идел буе районындагы «Прометей» клубының шахмат түгәрәгенә алып килә. Ә аннан соң инде могҗизалар дөньясында тылсымчы, ягъни тренер белән бергә сәяхәт башлана. Олег Ильясовичка Алисәнең тыйнаклыгы, сабырлыгы, бер эшкә тотынса аны ахырына кадәр җиткерүе ошый. Кыз әкренләп шахмат белән шулкадәр мавыгып китә, башкалар атналар, айлар буе чишә алмый торган мәсьәләләрне дә икенче көнне үк чишеп алып килә. Бервакыт тренер аңа өйгә бирергә мәсьәләләр табып бетерә алмый башлый. Шахматта берни дә белмәгән кыз бер ел эчендә беренче разрядлы шахматчы дәрәҗәсенә күтәрелә. Бу шулай ук сирәк очрый торган күренеш.

Уңышлар, билгеле, үзеннән-үзе генә килми. Аның өчен шахматны ярату гына да җитми.

— Бервакыт түгәрәккә Таня исемле бик талантлы кыз йөрде,— дип сөйли О. И. Игъламов.— Тик ул күпмедер уңышка ирешә башлагач, үз өстендә эшләүдән туктады һәм аннан соң фигуралы шуу түгәрәгенә китеп барды. Анда да озак йөри алмаган — чөнки үз алдыңа билгеле бер максат куймасаң, даими шөгыльләнмәсәң, уңышка ирешеп булмый. Ә Алисәдә шахматчы өчен кирәкле бөтен сыйфатлар да бар дип уйлыйм. Ул шахмат тактасы артында сәгатьләр буена бер дә кузгалмыйча утырырга мөмкин. Турнирлар вакытында үз командасы җиңелсә, иптәшләре белән ачуланышмый, ә аларның хаталарын тыныч кына аңлатып бирә...

Кызның шахматчылар өчен бик кирәк булган тиз отып алу сәләте, яхшы хәтерле булуы кечкенә вакытта ук күренә.

— Алисәгә өч яшьләр чамасы булгандыр, мин аңа

кибеттән рәсемле кубиклар алып кайтып бирдем,— дип сөйли аның балалар бакчасында тәрбияче булып эшләүче әнисе Гамбәрия Муллагалиевна,— берничә минуттан ул аны дөрес итеп төзеп тә куйган иде инде. Сабыр. Укырга да, шахмат түгәрәгенә йөрергә дә, миңа булышырга да өлгерә. Өйгә бирелгән эшләрен тәмамламыйча, бервакытта да йокларга ятканы юк... Ә менә 7 нче класста укучы улыбыз Ринат Алисәнең капма-каршысы,— дип сүзгә кушыла әтисе.— Казан шәһәре юл төзү-эксплуатация идарәсе шоферы Җәүдәт абый,— аңардан гомердә дә шахматчы чыгачак түгел, чөнки ул бик хәрәкәтчән, бер урында озак утыра алмый. Башта тимераякта йөреп карады, аннан көрәш түгәрәгенә күчте, хәзер әнә ишкәкче булам дип хыяллана...

Алисәнең өйгә бирелгән эшләре кайвакытта бик күпкә җыелалар. Бигрәк тә бер атна яисә ун көнгә ярышларга киткәндә. Әле ярый классташлары булышалар. Ул Казанның 16 нчы, 131 нче мәктәбендәге классташларына бик тә рәхмәтле. Алар да Алисәне яхшы хәтерлиләр булыр — күпме классташын шахмат уены серләренә өйрәтте бит ул. 1987—89 елларда А. Галләмова Мәскәүдәге махсус спорт-интернат мәктәбенең шахмат классында укыды. Өйдә әтиәнисе, тренеры белән киңәшкәч һәм республика Дәүләт физкультура һәм спорт комитетының ризалыгын алгач, осталыкны тагын да үстерү максатыннан эшләнде бу эш. Алисә аңа кадәр дә Чиләбедән танылган гроссмейстер Александр Панченко белән тыгыз элемтәдә яши иде. Дөресрәге, А. Панченконың читтән торып оештырылган шахмат мәктәбендә укыды. Ә Мәскәүдә кыз РСФСРның атказанган тренеры Рудольф Киммельфельд җитәкчелегендә шөгыльләнде. Әмма ул анда укыганда да Казан өчен, Татарстан өчен чыгыш ясавын дәвам итте. Зур-зур ярышларда катнашканда анкета тутырганда: «Тренерың кем?» дигән юлга «О. И. Игъламов» дип язды.

Беренче разрядка ия булган Олег Ильясович моннан 15—20 еллар элек Казанның һәм республиканың иң көчле шахматчыларыннан берсе була, берничә тапкыр Казан дәүләт университеты чемпионы исемен ала, республика беренчелегендә уңышлы чыгыш ясый. Хәзер ул «Прометей» балалар клубында тренер булып эшли.

— Мин үземнең төп тренерым итеп Рәшит абый Нәҗметдиновны саныйм,— ди Олег Ильясович.— М. Горький исемендәге Үзәк культура һәм ял паркында урнашкан югары спорт осталыгы мәктәбенә (ШВСМ) өч елдан артык йөрдем. Ә андагы шахмат түгәрәген ул чакта Рәшит абый җитәкләде.

Шахмат кебек серле, купкырлы уенда кемгәдер нәру, кемнедер кабатлау бәхәсле һәм мөмкин булмаган эш дип саныйм мин. Ә менә Алисәнең уеныида Рәшит абый уйнаган партияләрдәге кыюлыкны, ахырга кадәр уйнауны, көтелмәгән чишелешләр таба алуны күрергә була. Шахмат белгечләренең фикере шундый.

Алисәнең шахмат дөньясына килүенә дистәгә якын ел үтте. Шушы чорда ул ике йөздән артык ярышта, турнирда катнашты. Алар арасында, билгеле, «Прометей» клубы беренчелегеннән алып укучылар арасында РСФСР чемпионаты һәм СССР Халыклары спартакиадасы финалы, дөнья чемпионатлары да бар. Шунысы куанычлы: ярышлар шахматчы кызның осталыгын арттыруда бер адым булган. Әйтик, 1983 елда укучылар арасында үткән РСФСР беренчелегендә ул тугызынчы урынны гына ала, әмма күп кенә мастерлыкка кандидатларны, шул исәптән РСФСР чемпионы, Свердловск кызы Юлия Деминаны да ота. Юлиянең тренеры Алисәнең уенын карап торганнан соң: «Минем укучым аның яшендә болай уйнамый иде әле, бу кыз бик ерак китәчәк»,— ди. Шахмат Казан кызын чыннан да бик еракларга — Австриянең Инсбрук шәһәрендә үткән дөнья чемпионатына кадәр алып китте. Ә аңа кадәр ул сайлап алу турнирларында күп кенә көчле шахматчыларны отты.

Грузия шахмат мәктәбенең даны еракларга билгеле. Соңгы 10 ел эчендә хатын-кызлар арасында дөнья чемпионы исеме өчен шушы республика вәкилләре генә көрәшәләр. Майя Чибурданидзе, Нона Гаприндашвили, Нана Александрия кебек шахматчыларны бөтен дөнья белә. Алисәгә дә сайлап алу турнирларында Қахиани, Лагвилава, Джанджгава, Тереладзе кебек яшьтәшләрен җиңәргә туры килде. Ә шулай да ул укучы кызлар арасында ил чемпионы Софико Николадзены җиңүен иң зур уңыш дип саный. Дөнья чемпионкасы Майя Чибурданидзе туганының кызы булган Софико моннан алдагы ярышларда гына Алисәдән өстен булган иде бит. Тик татар кызы сайлап алу турнирында бөтен көчен биреп уйнады, яшь буенча үзеннән өлкәнрәк булган спорт мастерлары Софиева, Матвеева, Зайцеваларны да бирелергә мәҗбүр итте. Һәм 16 яшькә кадәр булган кызлар арасында дөнья чемпионатына бердәнбер путевканы яулады.

Менә ул Ак Олимпиадалар башкаласы Инсбрук шәһәре. Биргә малайлар һәм кызлар арасында шахмат таҗын дәгъваларга дөньяның 43 иленнән 70 кә якын шахматчы килде. Безнең командада Алисәдән тыш Ленинградта яшәүче 12 яшьлек татар малае Гата Камский да бар иде. Гата

анда уртача гына чыгыш ясады — кырыклап көндәше арасында унөченче булды. Ә Алисә үз яшьтәшләре арасында илдә генә түгел, ә дөньяда да үзенә тиңнәр юк икәнен раслады.

Беренче турда ул Франциядән Сабине Фрутоны, икенчесендә фин кызы Жоанна Паасикангасны отты. Шуннан соң бераз йомшабрак китте — өченче турда Болгариядән Кристина Ладйова, аннан соң Румыниядән Раду Лумиита белән ничьяга уйнады. Дүртенче тур тәмамланганнан соң таблога караса, исе китте — ул өченче урында гына бара икән. Кичен илебез делегациясе җитәкчесе, халыкара гроссмейстер Айвар Гипслис бүлмәсендә зур сөйләшү булып алды.

— Көндәшләреңнән куркып уйныйсың,— диде аңа танылган шахматчы.— Алар да синең кебек үк бу ярышларга беренче тапкыр гына килгәннәр бит — курыкма. Аннан соң беренче турларда җибәрелгән кайбер хаталар тикшерелде, көндәшләрнең уены анализланды һәм алга таба кем белән ничек уйнарга кирәклеге хәл ителде. Алдагы турларда Алисә Галләмова Колумбия вәкиле Изолина Майюльне, аннан соң Югославия, Венесуэла, Греция, Нидерландтан, Исландиядән, Германия Федератив Республикасыннан килгән кызларны отты. Бу инде 11 уеннан 10 очко, ягъни дөнья чемпионкасы дигән сүз иде.

Бөтендөнья шахмат федерациясе президенты Флеренция Кампоманес Алисәгә алтын медаль һәм алтын йөгертелгән кубок биргәндә, аның киләсе дөнья чемпионатына сайлап алуларсыз катнашу хокукына да ия булуын әйтте. Инсбрук шәһәре мэры Казан кызына хрусталь шахматлар бүләк итте.

Шахматчы кызлар ярышларда бер-берсенә каршы уйнасалар да, матчлардан тыш вакытларда шәһәр буйлап сәяхәтләргә бергә йөрделәр, бергә төрле уеннар уйнадылар. Кызлар бер-берсе белән хат алышырга сүз куешып, елашып аерылыштылар. Алисә бигрәк тә болгар кызы Кристина һәм Югославиядән Наташа белән нык дуслашты. Кайтып китәр алдыннан Кристина аңа Болгариядә чыга торган «Народен спорт» (бездәге «Советский спорт» кебек) газетасын күрсәтте. Анда дөнья чемпионаты шактый киң яктыртылган иде. Мәкаләләрнең башларына игътибар итте Алисә. Беренче язма «Болгария кызы — лидер» дип атала иде. Аннан соң «Көрәш кискенләшә» һәм «Медаль булырмы?» дигән язмалар. Иң соңгы язма «Медальсез калды» дип исемләнгән...

Ямьле май ае бетеп килгәндә — алмагачлар, шомырт-

лар шау чәчәктә чакта Үзәк телевидениесенең «Вакыт» программасын алып баручы диктор: «Австриянең Инсбрук шәһәрендә 16 яшькә кадәрле кызлар арасында Казан укучысы Алисә Галләмова чемпион булды» дигәч, безнең дә шатлыгыбызның, горурлыгыбызның чиге булмады. Алисә анда Татарстан данын гына түгел, ә ил данын яклап күрәште, совет шахмат мәктәбенең көчен тагын бер тапкыр исбатлады.

Инсбруктагы дөнья чемпионатыннан соң Алисә үзебездәге уеннардан тыш тагын ике мәртәбә халыкара турнирда катнашып, җиңүләргә иреште. Бөтендөнья шахмат федерациясе президенты 1989 елның көзендә якташыбызга халыкара гроссмейстер дигән мактаулы исемне бирде. Бу вакытта инде Алисә Мәскәүдәге интернат-мәктәптә укуын тәмамлап Казанга кайткан иде. Җәй көне, имтиханнарны уңышлы тапшырып, Казан дәүләт педагогия институтының чит телләр факультетына укырга керде ул. Аның тренеры — халыкара гроссмейстер Александр Панченко да Чиләбедән Казанга күчеп килде. Шулай итеп хәзер 10 нчы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә ике гроссмейстер, дүрт спорт мастеры булды. «Прометей» клубы хәзер «Алисә» исемен йөртә.

1990 елны да уңышлы башлап җибәрде А. Галләмова. Март аенда Мәскәүдә Халыкара хатын-кызлар бәйрәме хөрмәтенә үткәрелгән турнирда Марта Литинскаяга гына оттырып өченче булды.

Күп кенә шахмат сөючеләр хәзер Алисәнең хатын-кызлар арасында дөнья чемпионы булган Майя Чибурданидзе белән уйнавын көтәләр...

...Шахмат дөньясы могҗизалы, газаплы, сихри дөнья. Аңа килеп кергән кешеләр аны бервакытта да ташламыйлар. Алисәнең дә бу могҗизалар илендә адашмыйча йөрүен теләп калыйк.

Атлас Гафиятов

БӨРКЕТ КҮҢЕЛЕ КЫЯДА

Мәгърур тау-кыялар күптәннән инде эзләнүчән сәяхәтчеләр игътибарын үзенә тарткан. Күз күреме җитмәс биеклеккә ашкан, текә, мәңгелек бозга төренеп серле тын-

лыкка талган тау түбәләре бүген тикшеренүче-галимнәрне генә түгел, меңләгән спорт сөюче сәяхәтчеләрне дә үзенә җәлеп итә.

1923 елда профессорлар Г. Николадзе һәм А. Дидебуладзе җитәкчелегендә Грузиянең тауга күтәрелергә ратучылары Казбек түбәсенә менгәннәр иде. Һәм бу вакыйга тарихка совет альпинизмының башлангычы булып кереп калган. Совет альпинизмының максаты — иң гүзәл хисләр, кыюлык, ихтыяр көче, киң күңеллелек, ярдәмчеллек тәрбияләү. Болар иң беренче чиратта белемгә, батырлыкка омтылыш уятырга тиеш. Бу турыда Казан авиация институты студентларының «Спорт» конструкторлык бюросы мөдире Валерий Сергеевич Кудряшов белән сүз башлавым юкка түгел. Ул үзе дә һаман биеклеккә омтылучы альпинист.

— Валерий Сергеевич, тауларга мену сезнең балачак хыялыгызмы?

— Юк дисәм, дөрес ук булмас. Мин үзем Мамадышта үстем. Ә ул, белгәнегезчә, таулар арасында утыра. Тирә-ягындагы җиләк-җимешкә бай, хәтфә тау битләрендә малай чакта нинди генә уеннар оештырмый идек. Күрәсең, алар күңелдә эзсез калмаган. Казан дәүләт университетына укырга кергән елны ук альпинистлар секциясенә язылдым.

— Беренче яулаган биеклегегез һәм анда алган тәэсирләрегез нинди булды?

— 1971 елда Кавказдагы Узун-кол альпинистлар лагерена күтәрелдек. Әлбәттә, анда әле без үз адымыбыз белән мендек, ягъни берииндн дә кыялар белән очрашмадык. Кайчандыр бик күптән кыялардан кителеп төшкән, мүкләнеп беткән гигант ташлар белән аралашып үскән урманнарны аста калдырып, Альп болыннарына күтәрелдек. Безнең экспедицияләр гадәттә җәйнең уртасында оештырыла. Ул юлы да без болыннарның искиткеч матур, шау чәчәккә күмелгән чагына туры килдек. Анда инде сине чебен-черки дә җәфаламый. Һәр таңны синң мәһабәт Эльбрус алып килә. Әле болынлыкларда караңгылык таралып бетми, ә Эльбрусның чал кыяларына төшкән кояш нурлары чагылып җиргә яктылык сибә. Бу күренешне күзәткән кеше Эльбрус түбәсенә күтәрелү турында хыялланмый булдыра ала микән?! Болар миндә биеклеккә омтылышымны тагын да көчәйттеләр. Сергей Миронович Киров та бит болытлардан биектәге шушы тәэсирләрен болай дип сурәтләгән:

«Безнең арабыздан кем генә якындагы шушы великан түбәсенә менү турында хыялланмаган. Кавказ таулары тезмәсенә патшалык иткән бу мәһабәт биеклек кемне генә җәлеп итмәгән?

Ә бит аларның бик әзе генә бу хыялына ирешә алган!» Иң беренче сәяхәтемдә үк: «Бер мәртәбә кыя-тауга үрмәләгән кеше аннан мәңге аерыла алмый»,— дигәннәр иде, чыннан да дөрес икән.

Кавказның Эльбрус түбәсенә мендем. Тянь-Шаньда булдым. Памирның Ленин биеклегендә (6500 метр) булдым. Хыялым — 1982 елда Җир шарының совет альпинистлары яулаган иң биек ноктасы Эверест (биеклеге 8848 метр) очына басу.

— Альпинистлар арасында идеалыгыз бармы?

— Күренекле совет альпинистлары арасында кайсысының гына тормыш юлы белән танышсаң да, күңелдә искиткеч зур ихтирам, горурлык уятырлык. Шуңа күрә алардан берсен сайлап алып идеаллаштыру мөмкин түгел. Мәсәлән, альпинизм буенча атказанган спорт мастерлары, бертуган Абалаковларны гына алыйк. Евгений Михайлович альпинизмны үстерүгә зур өлеш керткән, иң биек кыяларны яулаган. Виталий Абалаковның Хан-Тенгрига (Тянь-Шань) менгәндә өшеткән аяк-кулларындагы 13 бармагын кисәләр. Ләкин шуңа да карамастан, ул яңадан-яңа, үзенчә әйтсәк, «алтын биеклекләр»гә күтәрелүен дәвам итә.

Ә Җиңү түбәсен ачуга зур өлеш куйган академик А. А. Летаветны кем генә белми икән. Күренекле галим бөтен гомере буе инанган спортчы булып калган. Памир, Тянь-Шань тауларында яңа биеклекләр ачуда үзе артыннан бик күп белгечләрне, альпинистларны ияртүче фәндә дә, сәяхәттә дә һаман югарыга рухландыручы көч булган. Бүген без аның исеме белән Тянь-Шань тауларының әһәмиятле биеклеген атыйбыз.

— Валерий Сергеевич, кыскача гына Татарстан альпинизмы турында әйтеп үтсәгез иде.

— Россия Федерациясе альпинистлары арасында кыяга үрмәләү һәм биеклек яулау буенча оештырылган осталык ярышларында алдагы урыннарның берсен яулыйбыз.

Республика альпинистларының уңышлары турында сөйләгәндә, Зоя Даутова турында искә алмый мөмкин түгел. Кыялар яулаганда кыюлыгы, җитезлеге, осталыгы белән һич тә ир-егетләрдән калышмаган бу кыз Союз тренерлары дәрәҗәсенә күтәрелде. Һәм җәйге айларда таулардагы альпинистик лагерьларда яшь спорт сөючеләрне кыя-тауларга күтәрелергә өйрәтте.

Зоя спортчы гына түгел, кеше буларак та иң гүзәл сыйфатлар җыелмасына ия иде. Экспедицияләрдә группада аның булуы күңелгә ниндидер тынычлык бирә, ышаныч уята, ул кыенлыкларны җиңүдә шәхси үрнәге белән һәммәбезгә рух бирә иде.

Аның тагын бер матур гадәте — таулар белән бергә җырга гашыйк иде Зоя.

Әмма кыя-үрләр безне кочагын җәеп каршыламый. Алар горур, алар — салкын таш! Баш имиләр, сине ышыкларга, сакларга омтылмыйлар. Тик кыю, куркусыз спортчылар гына аларны җиңә баралар. Әлбәттә, җиңүләр корбансыз булмый. Альпинистлар еш кына табигатьнең, тау-кыяларның рәхимсез күренешләре белән дә очрашалар. Якташыбыз Зоя Даутова да әнә шундый шәфкатьсез дулкынга элэгә...

— Альпинизмда җәмгыятьләр карашы аерыламы?

— Бик нык. Буржуаз җәмгыятьтә аның максаты ялгыз яуланган биеклекләр белән шаккатыру, танга калдыру. Безнең илебездә альпинизм күмәклек белән көчле. Безнең альпинистларга тар эгоистик караш чит, ят нәрсә. Һәр сәяхәт альпинизмда тупланган тәҗрибәләргә нигезләп төзелгән «СССРда тауга күтәрелү кагыйдәләре»ндәге система буенча оештырыла.

— Шулай да сезгә нинди куркынычлар яный?

— Самолетта ерак рейсларга очкан кеше белә инде, җир өстеннән 7—9 километр биеклектә 38—40 градус салкын дип игълан итәләр. Моннан күз алдына китерү кыен түгел: 20—25 градус җылы урыннан кыска гына вакыт эчендә әнә шул салкынга күтәрелү өчен сәламәт булу гына җитми, бик нык чыныгырга, һава шартларының кискен үзгәрүенә күнегергә кирәк. Аннан соң 30—50 шәр метр биеклектәге текә кыяга күтәрелгәндә, шуның урта бер җирендә гамак асып төн кунарга туры килгән чаклар да була. Бусы кыяга менү технологиясен яхшы белүне, аны оста файдалануны таләп итә. Тәҗрибәле альпинист, мәсәлән, әллә нихәтле биеклектәге кар, боз катламнарының ныклыгын, ышанычлылыгын күрер күз белән үк чамалый. Һәм группа куркынычсызлыгын тәэмин итә ала.

Альпинизмда техник җайланмалар елдан-ел киңрәк кулланыла. Аларны куллана белү дә зур түземлелек белән җентекләп өйрәнүне таләп итә. Бүгенге альпинизмның бурычы — тауларга гашыйк һәр яшь кешедә әнә шушы күнекмәләрне булдыру.

— Димәк, альпинист булу өчен спорт белән, техника белән дәвамлы дуслык, даими шөгыльләнү кирәк.

— Әлбәттә. Алай гына да түгел, безнең илдә альпинизм кешедән зур тәрбиялелек тә таләп итә. Бездә һәр альпинист табигать сакчысы да булырга тиеш.

— Моны ничек аңларга?

— Безнең илебездә урман-тауларның чисталыгы һәрвакыт игътибар үзәгендә. Альпинистик лагерьларда да, мәсәлән, тәртип шулай куелган: юлга чыкканда сумкаңда ничә банка яки консерв ризыгың бар, кире кайтканда, һәр кеше әнә шул бушаган савытларны күрсәтергә тиеш. Чөнки сер түгел, Һималай тауларының бик нык чүпләнүе һәм башка тауларга әнә шундый куркыныч янавы соңгы елларда проблема булып калыкты.

— 14 ел буе җәйне сәяхәттә уздыруыгыз турында сөйләдегез. Ә менә сезнең гаиләгез ничек карый соң? Иптәшегез җәйге ялны бергә уздыру турында сүз кузгатмыймы?

— Хатыным да таулар ярата. Туры килгәндә, сәяхәтләргә бергә чыгабыз. Тик тормыш, гаилә мәшәкатьләре белән аңа бу бәхет сирәк эләгә. Ә мине ул дөрес аңлый, ышана һәм әлегә хәтле каршы килгәне дә булмады.

— Сәяхәтләрдә ял иткәндә күбрәк нәрсә турында сөйләшергә яратасыз?

— Бу турыда сорагач, инглизләр: «...Ашау-эчү темасы бөтен сөйләшүнең 90 процентын, экспедиция планнары һәм политика — 9,5 процентны, ә хатын-кызлар турында сөйләшү 0,5 процентны гына тәшкил итә»,— дигәннәр. Безнең альпинистлар ашау-эчү, план-политика темаларына бертигез дәрәҗәдә тукталалар. Ә хатын-кыз турында сүз бездә дә сирәк кузгала. Аның каравы без кыяларга күтәрелгәндә аларны уйлап көч алабыз, биеклеккә рухланабыз.

— Валерий Сергеевич! Таулар гизү, биеклекләр яулауда шактый тәҗрибәгез бар. Алардан нәтиҗә ясап, тагын бер сорауга җавап бирсәгез иде. Альпинизм кешегә нәрсә бирә?

— Күренекле совет галиме, Арктика тикшеренүчесе, шулай ук альпинистларның Памир экспедициясе җитәкчесе О. Ю. Шмидт сүзләре белән әйтсәк, биек тауларга, бозлы кыяларга күтәрелгәндә алган чыныгуны башка бер генә спорт төре дә бирә алмый. Ә иң әһәмиятлесе — ул кешенең характерын чыныкта. Таулар кеше алдына авыр һәм катлаулы бурычлар куя. Аларны җиңеп чыгуның иң кыска, иң уңайлы юлларын эзләү, уйлау процессында кешенең фикерләү сәләте көчәя, ихтыяр көче ныгый, кыюлыгы, үз дигәненә ирешү омтылышы, төгәллеге, зирәклеге, җитезлеге арта. Кеше монда үзе өчен генә түгел, юлдашлары өчен дә үзенең бөтен мөмкинлеген эшкә җигә. Ә ерак сәя-

хәтләр, табигатьнең искиткеч гүзәл, бай күренешләрен гизеп йөрү, боз бушлыкларының гаҗәеп саф һавасын сулау, иң биек түбәдән офыкны күзәтү кешенең хисләрен баета, эчке һәм тышкы мәгълүматын киңәйтә, аны көндәлек тормыш ваклыкларыннан өскә күтәрә, кеше шәхесен идеаллаштыра.

Әңгәмәне *Я. Абдулкадыйрова* алып барды

ХӨКЕМ — СОҢГЫ ЧИК

Казанның Менжинский исемендәге клубында эчке эшләр органнары үзешчән сәнгать коллективларының концерты бара. Сәхнәгә әле ансамбльләр, әле нәфис сүз осталары, әле биючеләр чыга. Менә концертны алып баручы: «Совет районы эчке эшләр бүлегеннән майор Диләрә Вәлиуллина җырлый»,— дип белдерә. Сәхнәдән «Көймә генә килә генә», «Сибелә чәчәк», аннары «Тәфтиләү» көйләре агыла. Тыңлаучыларның үзешчән артистны һаман җибәрәселәре килми. Зал бик сорагач, ул яңадан сәхнәгә чыга, һәм җыр чылтырап аккан чишмәдәй дәвам итә...

Мөгаен, безнең Татарстан милиция хезмәткәрләреннән әле берәү дә татар халык җырларын башкару осталыгында Диләрәдән уздыра алганы юктыр. Үзешчән артисткага, төрле фестивальләрдә катнашып, илебезнең байтак шәһәрләрендә чыгыш ясарга туры килгәне бар. Ә 1977 елда, совет милициясенең 60 еллыгына багышланган Бөтенсоюз фестивалендә лауреат исемен алып, ул башкалабыз Мәскәүгә бару бәхетенә иреште. Башкала тамашачылары аны шунда «Татарстан сандугачы» дип атадылар. Диләрә Вәлиуллина Мәскәүдән милиция капитаны званиесендә кайтты. Бу чин аңа, СССР эчке эшләр министрының махсус приказы белән срогыннан алда бирелгән иде.

Буа, Чепья, Теләче, Саба ягы кешеләре озын буйлы, мәһабәт гәүдәле милиция хезмәткәре Миңзариф Газизовны, мөгаен, хәтерлидер әле. Ул бик күпләргә чын тормыш юлына басарга ярдәм итте. Файдалы киңәше, җылы сүзе белән һәркемгә ярдәмгә килергә әзер торды. Миңзариф абый тугыз балалы зур гаилә башлыгы, яхшы ата буларак та билгеле иде. Аның кызлары, малайлары бик тәр-

типле, тырыш, уңган булып үстеләр. Балалар әтиләреннән тагын бер сыйфатны үзләренә мирас иттеләр: җырларга оста булдылар. Хәзер җәйге ял чорларында әниләре Хәернниса апа янына — Теләче авылына барлык балалары җыела. Шунда аларның берсе кулына баян ала, икенчеләре җырлый башлы. Әгәр милиция майоры Миңзариф Газизов үзе дә исән булса, мөгаен, җырга кушылмыйча калмас иде.

— Балаларым, илгә файдалы кешеләр булып үсегез,— дия иде Миңзариф абый һәрвакыт. Аның балалары — укытучылар да, төзүчеләр, медицина белгече дә, хуҗалык җитәкчесе, инженер да, милиция работниклары да.

Диләрә Миңзарифовнаның эчке эшләр органнарында хезмәт юлы 1966 елда Казан дәүләт университетының юридик факультетын тәмамлагач башланды. Аны башта Биектау районы эчке эшләр бүлегенең балигъ булмаганнар эше буенча инспекциясенә билгеләделәр. Аннары җинаятьләрне ачыклау бүлегенә инспектор итеп күчерделәр. Берничә елдан шунда ук тикшерүче булды. 1974 елда гаиләләре Казанга күчкәч, ул Идел буе эчке эшләр бүлегенең тикшерүләр бүлекчәсендә эшли башлады. Хәзер инде шактый еллар Совет районы эчке эшләр бүлегендә өлкән тикшерүче булып хезмәт итә. Дөресен әйтергә кирәк, бездә җиңел кәсеп белән яшәргә тырышучылар, әрәмтамаклар, байлык артыннан куучылар әле шактый очрый. Милиция майоры Диләрә Миңзарифовна Вәлиуллина, бөтен белемен һәм тәҗрибәсен эшкә җигеп, әнә шундыйларның чын йөзен ача.

Аның кабинетына беренче тапкыр барып кергәч, мин гаҗәпкә калдым. Идәндә... берсеннән-берсе матур хатынкыз аяк киемнәре тезелеп тора иде. Әйтерсең, сатарга әзерләп куелганнар, үзләренең хуҗаларын көтәләр. Минем гаҗәпләнүемне күреп, өлкән тикшерүче:

— Әле шушы көннәрдә генә безнең бүлек хезмәткәрләре берәүне базарда сатып торганда тоттылар. Казан аэропортында эшләүче кеше булып чыкты. Шушыларны алырга дип махсус рәвештә Ереванга барган. Бәясен икеләтә арттырып сатып, акча «эшләп» алырга уйлаган.

Үзенең нинди бүлмәгә эләгүен белмәгән кеше башта, мөгаен, монда бухгалтерия икән дип тә уйлар. Әнә киштәләрдә — төрле-төрле папкалар, өстәлдә — хисаплау машинасы. Стена буенда зур гына сейф тора. Ләкин әлеге папкаларда саннар кушылмасы түгел, бәлки кайбер кешеләрнең кыңгыр эшләре җыелмасы тупланган. Аларның берәүләре, тикшерүе тәмамланып, инде ябылу алдында

тора. Икенчеләре әле яңа ачылган. Һәрберсе өлкән тикшерүчедән күп энергия, сабырлык, белем һәм вакыт сорый. Җыр, музыка яратучы кеше нечкә күңелле, йомшак характерлы була диләр. Әлеге сыйфатлар Диләрә Миңзарифовнага эшендә кыенлык китермиме соң? Аңа һәрвакыт җинаятьчеләр белән йөзгә-йөз очрашырга, кырыс булырга туры килә бит. Бу хакта сорагач, өлкән тикшерүче: «Белмим шул. Ул хакта уйлаганым да юк»,— дип җавап бирде. Диләрә Вәлиуллинаның үз эшен зур осталык белән башкаруына ирексездән сокланасың.

— Менә бу папкадагы «эш» белән шактый озак шөгыльләнергә туры килде,— диде Диләрә Миңзарифовна, киштәдәге бер папканы алып.

...Аны базарда тун сатып торганда эләктерәләр. Һәр ял саен бер ир кешенең кыйммәтле туннар, иләгән тиреләр, мех якалар сатуы хакында милиция бүлегенә сигналлар булгалый. Социалистик милекне урлауга каршы көрәш бүлекчәсе инспекторлары тиздән аны ачыклыйлар һәм артыннан күзәтә башлыйлар. Әлеге кеше туннарны танышлары аша кибеттән сатып ала да базарга алып барып үз бәясеннән шактый арттырып сата икән. Тоткарлаганда аннан шундый ансат юл белән нибары бер көндә җыелган 900 сум акча чыга. Әлеге ир кеше үзе яңарак пенсиягә чыккан икән. Һәм тагын шунысы гаҗәп: аның кесәсеннән... халык дружинасы члены һәм милиция хезмәткәре таныклыклары да табыла. Экспертиза әлеге документларның ялган булуын ачыклый, ә аларга ябыштырган фотолар моныкы. Милиция хезмәткәре таныклыгы кайчандыр бөтенләй икенче кеше исеменә бирелгән була. Документ ничек итеп бу кулга эләккән?..

Бу кеше спекуляция юлы белән инде шактый байлык тупларга өлгергән икән. Ул үзе, әлбәттә, акчасы булуын бөтенләй инкарь итә. Әмма тентү вакытында аның өендә суыткыч радиаторыннан төргәк белән 10 мең сум акча табып алалар. Шулай ук сатарга дип әзерләнгән тун, тиреләр дә чыга. Хатыны, шулкадәр акчалары барлыгын күргәч, гаҗәпкә кала һәм: «Миңа иткә, сөткә дә акчаны исәпләп кенә бирә иде. Дөньяның бөтен рәхәтеннән мәхрүм итеп яшәтте»,— дип елап җибәрә. Бөтен уңайлыклары белән квартиралары, әйбәт дачалары бар. Рәхәтләнеп яшисе генә бит. Юк, ул моңа риза булмыйча, җиңел генә баю юлларын эзли башлый. Аның ахыры менә шулай бик күңелсез тәмамлана.

— Бу «эш» тә күп вакытны алды,— диде өлкән тикшерүче, минем алга яңа папка куеп.

...В. бер фәнни-тикшеренү институтында да, циркта да эшләп ала. Әмма ул үз талантына әле мәйдан һаман табылмый дип исәпли. Шуннан соң әлеге хатын үзенең хыялын эшкә җигә һәм... аның талантына ышанучылар да табыла. Бервакыт ул Васильеводагы «Победа труда» заводының товароведы Л. белән очраша һәм үзен журналистка дип таныштыра, бөтен җирдә бик шәп танышлары булу белән мактана. Л. аңа алтын чылбыр алырга исәбе барлыгын әйтә һәм ярдәм итүен сорый. «Була ул»,— ди В. Һәм яңа танышыннан 800 сум акча ала. Шуннан соң «журналистка» югала. Күп вакытлардан соң очраклы рәвештә генә урамда очрагач, ул Л. га Төньяк полюста... командировкада булуын әйтә, бөтенесен юлларга вәгъдә итә.

Тиздән аның кармагына «Стрела» магазины хезмәткәре Сычев эләгә. Бу юлы инде «Район прокуратурасы тикшерүчесе». Аферистка җәтмәсенә барлыгы 22 кеше эләгә. Алар «журналистка»га, «тикшерүче»гә үз куллары белән 18 мең 586 сум акча бирәләр. Безнең законнарны әйләнеп үтеп, ансат кына теге яки бу максатка ирешергә тырышу кешеләрне менә шундый юлга бастыра. Шуңа күрә әлеге кешеләр өлкән тикшерүче белән очрашуга да бик теләмичә генә киләләр...

Соңгы вакытта, олы тәҗрибәсен исәпкә алып, Диләрә Миңзарифовнага яшүсмерләр һәм балигъ булмаганнар арасындагы җинаять эшләрен тикшерүне тапшырдылар. Мөгаен, Биектау районында чакта эчке эшләр бүлегенең шундый яшьтәгеләр буенча инспекциясендә зур тырышлык күрсәтүен дә истә тотканнардыр. Менә ул яңадан әле тормышка аяк басып кына килүче яшүсмерләр белән очраша. Аерма шунда: Диләрә Миңзарифовна элек аларны төрле тәртип бозулардан кисәтә, вакытында дөрес юлга басарга ярдәм итә иде. Ә хәзер исә кылган җинаятьләрен фаш итә, аларның совет законнары каршында ни дәрәҗәдә гаепле булуларын ачыклый. Аңа элеккечә тәмле тел белән сөйләшеп утырырга туры килми. Гадәттә, җинаять эшләгән кеше үзенең гаебен һәрвакыт кечерәйтеп, киметеп күрсәтергә тырыша. Бу — яшүсмерләргә дә хас. Андый чакта шактый каты сөйләшергә туры килә.

Диләрә Миңзарифовнаны соңгы елларда яшүсмерләр арасында җинаятьләрнең шактый артуы нык борчый. Һәм һәр тикшерү саен ул шуңа ышана: яшь кешене тәрбияләүдә, аны дөрес формалаштыруда гаилә зур роль уйный. Тикмәгә генә гаиләне җәмгыятьнең иң төп күзәнәге дип атамыйлар шул. Әгәр бу күзәнәк черек икән, ахыргы нәти-

җәләрнең нинди буласын күз алдына китерү кыен түгел. Андый гаиләдә юньле кеше тәрбияләнми. Халыктагы «Оясында ни күрсә, очканда шундый булыр», «Алма агачыннан ерак төшми» дигән әйтемнәр дә нәкъ менә шундый мәгънәне аңлаталар бит. Теге яки бу уңайдан мәктәпләрдә, ата-аналар белән очрашуларда чыгыш ясаса, Диләрә Миңзарифовна һәрвакыт әлеге фикерне еш кабатлый. «Урам тәрбиясе» дигән сүз белән акланырга тырышучыларга да аның сүзе бер була. «Үзегездәге җитешсезлекне урамга сылтамагыз. Киресенчә, улыгызны яки кызыгызны яхшырак тәрбияләргә тырышыгыз, аны кечкенәдән үк яманны таный белергә өйрәтегез»,— ди ул андый ата-аналарга.

Күптән түгел бер төркем яшүсмерләр кылган җинаятьләрне тикшергәндә аңа ата-аналардан мондый аклануларны шактый ишетергә туры килде. Әмма мәсьәләнең асылында тагын шул ук нәрсә — гаиләдә тиешле тәрбия җитмәү ята иде. Берничә яшүсмер егеттән торган бу төркем узган җәйдә Казанка яры буендагы бакчаларда тәртипсезлекләр эшләгән. Болар байтак дача йортыннан әйбер урлыйлар һәм аны ярым-йорты бәясенә саталар. Акчасы, билгеле, күңел ачуга китә. Бу хулиганнар йортларның тәрәзәләрен ваталар, ишеген каералар, андагы һәртөрле кирәк-яракны туздыралар. Аннары төнгә урамда калган автомашиналарга, мотоциклларга да тынгылык бирмиләр. Мәсәлән, Дашкин дигән берәү Татарстан башкаласына Пензадан үз автомобиле белән килә. Ул машинасын Пионер урамында калдыра да танышларына кереп йоклый. Кич белән урамда йөргәндә әлеге җиңел машина хулиганнар күзенә бик тиз чагыла. Алар, алгы яктагы пыяланы алып, машина эченнән әйберләрен урлыйлар. Икенче вакыт 8 Март урамындагы бер җиңел машинаны кабызып алып китәләр. Туйганчы йөреп күңел ачкач, аны шәһәр читендәге тын урамда ташлап калдыралар һәм төрле частьларын сүтеп алалар. Урамдагы саклаучысыз пиво мичкәсеннән сыра алып төне буе кәеф-сафа кору да калмый болардан. Ләкин бездә ачылмыйча калган җинаятьләр бик аз. Әлеге үсмерләрнең кыңгыр эшләренә дә чик куелды. Гражданнардан берничә сигнал алынуга, милиция хезмәткәрләре аларның эзенә төштеләр.

Өлкән тикшерүчегә аларның һәрберсе белән йөзгә-йөз очрашып бик озаклап сөйләшергә туры килде. Менә шунда теге хакыйкать тагын бер тапкыр расланды. Әйе, гаиләдә тәртип булмаса, анда бала юньле тәрбия ала алмый, «урам йогынтысы»на бик тиз бирелүчән була. Менә шул

ук компаниядәге Игорь дигән үсмерне алыйк. Аның әтисе бер исерек икән, үзен инде күп җирдән эштән куганнар. Кая гына керсә дә, юньләп эшләмәгән. Мондый атадан бала тәрбиясе көтеп буламы соң? Әнисе үлеп киткәч, Игорьга берниинди контроль калмый. Ул көннәр буе урамда йөри, кайчакта кунарга да кайтмый. Җинаятьчеләр арасында алтынчы классны яңа тәмамлаган малайны да күрү Диләрә Миңзарифовнаны аеруча борчый. Баксаң, моңысына да гаиләдәге чатаклыклар сәбәпче икән. Әлеге малай — Сергей — үги әни белән яши: үги — үги инде, аның малайга җылы сүз әйтергә, юньле киңәш бирергә, әйбәтләп өс-башын карарга да вакыты «җитми». Яшүсмер исә «киңәшче»ләрне урамда таба. Алар Сергейны үз компанияләренә бик теләп алалар.

— Хәзер яшәү урыннарында тәрбия эшен аеруча нык көчәйтергә кирәк. Монда йортлар идарәләре, торак-эксплуатация участоклары каршындагы җәмәгатьчелек активына олы бурыч йөкләнә. Алар үз микрорайоннарындагы һәр гаиләнең ничек яшәвен белеп торырга, кирәк чакта тәрбияви ярдәм күрсәтергә бурычлылар. Шунсыз уңышка ирешергә мөмкин түгел,— ди Диләрә Миңзарифовна.

...Диләрә Миңзарифовна эштән шактый арып кайтты. Әмма почта ящигында күптән көтелгән хатны күргәч, арыганлыкның эзе дә калмады. Ул Ленинград өлкәсендәге кызы Гөлнара белән кияүләреннән иде. Алар хәзер шунда яшиләр. Инде кечкенәләре дә бар. Тормышлары бик әйбәт бара икән. Диләрә Миңзарифовнаның күңеле бөтенләй күтәрелде. Ул кухняда аш әзерләгәндә үзе дә сизмәстән җырлап җибәрде. Ире, ТАССР Агропромышленность дәүләт комитетының бүлек начальнигы урынбасары Илгиз Хәлимович Вәлиуллин өйгә кайтканда аны шул хәлдә күрде.

— Берәр шатлыгың бар, ахры? — диде ул, хатынының күзләренә карап.

— Әнә Гөлнаралардан хат килде,— диде Диләрә Миңзарифовна.

Ул кичтә Вәлиуллиннар өендә куанычтан җыр да, музыка да яңгырады. Ире пианинода уйнады, Диләрә үзе җырлады.

Нургали Булатов

ЕГЕРМЕ МЕҢ ЕЛ БЕРГӘ!

Күп кенә илләрнең галимнәре раславынча эт кеше кулына иялэнгән иң беренче хайваннардан санала. Австриянең күренекле галиме Конрад Лоренцның фикере буенча, мәсәлән, кеше үз куышына этне безнең эрага хәтле 20 мең ел элек иялэндергән булган. Шул чордан бирле эт кешенең иң ышанычлы, иң тугры дусты булып исәпләнә. Күренекле инглиз галиме Ч. Дарвин алар турында: «Безне үзләренә караганда да ныграк яратучылар»,— ди.

1967 елда ДОСААФның Зеленодольск шәһәр комитеты каршында эт өйрәтүчеләр җәмгыяте клубы оеша. Анда йөрүчеләр саны көннән-көн күбәя. Берсе клубка әле әнисен имүдән дә туктамаган юеш борынлы нәни йонтәсен күтәреп килә, икенчесе үткән бер кешегә капка астыннан өреп калудан башканы белми картайган йорт этен ияртеп килә, кайберләренең этләре инде күргәзмәләрдә призлар яуларга өлгергән. Ә менә сатучы Бэлла Владимировна Бирюкова көнчыгыш Европа овчаркасы белән килде. Хуҗасыннан бер адымга да калышмый янәшә атлап баруы белән үк эт башкаларның игътибарын җәлеп итте. Вакыты-вакыты белән ул Бэлла Владимировнаның күзләренә карап ала. Бу этнең затлы нәселдән булуы бөтен килешкилбәтеннән күренеп тора. Ул аның акыллы күзләрендә дә, үз-үзен тотышында да, үз дәрәҗәсен белеп вәкарь генә атлавында да чагыла.

Алар шәһәр урамнарыннан үткәндә күпләр сокланып елмаеп калалар. Билгеле инде, малайлар бигрәк тә... Һәркайсының күз карашыннан: «Эх, минем дә шундый этем булса иде!» — дигән уйны укып була. Кайберләре шүрләп, читкә тайпылалар, кайберәүләрнең күзләрендә — ачу һәм нәфрәт. Алары, мөгаен, язын ачылган беренче яфракка да, кышын күктән сибелгән энҗедәй кар бөртекләренә дә сөенә белми торган кешеләрдер... Ә Наил бу овчарканы беренче күрүгә үк исемен сорады. Лада икән. Яңа танышының һөнәрен беләсе килеп, күнегүләр вакытында яшеренеп кенә күзәтте. Ниһаять, үсмер егетнең малай чактан ук бөреләнгән хыялына юл салынды. Ладаның бәбиләре булды. Әлбәттә, Бэлла Владимировна аның берсен Наилгә тәкъдим итте. Аңа исемне дә Наил үзе кушты.

Лир кушаматлы нәни йонтәскә бер ай тулуга Наил аны күтәреп клубка килде... Эт өйрәтүчеләр клубының һәвәскәр члены Наил Яруллин белән бүгенге әңгәмәбездә әнә шулай башланган биографияне дәвам итәбез.

— Наил, Лирны дус малайларыгызны кызыктыру өчен генә алдыгызмы, әллә аны өйрәтүне башта ук максат итеп куйган идегезме?

— Хайваннар белән мавыгуым эттән түгел, төлкедән башланды. Җиденче класста укыганда сазлыкта адашып калган төлке баласы таптым. Алтынсу йөнтәс ул җан иясен ташлап китәргә кызгандым, өйгә алып кайттым. Бер ел ашатып-эчертеп үстердем. Тычканнар тотып, үз-үзен туйдыра башлаганын сизгәч, кире урманга илттем.

Аннан соң канатын мәче яралаган карганы дәваладым. Ул миңа шул хәтле нянәнде. Һәр көнне мәктәпкә озата торган булып китте. Аңа Гришка дип исем куштым. Бераз командалар үтәргә өйрәттем. Аларны үзләштерүен күрү хайваннар өйрәтү белән мавыгуымны көчәйтте. Көчемне этләр өйрәтүдә сынап карарга булдым. Һәм шушы теләгем мине эт өйрәтүчеләр клубына алып килде дә.

— Лир — беренче тапкыр өйрәткән овчаркагыз димәк. Аның белән чик буенда да хезмәт иткәнсез дип ишеттем, дөресме?

— Үзебез өйрәткән этләр белән илебез иминлеген саклау бәхетенә ирешүчеләр — без өчәү идек. Рифкать Шиһабетдинов, Наил Әхтәмов һәм мин. Өчебез дә Ладаның балаларын өйрәтеп үстердек. Ерак Көнчыгышта, бер частьта, бер отрядта хезмәт иттек. Әлбәттә, бу ышанычны яулау өчен, эт өйрәтү буенча, клубтан алган программа нигезендә, киеренке режимда шөгыльләнергә туры килде. Армиягә киткәнче овчаркаларыбыз гомуми курс нормаларының икенче дәрәҗәсен уңышлы тапшырдылар. Һәм хәрби хезмәткә яраклы дип табылдылар.

Дүрт аяклы дусларыбыз хәрби хезмәттә безнең ышанычыбызны акладылар. Аерым батырлыклар белән танылмасалар да, илебез чиге сагында сизгер, уяу тордылар. Шулай да хәтердә кечкенә генә бер вакыйга саклана. Сак-та чакта көймәбезне кинәт көнә елга дулкыны кире якка борып куйды. Шулчак көймә борынында басып барган Лир кинәт суга төшеп китте. Кызу йөзгән моторлы көймә, көчле агым аны бик тиз артка калдырды. Җитмәсә, эре-эре боз кисәкләре Лирның күкрәгенә бәреп, йөзәргә комачаулый иде. Мин борылып кире килеп җиткәнче, этем хәлсезләнеп өлгергән. Шулай итеп аны үземә коткарырга туры килде. Шул вакыйгадан соң Лир безнең чын дуслыгыбызга кабат ышангандай булды.

— Наил, мондый шөгыльнең кешеләрдә яхшы сыйфатлар формалашуга уңай тәэсире бар дип уйлыйсызмы?

— Һичшиксез! Этләрне ерткыч хайваннар рәтенә керт-

сәк тә, алар бездән башка көчсез, яклауга мохтаҗ җан ияләре. Балачактан алып үстерсәң, эт сиңа беркайчан да тугрылыгын югалтмый. Хәтта җәберләсәң дә сиңа ташланмый. Киресенчә, үз гаебен таныгандай, колакларын яткызып, каршыңа килеп ята да, күзләрен мөлдерәтеп карашын сиңа төби. Аның мондый күндәмлеген, акылын бәяләп, аны якын дус итәргә алынган яшьләр миндә аерым бер соклану уята. Эт белән даими шөгыльләнүгә ихтыяр көчен туплый алган егет яки кыз үз тормышын да төгәл режимга көйли. Этләр өйрәтүгә алынуның тагын бер отышлы ягы шунда — ул кешенең холкындагы тискәре гадәтләрне дәвалый. Чөнки эт хуҗасының нервлары тәртиптә түгеллеген тиз сизә. Командаларны үтәгәндә борчыла, игътибарсыз була башлый. Шуңа күрә этләр янында сабыр булырга, үз-үзеңне әдәпле тотарга мәҗбүр буласың. Әкренләп ул сыйфатлар синдә чынлап тамыр җәя.

— Наил, этләрне өйрәтә башлауның срогы, урыны, беренче күнегүләргә кыскача гына тукталсагыз иде.

— Мин үзем эт баласын 1 айлык чагыннан өйрәтә башлыйм. Занятиеләр вакытында игътибары таркалмасын өчен аның белән икәүдән-икәү генә булу шарт. Беренче күнегү — этнең үз исемен танырга өйрәтүдән башлана. Аннан соң «Фу» («ярамый») дигән авазлар тезмәсенә күчәсең. «Утырырга!», «Ятарга!», «Торырга!», «Яннан атла!» дигән командаларны кабатлый-кабатлый катлаулырак күнегүләр өйрәтүне дәвам итәргә кирәк. Эт өйрәтүчеләр өчен китапханәләрдә методик ярдәмлекләр дә бар. Ә иң яхшысы — эт өйрәтүчеләр җәмгыяте белән элемтәдә тору. Чөнки йортта асрала торган этләрнең сәламәтлеген күзәтеп тору һәм кирәкле профилактик чаралар үткәрү буенча да клуб зур ярдәм күрсәтә ала. Әмма, кызганычка каршы, бик күп районнарда ДОСААФ оешмалары эт өйрәтүчеләр җәмгыяте клубы эшчәнлеген яхшыртуны кирәк тапмыйлар. Ә бит яшьләр, үсмерләр, балалар арасында эт асраучылар бик күп. Тик аларның күбесе өйрәтелми. Өйрәтелмәгән этләр кирәк-кирәкмәгәнгә өрүдән башканы белмиләр, хәтта аңсыз усаллык яки хуҗаларының алар белән дөрес идарә итә белмәве аркасында төрле бәхетсезлек китереп чыгаралар.

— Наил, яхшы өйрәтелгән этләр белән бүген тормыш-көнкүрештә нинди файдалы эшләр башкарырга мөмкин булуын әйтә аласызмы?

— Җир шарының Төньяк һәм Көньяк полюсларына беренче эзләрне салуда, Ватан сугышында дошман танкларын шартлатуда, элемтә эшен башкаруда, яралыларны

табып ташуда, медицина өлкәсендә әһәмиятле ачышлар ясауда, хәтта галәмне яулауда кешеләрнең иң зур ярдәмчесе этләр икәнлеген кем генә белми! Дүрт аяклы акыллы, тугрылыклы дусларыбызны өйрәтеп үстерүгә көчебезне, вакытыбызны кызганмасак, алар бүгенге тормышта да бик күп файда китерә алырлар иде. Көнчыгыш Европа овчаркалары, мәсәлән, әйтеп үткәнебезчә, чик буенда, җинаятьчеләрне эзләүдә хезмәт итәләр.

Этнең батырлыгы борынгы заманнардан ук югары бәяләнгән. Мәсәлән, эткә беренче һәйкәл безнең эрага кадәр IV гасырда Коринф шәһәрендә куелган дип исәпләнә. Соэтр исемле эт, шәһәргә яшеренеп кенә дошман якынлашуын сизеп, бөтен гарнизонны уята. Үз вакытында башланган контрһөҗүм дошманны җиңәргә ярдәм итә. Тугры Соэтрга исән чакта ук һәйкәл куела. Һәм аңа «Коринфның коткаручысы һәм яклаучысы» дигән сүзләр язылган көмеш муенчак тагыла.

XIII гасырда Барри исемле эт хөрмәтенә Парижда салынган һәйкәлнең тарихы шундый.

Италияне Үзәк Европа илләре белән тоташтыручы юл Альп тауларының Сенбернар кичүе аша узган. Ике километр ярым биеклектән үткәнгә, кискен үзгәрүче һава шартлары юлчыларга бик күп һәлакәтләр китергән. Аларны коткаруда Сенбернар этләре генә ярдәм итә алган. Шулар арасында Барри исемле эт аеруча батырлык казанган. Ул кар астында күмелеп калган 41 кешене үлемнән коткара. Әмма аларның 41 нчесе...

Бу юлы алар көрт күмеп киткән кешеләрне озак эзлиләр. Тик таба алмыйлар. Кайтып китәләр. Барри гына эзләвен дәвам итә. Ниһаять, аның сиземләве бу юлы да дөрескә чыга. Ул көрт күмеп киткән юлчыны казып чыгара. Өшүдән хәрәкәтсез яткан кешенең битен ялый. Ә кеше аңына килеп күзен ачуга, Барриңы бүре дип белеп, револьверы белән (пычагы белән дигән версия дә саклана) аны үтерә...

Шотландия, көньяк рус, Кавказ овчаркалары далаларда, тауларда маллар көтәләр. Овчаркаларны тагын руда эзләүдә һәм газ инспекторлары итеп файдаланырга мөмкин. Гигант сыман кара, йөнтәс ньюфаундлендлар суда яхшы йөзәләр, оста чумалар. Әгәр аларны өйрәтеп үстерсәң, суга батучыларны коткаруда аларны беркем дә алыштыра алмый. Себердә лайкаларны җигеп, кешеләр, йөкләр ташыйлар. Тагын аучыларга кошлар, җәнлекләр аулауда ярдәм итүче этләр күпме. Әллә нихәтле декоратив бүлмә этләре токымнарын санарга була.

— Наил, үз тәҗрибәгездән чыгып эт асраучыларга нинди киңәшләр бирер идегез?

— Өлкәннәргә дә, балаларга да киңәшем шул: нәни җан иясен юаныч итеп алгансыз икән, үсеп җиткәч кызыгы юк дип, урамга чыгарып ташларлык итмәгез. Иренмичә өйрәтеп үстерсәгез, аны кызганыч язмыштан коткару белән бергә, ул сезнең үзегездә дә ихтыяр көче тәрбияләргә ярдәм итәр. Дүрт аяклы дустыгыз көче белән дә, акылы белән дә сезгә тугры хезмәт итәр.

Әңгәмәне *Язилә Абдулкадыйрова*
язып алды

«КҮКТӘ — ТӨН ПӘРИЛӘРЕ»

«Күктә — төн пәриләре» исемле фильмны легендар 46 нчы хатын-кызлар гвардия авиаполкы штурманы, Кызыл Йолдыз, II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм дистәләгән медальләр кавалеры Александра Семеновна Попова белән Ессентукида янәшә утырып карадык. Аның бу картинаны беренче тапкыр гына күрүе түгеллеген белә идем. Шулай да экрандагы һәрбер авыр, кызганыч эпизодтан соң сиздерми генә аңа күз салам. Әлбәттә, сизүеннән юкка куркам. Ул — бөтен барлыгы белән фильмдагы кызлар арасында. 46 нчы гвардия полкы сугышчыларының шатлыгын бүлешә, хәсрәтен уртаклаша...

Картина тәмамланды, халык тарала башлады. Ә Александра Семеновна утыра бирә. Аның күңелендә картина дәвам итә...

— Александра Семеновна! Режиссерның иҗаты чынбарлык белән туры киләме? — дип, сак кына сорап куйдым.

— Килә генәмени. Утлы-давыллы мең дә бер йөз тәүлекнең тамчысы гына — нибары өч көне генә бит болар. Моңа охшаш сорауны миңа улым да биргән иде. Краснодарда Кубань дәүләт университетында укыган чагы. Янына бардым. Һәм очраклы рәвештә шушы фильмны беренче тапкыр күрү бәхетенә ирештем. Улым белән бергә карадык. Чыкканда: «Шундый яхшы фильм. Шул ук вакытны бик куркыныч та, арттырыбрак җибәргәннәр ахры. Берсеннән-берсе яшь, гүзәл, нечкә хисле кызларның бу хәтле

кыюлыгына ышанасы да килми»,— ди бу, миңа сынаулы карап. «Шунысын да исеңдә тот, улым, алар — Ватан өчен сугышка үзләре теләп кергән кызлар. Һәркайсы туган ил бәхете хакына гомерләрен бирергә әзер иде. Ә бит барысы да тормышка гашыйклар, талпынып-канатланып яши, янып сөя торган чаклары иде. Әмма күпләренең хыяллары язмышлары белән бергә шунда өзелеп тә калды...» дип аңлатырга туры килде үзенә.

— Фильмны төшергәнче режиссер сценарий турында полк сугышчылары белән очрашып киңәшмәдеме?

— Монда безне җыеп киңәш сорауның хаҗәте булмагандыр дип беләм. Чөнки режиссер — Советлар Союзы Герое очучы Евгения Андреевна Жигуленко үзе безнең полкташыбыз. Аның белән бер эскадрильяда идем. Беренче мәртәбә бергә очарга да туры килде әле үзе белән. Сугышчан заданиеләрне үтәүгә иң җитди карый торган очучыларның берсе иде ул.

Женяның бөтен хыялы — җиңү яулап исән калсак, гүзәл кызларыбызның батырлыгы турында фильм иҗат итү иде. Һәм сүзендә торды да. Сугыштан соң В. И. Ленин исемендәге Хәрби политик академияне тәмамлады. Тормышын, хезмәтен армия, авиация белән бәйләгән Женябызның кинематография институтын тәмамлаганын белми дә калдык. Беренче итеп «Күктә — төн пәриләре» фильмын куйды. Аннан соң «Хаталанырга хакыбыз юк» дигән картинасы чыкты.

— Александра Семеновна, «Күктә — төн пәриләре» исемле фильмда сезнең сугыш елларыгыздагы вакыйгаларга охшаш эпизодлар юкмы?

— Фильм полкның оешып, һөҗүмгә керешкән вакытны эченә алган. Беренче сугышчан очышны полк командиры Евдокия Давыдовна Бершанская экипажы ясаган иде. Картина шуннан башлана. Фильмда күбрәк очучылар тормышы чагылдырылган. Ә мин полкка килгәч үк техник булып билгеләндем. Соңрак Нина Распопова, Мария Смирнова, Нина Худяковалар ярдәме белән штурман булып киттем. Керчь өчен барган сугышларда Женя Жигуленко белән беренче тапкыр хәрби очышка чыктым. Шул очышларның берсендә безнең экипаж дошманның аэродромын шартлатырга задание алды. Караңгы, җилле төн. «Карлыгач»ыбыз (ПО-2 самолеты) як-якка чайкала. Аэродром өстендә тынлык. Прожекторлар да эшләми. Дошман безнең килгәнне сиздерми генә көтә. Женя җирдә очкынсыман гына ут күреп алган. Миңа әзер булырга кушып, курсны шул якка тотты. Нәкъ билгеләнгән ноктага килеп

чыкканбыз: бомбаларны ташлавым булды, җирдән бер-бер артлы ут-ялкын өермәсе күтәрелде. Һөҗүмнең бу хәтле төгәллеген көтмәгән фашист, прожекторлары белән күкне айкап, зениткадан, пулеметлардан безгә ут ачты....

Ә Клава Серебрякова белән Булганак юлында һөҗүмгә чыккач, заданиене үтәгәнче үк, немецларның күзне чагылдырырлык прожектор зонасына эләктек. Көчле ут ачтылар. Аннан ычкынган секундларда билгеләнгән ноктаны эзлибез. Уебыз исән калу, полкка әйләнеп кайту түгел, заданиене үтәү. Бөтен игътибар — күзләрдә, ә күзләр җирдәге объектны эзли. Ниһаять, билгеләнгән ноктаны шартлаттык. Әмма, кайтыр якка борылгач, пуля тиеп самолетыбызның моторы сүнде. 600 метр биеклектә; диңгез өстендә идек. Клаваның оста идарә итүе аркасында җиргә җитә алдык. Бәхеткә каршы, үзебез, җиңелчә җәрәхәтләр генә алып, исән калдык. Җилдән җитез фанер «карлыгачыбыз» гына әрәм булды. Вакытында кайтмагач, эскадрильяда безне борчылып көткәннәр. Таң атканда арып, пычранып кайтып кергәч, куанычларының чиге булмады.

Фильмдагы боларга охшаш күренешләрне фәкать безнекедер дип булмый, чөнки андый хәлләр полк тормышында төн саен кабатланып тора иде.

— Картинаның исемендә режиссер сезне ни өчен «төн пәриләре»нә тиңләгәндер дип уйлыйсыз?

— Бу безгә фашист таккан исем. Максатларына ирешми торып дошман өстендә бөтерелүдән туктамаган каһарман кызларыбызга нинди генә исемнәр кушмадылар алар. Янәсе, безнең полк «башкисәрләр»дән җыелган, янәсе без «урам хатыннары» — безгә махсус укол ясыйлар да, без хатын-кыз булудан туктыйбыз, безгә үлем ни дә, яшәү ни һ. б. Димәк, без алар өчен куркыныч көч булганбыз. Төнге очышларыбыз фашистның котын алган. Ә Ватан өчен барган изге сугышта безнең кызларыбыз туктамый хезмәт итүче кыя карлыгачлары иде. Ял иткән арада алар әтиәниләре, туганнары, дуслары, сөйгән ярлары, туган яклары, җиңү, якты киләчәк турындагы матур хыяллары белән яшиләр. Бервакыт чигү белән мавыктым, аннан шахматка күчтем... Дошман өстендә очканда күңелләрдә бары бер максат — бәхетебезне күпсенеп, утлы кулын сузган фашистны акылга утырту.

— Александра Семеновна! Исән калган полкташларыгыз белән элемтәгез ничек? Очраклы очрашулар куандырганы юкмы?

— Һәр елны диярлек җыелабыз. Һәм һәр очрашуда балалар сыман сөенешәбез. Безнең дуслык гадәти генә түгел

шул ул. Иң саф, иң эчкерсез, иң тирән дуслык. Юеш, салкын землянкаларда бер-беребезне җылыткан, утлы өермәләрдән ышыклаган, авыр, куркыныч минутларда юаткан, көч биргән, бер кабым ризыкны бүлешкән дуслык! Хәзер бер-беребездән ерак яшәгәндә дә сүрелми ул. 1953 елда, әти-әнием үлү кайгысыннан айнып җитмәс борын, нык кына авырып киттем. Нинди юллар белән генә ярдәм итмәде полктагшларым.

Ава Есауленко очрашуларга килә алмый иде (гаиләсе белән Сахалинда яши). Сугыштан соң 24 ел үткәч, иптәше белән өйгә килеп керде. Кочаклашып алдык та, көтелмәгән бу очрашудан икебез дә өнсез калдык. Исәнләшә дә алмыйбыз — телләребез бәйләнде. Шатлык-куанычны аңлатып, сүзләрне сөйләшеп бетерерлек түгел иде....

Соня Бурзаева белән дә уйламаганда очраштык. Полкыбызның беренче штурманы иде ул. Сугыштан соң, Белоруссиядә яшәгәндә ире үлгән. Күктә сынатмаган штурманыбыз бу кайгыны бик авыр кичергән. Очрашуларга килүдән туктады. Краснодар урамында үзе белән очраклы күрешергә насыйп булды. Мин улым янына барган идем, ә ул, ире үлгәч, шунда күчеп яши икән. Озак сөйләштек. Мин үземчә аны юатырга тырыштым, очрашуларга килергә куштым. Шуннан соң ул бер генә очрашуны да калдырмый. Фронтташ дуслары белән аралашу аның рухын бөтенләй күтәреп җибәрде.

— Александра Семеновна! Сугыш хыялларыгызга нинди киртәләр куйды?

— Урта мәктәптән соң, 1940 елда Саратов дәүләт университетының геология факультетына укырга кердем. Шушы белгечлекне тизрәк үзләштереп, тау токымнары эзләргә ашкына идем. Әмма, беренче курсны тәмамлауга, сугыш башланды. Замандашларым белән минем дә, укуны калдырып торып, ил өчен сугышка китәсем килде. Һәм майор Марина Раскованың хатын-кызлар авиаполкы туплавын ишетүгә, район комсомол комитетына киттем...

Университетны сугыштан соң тәмамладым. Бераз эшләгәч, аспирантурада укып, геологик эзләнү-разведка партияләре буенча кандидатлык диссертациясе якладым. Тик сугышның тәэсире сәламәтлектә дә сиздерә башлады. Экспедицияләргә йөрү кыенлашты. Читтән торып педагогия институтын тәмамладым. Хәзер Ессентуки шәһәренең 12 нче мәктәбендә тарих укытам.

— Александра Семеновна! Бик күп төрле җәмәгать порученияләре үтәвегез белән яшь буынга хәрби-патриотик тәрбия бирүдә зур өлеш кертүегезне Ессентукида зурлап

бәялиләр. Димәк, сез һәр көнне балалар, яшьләр, халык арасында. Очрашып сөйләшүләрдән соң, үз чорыбыз белән чагыштырып, бүгенге кызлар турында уйланганыгыз бармы?

— Очрашуларга бит кызларның, нигездә, яхшыга омтылганнары, җәмгыять, өлкәннәр каршында үзен җаваплы сизгәннәре килә. Алар синең һәр сүзеңне йотылып тыңлый. Күзләренә карасаң, аларның һәркайсының, кирәк булса, ил өчен, халык өчен безнең полк кызлары батырлыгын кабатларга әзер булуын күрәсең. Шулай да мине күпчелек яшьләргә хас бер сыйфат борчый: аларның физик әзерлеге. Авырлыклар белән көрәшү өчен теләк кенә җитми бит әле. Хезмәт, физик чыныгу аша ныгыган ихтыяр көче булу мөһим. Ә бүгенге яшьләрнең (бигрәк тә кызларның) күбесе нәзберегрәк. Без аларны авыр күтәрүдән дә, озак эшләтеп арытудан да, йокысын бүлүдән дә саклап, суыктан, җилдән ышыклап үстерәбез. Ә безнең полк кызлары бит, кирәк икән, тәүлекләп йокламаска да, центнерларны күтәрергә дә, авырту-сызлауларны күз яшьсез генә кичерергә дә өйрәнеп үскәннәр иде. Аңа карап кына берсе дә буй-сын гүзәллегеннән, уй-хисләр нечкәлегеннән мәхрүм түгел иде. Аларның матурлыгын да, батырлыгын да, итагатьлелеген дә әйтеп-аңлатып бетерергә сүз җитми.

Әңгәмәне *Язилә Абдулкадыйрова*
алып барды

ЮЛЛАР ДӘШӘ ЕРАКЛАРГА

Иван Ефимович бу көнне куанычын кем белән уртаклашырга да белмәде. Карчыгы өйдә юк иде, күршеләре эштә. Бала-чага сине барыбер аңламас. Әһә, киленгә хәбәр итәргә. Балалар бакчасында өлкән медсестра булып эшли ул. Телефоны да бар.

— Валя, Валечка,— дип сүз башлады Иван Ефимович,— бераз дулкынланып,— ишетмәгәнсездер әле...

— Нәрсә булды? — дип курка калды килене.

— Әйе, булды, бар... Сашаны... өлкә партия конференциясендә иде бит. Ни инде, шул, съездга делегат итеп...

Карт машинист бүтән нәрсә әйтә алмады, тамагына ниндидер төер тыгылгандай булды. Килене эштән ашыгып

кайтып керде. Кич белән Сашаны зарыгып көттеләр. Ә ул, үч иткәндәй, соңлады.

Әйе, ул әле юлда, үзе дә өенә ашыга. Шатлыгын уртаклашасы киләдер. Әйдә, кайта торсын. Шушы арада безнең таныша торыр кешеләребез бар. Ул Иван Ефимович Шулаев — Юдино локомотив депосының карт машинисты. «Карт» дигәнгә бер дә үпкәләми ул. Җитмешкә якынлашып килгәндә сине яшь дип тормаслар бит инде. Яше белән дә, эше белән дә өлкән шул инде Иван Ефимович, ветеран.

1932 елда яланаяклы Ваня авылдан биргә килеп Юдино депосына паровоз мичләре чистартучы булып эшкә урнаша. Кем белә, көмеш дилбегә кебек сузылган юллардан төтен бөркеп борыла-сарыла чапкан поездларның күңелле сигнал тавышлары бәлки аның күңелен сабый чактан ук биләп алгандыр. Бәлки «нужа» бабай да куганбыр. Еллары шундый булган. Ничек булса да булган, топка чистартучы «кара малай» гомерен тимер юл белән чишелмәслек итеп бәйләгән. Тора-бара машинист ярдәмчесе була ул, өлкәннәр булышлыгы белән һөнәрен үстерә бара, үзлегеннән машина йөртә башлый. Ә сугыштан соңгы елларда инде, машинист-инструктор булып, башкаларны тепловоз йөртергә өйрәтә, остаз булып таныла. Танылуын шуннан беләм: күкрәгеп Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, һәртөрле медальләр бизи. «Мактаулы тимер юлчы» дигән исеме дә бар.

Машинист-инструктор кулы астында 90 кешелек колонна эшли. Һәркайсы өчен — машинистмы ул, машинист ярдәмчесеме — инструктор җавап бирә. Ул елларда Иван Ефимович Шулаев һәм аның кебек башка өлкән машинистлар әзерләп чыгарган кадрларның күбесе үзләре остаз дәрәҗәсенә ирештеләр. Алар арасында малае Александр да бар. Үз һөнәренә чын күңелдән гашыйк кеше өчен аның һөнәрен дәвам иттерүчедән дә якын һәм кадерлерәк кеше юктыр. Ә андый кеше үз малаең да булса, бигрәк тә. Бусы инде бүтәнчә бәяләнә — династиянең башлануы дигән сүз.

Һөнәргә мәхәббәтне кешедә мәҗбүри рәвештә тәрбияләп булмый. Монда күп факторлар бергә туплана. Сашаны беренче тапкыр машина кабинасына алып менеп, аннан сигнал бавын тарттыру, аңа машинист сандыгын (үзләренчә аны «шарманка» диләр) җыярга рөхсәт итү, беренче тапкыр утыртып ерак рейска алып чыгу... Болар бит барысы да сабый күңелендә тирән эз калдыра торган вакыйгалар. «Әти кебек булырга!» дигән теләкнең ничек һәм кайда туганын Александр Иванович хәзер әйтеп тә бирә

алмастыр бәлки. Әйтә дә алмасын, ди. Хикмәт андамыни. Ул менә этисен дә уздырды. Гади генә бер мисал. Иван Ефимович 29 яшендә үзлегеннән локомотив йөртә башлый. Ә Саша исә үзе хуҗа булып беренче тапкыр рейска 24 яшендә чыга. Сигез елдан аны III дәрәҗә Хезмәт Даны ордены белән бүләклиләр. Тагын биш елдан — партия съезды делегаты булып сайлану.

Коммунист Иван Ефимовичның чиктән ашкан куанычын аңларга була. Чөнки мондый ышаныч юк-бар кешегә күрсәтелми. Шатлыгыннан түбәң күккә тияр. Бу кичне Александрның ничек кайтып керүен, аны ничек каршы алуларын һәм моның гомуми гаилә куанычына, икенче көнне ул эшләгән депо коллективы куанычына әверелүен бөртекләп язып тормасак та аңлашыла төсле.

Александр Иванович Шулаевның хезмәт юлы унынчы классны тәмамлау белән үк башлана. Юдинодагы 1 нче тимер юл училищесын тәгәлләгәч, аңа ярдәмче машинист хокукы бирәләр. Сашаны ТЭ-3 тепловозына өлкән машинист Виктор Семенович Дубровин янына утырталар. Аз сүзле бу малай беренче көннән үк ошый өлкән машинистка. Ул вакытта әле машиналарның тормозлары йомшак була. Менә Зөя — Ходаш участогында түбәнәеп бара торган километрларны үтәләр. Бөтен тормозлар тартылган.

— Колодкалар төтенлиме? — дип сорый өлкән машинист.

— Төтенли,— ди Саша игътибар белән күзәтеп.

— Төтенләсә әйбәт, янмасын гына...

Бу сөйләшү Сашаның хәтерендә әлегәчә саклана. Хәзер инде тепловозларның көчлеләрен йөртәләр алар: ике секцияле, 8 мең ат көчле куәткә ия. Хәтта аннан да көчлерәкләрен — 10В серияле камилләшкәнрәк тепловозларны да йөгәнлиләр. Авыр составларны җилдәй җитез һәм хәвефсез йөртүгә ирешәләр.

Армиягә киткәнче дә, аннан кайткач та 1967 елга кадәр Саша машинист ярдәмчесе булып эшли, һөнәрен камилләштерә. Үзлегеннән локомотив йөртү хокукы алу өчен һәркем ярдәмче булып илле мең километр юл үтәргә тиеш дигән кагыйдә яши. Бу шартны үтәмәгән бер генә кеше дә машинист була алмый. Җир шарын экватордан урап чыкканнан да күбрәк. Һәм бу мәҗбүри шартны Саша уңышлы башкара. Гомумән, юл йөрү егетнең канына сеңгән. Армиядә хезмәт иткәндә дә ул машинадан аерылмый, шофер булып эшли. Икенче класслы шофер булу өчен имтихан тапшыра. Транспорт хәрәкәте кагыйдәләре буенча «бик яхшы» билгесе ала. Шулай да правосында бер тарихи

«тишек» бар. Берчак бозлы юлдан барганда уяулыгы житеп бетми, газигы белән алдагы машинага килеп бәрелә. Аның гаебе дә түгел, югыйсә...

Менә ул дулкынланып көткән көн килеп житә. 1970 ел, февраль башы. Бүген Александр Шулаев мөстәкыйль юлга — Юдино — Кизнер маршруты буенча рейска чыгачак. Аның янына бүген ярдәмче дә утырттылар.

Иртән машинист-инструктор Геннадий Леонидович Телягин аны «Ну, Сашок, сынатма», дип озатып калды. Ул гына да түгел, тәжрибәле машинистлардан А. Варламов, М. Диковларны да Саша үзенең өйрәтүчесе итеп саный. Әтисе инде бу вакытта лаеклы ялга чыккан була. Әмма улының беренче рейстан кайтуын ул да башкалардан ким көтмәгәндер. Һәрхәлдә, малаен беренче тапкыр ялантәпи килеш паровозга алып менүче, аңа сыбызгы җебен тартырга рөхсәт итүче ул бит әле.

Дистә еллар вакыт үткән. Шулай да мин аннан: шул беренче рейсны хәтерлисеңме? — дип сорап куям.

— Хәтерләмичә,— ди Александр Иванович,— кышның кояшлы иртәсе иде. Салкынча җил исеп тора. Кузгалдык. Турыдан-туры Дербышкига... Линейка белән сызган кебек тигез юл. Син бер урында торасың, ә корыч рельслар сиңа таба зур тизлек белән шуышалар төсле. Барган саен барасы, билгеләнгән станциягә тизрәк житәсе килә. Тимер юллар алар шулай бит, һаман саен еракларга дәшәләр. Шундый сихерли, бармый кала алмыйсың. Беренче рейсны онытырга мөмкин түгел. Ярдәмче булып йөргәндә бер хәл. Янында өлкән кеше, ышанычлы машинист утыра. Һәммәсенә ул җавап бирә. Шуңлыктан әллә ни борчылмыйсын. Ә монда... бар җаваплылык синдә. Беренчесендә тез буыннарым калтыраганын хәтерлим. Шулай да үземне тиз кулга алдым. Таныш юл. Таныш үрләр...

Бардык. Һәммәсе инструкциядә язылганча үтте. Кизнердан состав алып кайттык. Ул вакыттагы беренче ярдәмчем Володя үзе күптән машинист инде. Мине хәтерләми дә торгандыр, бәлки. Мин үзем дә шулай, ярдәмче булып йөргән чактагы күп нәрсәне искә төшерә алмыйм.

Тимер юл транспортында төп күрсәткеч — аның ритмлы эшләве. Ритмлы эшләгәндә тонна-километрлар үзләре артып торалар. Сменага 7500 тонна-километрга җитә ул. Һәр машинист елга 120 мең тоннадан артык төрле халык хуҗалыгы йөкләре ташый. Әле бу бер машинист исәбенә генә шулай. Деподагы дистәләгән машинистның һәркайсының үз хисабы, үз рекорды. Юллар гына төзек булсын

да, тепловозың гына тартсын. Юл кагыйдәләре, машинист алдына куелган таләпләр бертөрле. Мәсәлән, юлда барганда ниндидер төгәлсезлек, ватылу булып тукталып калдың, ди. Аның сәбәбен эзләп табуга ун минут вакыт каралган. Шушы арада кузгалып китә алмыйсың икән, башка составларга юлны бушат. Машинист Александр Шулаевның әле үзенең эше дәверендә юлда бер тапкыр да тоткарлык тудырганы юк.

Александр Ивановичның тимер юл транспортчылары арасындагы социалистик ярышларда җиңеп чыгуы бер генә тапкыр түгел инде.

Ләкин тимер юлдагы гомуми кимчелекләргә аның бик тә эче поша. Тимер юллар эшен яхшырту, камилләштерү буенча ил күләмендә нәтиҗәле чаралар күрү таләп ителгәнен яхшы аңлый ул. Чөнки бу тармактагы таркаулык соңгы вакытта үзен бик сиздерә башлады. Әле анда, әле монда һәлакәтле аварияләр килеп чыгып тора. Бу инде Шулаев кебек аерым кешеләр тырышлыгы белән генә җиңеп була торган җитешсезлек түгел, ил күләмендәге чаралар күрелүне таләп итә торганы.

...Ул көнне Витя иртә уянды һәм күзен угалап ачуга әтисенең машинист сандыгын эзләде. Җитмәгән, сүзендә торган, дип сөенде ул. Тиз генә торып юынды, киенде, чәй эчеп алды. «Шарманка»га кирәкле инструментларны, көнозынга җитәрлек азык салдылар. Александр Ивановичның улын беренче тапкыр үзе белән рейска алуы иде. Рейстан кайткач, улының арыган йөзенә карап, әнисе елмаеп куйды.

— Нәрсә син, Витя,— диде Валентина Васильевна аптыраган булып — әтиең елмаеп кайтып керде, ә синең борының салынган...

— Салынмас анда,— дип мышкылдады Витя,— ашарга күбрәк куярга иде. Җитмәде...

— Шулаймыни. Ачыккан икән минем улым...

Хәзер инде Витя үзе юллар чатында. Аңа врач булырсың, диләр. Ә ул «мин бары тик машинист кына булачакмын» дип тәкрарлый.

Бәлки, династия шулай дәвам итәр. Малае әтисе юлын сайлый икән, бу инде бик яхшы. Олы хезмәт юлы ул, бабасыннан башланган юл.

Мирхәт Хөснимәрдәнов

ТӘВӘККӘЛ ТАШ ЯРА

Төзелеш материаллары ташучы Борисенко бригадасы шоферларының хезмәт казанышларын бөтен ил белә. Бу коллектив, автопоездлар йөртүгә күчеп, үз тармагында бөтен союзда иң югары нәтиҗәләргә иреште. Алар тәҗрибәсе турында министрлыкта да зур һәм эшлекле сөйләшү булып узды. Унбер шофердан торган бригада ел саен егерме машинага планлаштырылган кадәр йөк ташый. «Казанстройтранс» берләшмәсенең экспериментал автохуҗалыгында бер тонна-километр йөк ташуның үзкыйммәте алтмыш бер тиен булса, Борисенко җитәкләгән коллективга ул ике тапкыр кимрәк. Бу бригада 1987 елда ук йөк ташуның 1990 елга билгеләнгән дәрәҗәсенә чыга. Бирeдә хезмәт җитештерүчәнлеге дә 2,5 мәртәбә югарырак. Мондый югары нәтиҗәләргә ирешүнең төп чыганагы — Борисенко бригадасы егетләре автопоездларның йөк күтәрешен арттырдылар, туктап торуларны киметтеләр, машиналарны техник карау һәм ремонтлау сыйфатын күтәрделәр, үзләре йөри торган 28 километрлы магистральне үз көчләре белән ремонтладылар.

Ә кем соң ул Евгений Борисенко үзе? Ул — 50 яшьләрдән югары, баһадир гәүдәле, мөлаем гына кеше. Әңгәмәне җаваплылык, үз һөнәреңөчен горурлык хисләре тоеп эшләргә борып җибәрсәң, аның бөтен эчке дөньясы ачыла. Һәр сүзендә — бүгенге яңарыш рухы. Омтылышларына һәм характерына төптән төшенгәнче үк бер нәрсәне ап-ачык тоясың: ул — планнарны тормышка ашыру өчен кыю көрәшүче, экономиканы һәм кешеләрнең иҗади активлыгын күтәрүдә кайда, нәрсә һәм ничек эшләргә кирәклеген бик әйбәт белүче.

Әмма Борисенко юл төзү буенча күтәргән тәкъдимнәр һәркайда да җиңел генә кабул ителмиләр. Иске традицияләрнең тамырлары тирән, аларны йолкып ташлау авыр. Аны тыңлаучылар «Идеясе сабын куыгы кебек шартлаячак», «Автопоезд йөртә башлагач та буй итмәс таләпләр куйган иде инде»,— дип фикер йөрттеләр. Юк, Евгений Леонидович андый сүзләр ишетү белән генә үз фикереннән ваз кичәргә теләми. Ул, үзенең хаклыгына ышанып, КПССның шәһәр комитеты юлын таптый, үз фикерен профсоюзларның өлкәара конференциясе трибунасыннан сөйли һәм аның идеясе җиңә.

Яңа башлангыч район һәм шәһәр күләмендә хуплау тапканчы, Евгений Леонидович машинасына утырып, брига-

дасы шоферлары йөри торган юлны әйләнеп кайта.

Барганда да, кайтканда да юлдагы чокырларга җаны әрни аның.

— Спидометрга күз салыгыз. Тизлек ватык юлда сәгатенә 5 километрга кадәр төште. Ә без 35—40 километрдан киметмәскә тиеш. Чокырлар күпме вакытны ашый?! Машиналар ватыла, ягулык әрәм була. Минем арттан әле күпме машина килә. Саный китсәң, дәүләткә кыйммәткә төшә бит бу,— ди Борисенко.

Баксаң, шул чокырларны тутырып тигезләп китү өчен күп нәрсә кирәкми икән. Ватык кирпечләр, бетон калдыклары, төзелешләрдә тулып ята. Сүтелә торган иске йортлардан хәтсез кирпеч чыга. Аларны кайда чокыр — шунда илтеп аударалар. Яхшы хуҗа эшемени бу? Укучылар урамнардагы, ишегалларындагы тимер-томырны җыялар ич! Мартеннардан арзан һәм шәп металл чыга. Төзелеш калдыкларына да караш шулай булса иде.

Казанда юлларны әлегә Борисенко бригадасы шоферлары гына ремонтлый. Вак таш базасы һәм 4 нче тимербетон әйберләр заводы арасындагы трассаны алар үрнәк төскә кертәләр. Ремонт өчен кирәкле материалларны «Каздорстрой» тресты бирә. Һәр шоферның кулында — талон, машинасында — яңа түшәлгән асфальтны тигезләү өчен каток. Атнаның бер көнен Борисенко җитәкләгән коллектив шушы мөһим эшкә багышлый. Ай ярым эчендә бригада шоферлары үзләре йөри торган юллардагы чокырларга 80 тоннадан күбрәк вак таш салалар һәм асфальт түшиләр. Ремонтланган юллардан Евгений Леонидович белән тагын бер кат йөреп кайттык. Игелекле эше өчен куанып бетә алмый бригадир. Юл ремонтлауда бушлай эшлиләр. Үрнәк алырлык әйбәт башлангыч, аны шәһәрнең генә түгел, бәлки республиканың барлык автохуҗалыкларында да тизрәк җәелдерәсе иде.

Евгений Борисенконың тормыш юлы да әлеге магистральләр төсле сикәлтәле. Евгений — әти-әнисенә бердәнбер бала. Әтисе сугышның беренче көненнән үк фронтка китә. Фашистлар Харьков өлкәсенә килеп җиткәч, Нина Сидоровна, биш яшь тә тулмаган улын ияртеп, Урта Азиягә китә. Женя җиденчене тәмамлагач, тимер юл училищесына укырга керә. Бер үк вакытта кичке мәктәптә укый. Училищедан тепловоз ремонтлаучы слесарь һөнәрен алып чыга, тимер юл станциясендә эшли. Кичке мәктәпне тәмамлап өлгергәнлек аттестаты алган елны Совет Армиясе сафларына чакырыла. Хәрби хезмәттә дә укуын дәвам

итә. Армиядән беренче класслы шофер һәм тракторчы булып кайта һәм Казанга килә. Мәктәп укытучылары Женядан яхшы конструктор чыгачагын әйткән булалар. Математиканы һәм сызымны бик әйбәт белә ул. Хыялы — авиация институтына керү. Әмма ул елларда аны тормышка ашыру бик күпләр өчен авыр була. Армиядә алган һөнәре буенча шофер булып эшли башлый. Булачак хатыны Лариса белән таныша, өйләнешәләр, кызлары туа һәм Борисенколар гаиләсе Казанда төпләнеп кала.

Моннан уналты ел элек «Казанстройтранс»та экспериментал автохуҗалыгы оештырыла. Танылган шофер, тракторчы һәм слесарь һөнәренә ия булган Борисенконы бригадирлыкка тәкъдим итәләр. Бу чакта яңа бригадирның автохуҗалык җитәкчеләренә һәм белгечләренә күпме мәшәкатьләр тудырачагын берәү дә башына китерми. КрАЗлар кайта, көчле машиналар. Күрше автохуҗалыкта андыйлар бар. Танышы Расковалкин — шунда шофер. Кичен өйгә кайтышлый очрашалар.

— КрАЗларны тулы куәтенә эшләтмибез,— ди Борисенко.

— Ни өчен?

— Унике тонна гына түгел, ике тапкыр күбрәк йөк төяп була аларга. Прицеп кына кирәк.

— Бездә бар, мин тагам...

Бер атнадан Борисенко урамда Расковалкин машинасын прицеп белән күрә һәм туктата.

— Тарта аламы?

— Әлбәттә, егерме дүрт тоннага «әһ» тә итми.

Борисенко уйга кала. Гаражда андый прицеп юк. Евгений Леонидович бернинди рөхсәтсез-нисез прицеп ясый башлый. Мондый эшкә фатиханы баш инженердан алырга кирәк, ә ул кицәшеп тормый һәм шактый кыен хәлдә кала. Баш инженер Гайфуллинның прицеп таккан машинаны күреп коты оча. Борисенко ашыгыч рәвештә рейстан гаражга чакыртыла. Мораль уку башлана.

— Кем кушты? Бер атнадан машинаның моторы тетелеп бетә, алып ташла прицепны.

Борисенко сабыр. Бер атна йөрде ич. Тешен кысып булса да түзә. Начальство әрләүдән туктагач:

— Алайса, мин дә бер-ике сүз әйтим,— ди.— Машинага зыян килмәс. Ике шофер кадәр эшлим. Ватылса, җәзасын бирерсез.

Йөр, дип тә, тукта, дип тә әйтүче булмый. Бригадир рәсми рөхсәттән башка рейсларга чыгуын дәвам итә. Ватылып бер генә сәгать тукталып торган очракта да эшнең

ничек бетәсен белә, бөтен зыянны үзеннән түләтәчәкләр. Борисенко җитди бер карарга килә: атналык цикл кертергә кирәк. Моның асылы шул: атна буена эшли һәм бер көн үзе техник карау үткәрә. Бер, ике, өч... биш... ун ай узып китә. Евгений Леонидович КрАЗы сәгать механизмы кебек төгәл эшли. Прицеп тагып ул хезмәт җитештерүчәнлеген ике мәртәбә күтәрә. Отыш күз алдында. «Казанстройтранс» җитәкчеләре Борисенко бригадасының тәҗрибәле шоферларына прицеп тагып эшләргә рөхсәт бирүләре турында приказ чыгарырга мәҗбүр булалар. Бригадада беренче ун автопоезд әнә шундый каршылыклар аша туа. Аларга Әнвәр Хәммәдиев, Равил Садриев, Илья Семенов, Виктор Соковой утыра.

Евгений Леонидович ирешелгәннәр белән тынычланмый. КрАЗның көче егерме дүрт тоннадан артык төйи ала. Ничек исбатларга? Яңа машинасын яшь егеткә бирә, үзе иң иске КрАЗны ала. Башта яхшылап ремонтлый һәм 32 тонна төяп йөри башлый. Иске машина белән туктаусыз бер ел да ун ай йөри һәм рекорд куя. Бу — коллективның хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә дә йогынты ясый, шоферларның эш хакы арта.

Евгений Леонидович хәтер йомгагыннан үткән ел азагындагы тагын бер вакыйганы сүтә. Ул КрАЗ белән 40 тонна йөк ташырга мөмкин икәнлеген исбатларга тели. Якын дуслары каршы төшә: «ГАИ белән конфликтка кермә. Сиңа ни җитми? Орденнарың бар инде. Квартираң әйбәт. Машинаң бар. Йорт җиһазларың да җитәрлек». Әмма Борисенко позициясеннән чигенми. Казанда һәм илебезнең төзелеш транспорты системасында кырык тонналы беренче автопоездны рейска алып китә. КрАЗ таккан бу состав, шәһәр урамындагы транспорт хәрәкәтенә комачауламыйча, юлларга зыян китермичә, ватылмыйча чаба.

Берчак мин Евгений Леонидовичны «Казанстройтранс» берләшмәсе начальнигы Хәбибрахманов бүлмәсендә очраттым. Зур автотранспорт предприятиесе җитәкчесе һәм шоферлар бригадиры озын өстәлнең башында кара-каршы утыралар. Алларында — кәгазь, кулларында — ручка. Нидер язалар, схемалар сызалар, бәхәсләшәләр. Сүзләрен озак бүлдерми тордым. Үзара аңлашуларын күргәч, кул биреп күрештек. Борисенко гадәттәгечә елмаеп куйды да иркенләп сөйләп китте:

— Күрәсез, яңарыш һәм демократияне тагын да үстерү чорында эшләве ничек җиңеләйде. Элек шоферлар начальство янына үзләре чакырса гына керә иде. Хәзер бүлмә ишеге һәрчак, һәммәбезгә ачык. Фикерен, тәкъдимнәрен

бар икән, кереп уртаклаш. Игътибар белән тыңлыйлар, безнең фикер белән килешәләр. Кемгә-кемгә инде, ә менә көндәлек мәшәкатьләр эчендә кайнаучы шоферларга уңышларыбыз да, кимчелекләребез дә ачыграк күренә.

Борисенконың бу сүзләрендә мин тулы канәгатьләнү хисләре тойдым. Яңа ел алдыннан берләшмә шоферлары сайлау алды җыелышына җыелалар. Көн тәртибе һәркайсына мәгълүм: җирле Советлар халык депутатлыгына кандидатлар күрсәтү. Өч мең кеше эшли торган коллективта лаеклы кешеләр күп. Беренче итеп Евгений Борисенко һәм Эмир Эдиятуллин исемнәрен атыйлар. Икесе дә коллектив ихтирамын һәм хөрмәтен казанган, инициативалы һәм эшлекле, әйбәт гаилә башлыклары, җәмәгать эшләрендә дә актив катнашалар. Көтмәгәндә Борисенко үз кандидатурасын кире ала. Моны ул профком члены һәм бригадир буларак эшенең болай да күплеге белән аңлата. Әмма җыелыш аңа каршы төшә. Ачык тавыш бирү юлы белән үткәрелгән сайлауда Борисенко кандидатурасы яклана.

Нигә транспортчылар өчен торак, социаль-культура объектлары аз төзелә? Министрлыкның бригада подрядын үстерү белән начар шөгыльләнүенең сәбәбе нәрсәдә? Нигә көнкүреш өчен кирәкле вагоннар чыгарылмый? Шоферларның киемнәре шыксыз — болар барысы да Борисенконың үзе хәл итәргә тиеш дип саналган мәсьәләләр.

Евгений Леонидович гомере буе ил гаме белән яши. Үзгәртеп коруның бөтен фронтында Борисенколар никадәр күбрәк булса, алар яңарыш юлындагы киртәләрне тизрәк җимерерләр иде.

Мәгъсүм Гәрәев

ҖИДЕ КАТ ҖИР АСТЫНДА

Чү, нәрсә булды?

Гөлүс башына каскасын киярге дә онытып, вагоннан атылып чыкты. Бик көйле эшлиләр иде ич әле, нәрсә генә булды соң? Тешкә тиярлек яман итеп нәрсә шыгырдады? Их, нигә дип кенә ял итәргә уйлады икән. Әллә

бораулаучы онытылып киттеме? Рәфыйкка күпме әйттем: син оста, тәҗрибәле кеше, әмма яңа скважинада безнең генә тәҗрибә җитми, дип. Алай дисәң, инструктор-бораулаучы Михеев та шунда.

Җиһазлары да чит илнеке бит аның, шайтан алгыры. Нәзберек җан, көенә китереп эшләтмәсәң, хәзер чыгымлый башлый. Автоматика, электроника — эченә керсәң, башың бетәрлек. Ә без элекке буровойда кувалдага күнеккән. Бәргәләп, дөмбәсләп алуың була, ипкә килә, җайлана.

Их, бөтен эшне бозып ташламаган булсак кына ярарые!

Гөлүс шабыр тиргә батып уянды. Өнемме бу, төшемме? Төш дисәң, тып-тын; ни скважина каланчасы юк, ни җил сызгырмый. Уф, тәүлек буе чабу, ял белмәү менә нишләткән. Кичә бер километрдан артыграк бораулагач, скважина изменә убыр урынына йота башлаган иде. Девон картның чираттагы «күчтәнәче» дип көттеләр, берәр сәгатьтән скважинаның «тамагы» туймасынмы? Шуннан соң гына җиңел суладылар.

Бу скважина кайсы төбәктә дисезме? Нәкъ Әлмәт артында бардыр бер авыл — Кичү диләр. Шул авылдан ерак түгел, Сөембикә манарасыдай биек скважина башын күккә чөйгән. Мәгъруր утыра, гүли, чыңлый, тырылдый. Тәүлек буе шулай. Бораулаучыларны гадәттә чегән тормышы белән яшәүчеләр дип йөртәләр. Бер ай да тулмый, алар арба күчәрен майларга, башка урынга күчену хәстәрен күрергә тотыналар. Ә Кичү авылы янындагы скважина бөтенләй үзгә, ул утрак тормыш өлгесе. Җиде километр тирәнлеккә казу ул сиңа 70 көн дә, 7 ай да түгел, ә 7 ел да 3 ай буе тир түгәргә туры киләчәк. Шуңа күрә имән төбедәй нык утыра Кичү скважинасы.

Бүген «Татнефть» берләшмәсендәгеләрнең күзе аларда. Шулай булмый хәл юк, республиканың нефть промышленносте үсешендә иң катлаулы чор җитте. Төп ятмалардагы җир маеның суырыласы суыртылып бетүгә бара, сважиналарның гайрәте кимегәннән-кими. Мастер Г. Мөгыйнов әйтүенчә, җир мае штуцердан фонтан кебек бәреп тормый хәзер. Нефть кимүенең сәбәбе — өстәге ятмаларны үзләштерү белән мавыгу. Ә менә җиде йозакка бикләнгән хәзинәне — өскә чыгарга бик атлыгып тормаган «кара алтын»ны җир куеныннан алып күрсәт син! Зур көч куеп, күп чыгымнар тотып табылырга тиешле ятмалар запасы 60 процентка, ә инде өлешчә су кушылганнары белән 70 процентка җыела.

Татарстанда геология эзләнүләре башлануга 50 ел

тулган көннәрдә нефтьчеләр каласыннан ерак түгел Кичү авылы янында 46 метрлы буровой калкып чыгуның үзенә бер тарихы бар.

— Без бу скважинага аеруча зур өмет баглыйбыз,— ди «Татнефть» берләшмәсенең баш геологы Ринат Хәлиуллович Мөслимов.— Җиде километр тирәнлектә нефть табачагыбызга мин бөтен күңелем белән ышанам.

5099 метрга бораулангаи скважина безгә бай мәгълүмат бирде, эзләнүне дәвам итәргә, тирәнгәрәк төшәргә кирәклеген күрсәтте. Нефтьнең килеп чыгышын ике төрле нигезләүче теория тарафдарлары арасында кызу, кискен бәхәс бара. Мин органик булмаган теория, ягъни Д. Менделеев теориясен яклыйм. Иманым камил, җиде кат җир астында нефть табарбыз, бу бәхәс безнең файдага хәл ителер,— ди Кичү авылы янында гаять тирәнгә бораулау өчен буровой кору буенча ун ел буе көрәшкән һәм үз дигәненә ирешкән белгеч.

*

* *

Алар — разведкачылар, билгесезлеккә юл яручылар. Разведчик дошман тылына үтеп кергәндә нинди кискен, кыен, четерекле хәлләрдә каласын белми. Задание генә үтәлсен. Дошманның серен алырга, кыйммәтле мәгълүматлар яки «тел» алып кайтырга — аның бар исәбе шул. Бораулаучы-разведкачылар да җиде километр тирәнлектә нинди сер яшерелгәнен белмиләр. Аларның бурычы катлы-катлы сорауларга җавап эзләүдән гыйбарәт. Нефть нәрсәдән килеп чыккан; черегән яфрак, җәнлекләр таркалуданмы, әллә химик тәэсирләр астындамы? Кристалл фундаментта нефть бармы? Җир кабыгы ярылган урында (Кичү скважинасы нәкъ шул төштә утыра, диләр) нинди хәзинәләр яшерелгән? Гомумән, җир төзелеше нидән гыйбарәт? Тагын әллә никадәр чишелмәгән, сер пәрдәсенә яшеренгән сораулар.

Юл яручыларга һәрвакыт кыен.

— Мондый скважинаны беренче тапкыр борабыз (нефтьчеләр бораулыйбыз дип түгел, ә борабыз дип сөйлиләр). Элек без девонга бора идек. Иң зур тирәнлек — 1800—1900 метр. Ә моныеы җиде километр тирәнлеккә төшү, моңарчы без күрмәгән тирәнлек. Егермеләп институт галимнәренең күзе бездә булачак. 25 метр төшкән саен тикшереп, анализ ала барачаклар.

Әлеге скважинада эшләүче коллективның «төшен» аның бригадасы тәшкил итә. Мөгыйновныкылар — каты токымнан. Коммунист Г. Мөгыйнов Әлмәт бораулау эшләре идарәсендәге иң арттагы бригаданы беренчеләр сафына чыгарды. Ул җитәкләгән комсомол-яшьләр коллективы республика ярышында гел җиңүчеләр рәтендә булды. Тагын шунысы бар — Ягъфәр Сабитов, Мисхәт Халиков, Николай Гурьев, Гыйракта эшләп, бай тәҗрибә туплаган бораулаучылар.

— Кичү скважинасында эшләячәк бригадаларны җитәкләү өчен мастерлар Герасимов белән Мөгыйнов сайлап алынды. Һәм менә ни өчен — Әлмәт бораулау эшләре идарәсенең партком секретаре В. Матвейкин сүзне шулай башлады.— Аларны ике тип җитәкче дип әйтергә була. Мастерлар яшьләре ягыннан да төрле кешеләр. Дмитрий Иванович тәҗрибәлерәк, егерме ел бораулау мастеры. Нинди генә скважиналарда эшләмәде икән ул? 5099 метрлы скважинада эшләп бай тәҗрибә туплады. Бу яктан Гөлүскә күп ярдәме булачак аның. Герасимов — тумыштан педагог. Яхшы тәрбияче, бик сабыр, салмак кеше. Аның элекке бригадасында иң ныклы тәртип иде, ул яшьләр өчен кайгыртучан җитәкче.

Гөлүс Мөгыйнов шулай ук бай тәҗрибә туплаган кеше. Техникум тәмамлады. Таза, нык, сыналган ир-егет. Җаваплылык хисе бик көчле анда. Үз максатына ирешү өчен үҗәтлеге дә җитәрлек. Эшкә дәрте ташып тора, инициативалы җитәкче. Кешеләр белән, аеруча яшьләр белән уртак телне тиз таба. Партком члены буларак та җаваплы поручениеләр аңа йөкләнә.

Республикада бораулана торган йөзләрчә скважиналардан аермалы буларак, әлеге скважинада бораулаучыларның хезмәткә мөнәсәбәте ничек үзгәрә соң?

— Элек без күп вакыт кешене мактый идек,— дип сөйли мастер Г. Мөгыйнов.— 1800 метрны 24 көндә үтә идек. Алты көнне оту безнең телдә «тизләнеш» дип атала. Ә яңа скважина күбрәк фән өчен кирәк. Монда тизләнеш соралмый, сыйфат мөһим, фән өчен тулы мәгълүмат бирү мөһим. Шуңа күрә катламнарны бозмыйча эшләргә омтылабыз.

— Бу скважинада эшләү сезнең өчен отышлымы?

— Түләү ягын алсак, бораулаучылар, аларның ярдәмчеләре элекке скважиналарда эшләгәнгә караганда 120—150 сум кимрәк ала.

— Нигә шулай килеп чыга соң?

— Идарәдә: «Сезгә түләргә акчабыз җитми» дип аңлаталар.

— Бригадагыз таркалыр дип курыкмыйсызмы? Әлмәт өчен генә түгел, республика өчен дә әһәмиятле, җаваплы скважина ич. Тәҗрибәле, тәртипле, оста бораулаучылар урынына нинди яшьләр килә бит әле...

— Шулай килеп чыкмагае дигән шик бар күңелдә.

Г. Мөгыйновның шиге, бәлкем, урынлыдыр да. Ничек кенә булмасын, фән өчен гаять әһәмиятле булган бу скважинаның киләчәген яманга юрарга ашыкмыйк әле. Күңелдә яңалыкның киләчәге өчен туган борчылу, шик-шөбһәләр бораулаучы Рәфыйк Шәйдуллин, буровой начальнигы Ленин ордены кавалеры Михаил Родионов белән сөйләшкәч юкка чыкты.

— Дөресен әйтим, мине акчасы кызыктырмый. Эше авыр, салкында, җилдә эшлисең, анысын әйтмим. Акчасы мул төшә дип, мине Себер якларына да күп кыстаганнар иде. Бармадым. Акчада гына түгел бит хикмәт. Коллектив, иптәшләрең яхшы булсын,— ди Р. Шәйдуллин.

— Үзебез корган скважинада 6 мартта эш башладык. Әлегә күз тимәсен, 1147 метрны хәвефсез үттек,— ди нефть ветераны М. Родионов.— Дөрес, эш графигы белән килешмичә буровойдан китүчеләр булды. Әмма бораулаучылар яңа скважинаның әһәмиятен, өстенлеген аңладылар.

Җиде елга утрак тормышка күчеп эшләүнең файдалы яклары да шактый. Әлмәт юл өсте генә — ярты сәгать барырга, ярты сәгать кайтырга. Йөз чакрымга пычрак, сазлык ерып керү түгел инде. Әгәр 7—8 елга түземлекләре җитсәме? Бораулаучылар экономиканы һәм технологияне белү ягыннан бәһа биргесез, алыштыргысыз белгечләр булып җитешәчәкләр.

«Румыниядән сатып алынган җиһазларда эшләргә тизрәк өйрәнсеннәр иде». Мастер А. Трофимовның шуны кайгыртып йөргән көне. Скважинада аның җитәкчелегендә өч инструктор-бораулаучы эшли. Өчесе дә Көнбатыш Себердә, Оренбургта чит ил җиһазларында эшләп азу ярган кешеләр. Мастерлар Д. Герасимов белән Г. Мөгыйнов бригадалары алдынгы һәм куркынычсыз эш алымнарын биш бармакларыдай беләләр икән, димәк ки, инструктор аларны укытуга, өйрәтүгә җитәрлек көч куйган.

Скважинада ашханә бар, көнгә өч тапкыр кайнар аш әзерләнә. Тиздән душ, мунча әмәлләп куярга ниятлиләр.

* * *

Махсус кран ярдәмендә машинадан калын, авыр торбаларны бушатып бетергәч, мастер белән вагонга юнәлдек. Имәндәй таза, нык гәүдәле, чибәр йөзле, кара чәчле бу кеше беренче караштан ук әйбәт тәэсир калдыра. Уен-көлке кушып сөйләргә ярата, ачык табигатьле. Урта мәктәп, аннары нефть техникумын тәмамлаган. Совет Армиясендә хезмәт иткән. Бораулаучы ярдәмчесе, бораулаучы-мастер баскычларын үткән. Өйләнгән, гаилә корган. Бер карасаң гап-гади биография. Әмма Гөлүс, нефтьче буларак бүгенге халәтенә житү өчен, бик күпләр үтә алмый буровойдан китәргә мәжбүр булган икеләнү дулкыннарын җиңгән кеше.

Г. Мөгыйнов Социалистик Хезмәт Герое М. Гринь үрнәгендә артта калган бригадага күчә, аны алдынгылар сафына чыгара. «Хезмәттәге батырлык өчен», «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» медальләре белән бүләкләнә. Авариясез эшләүне тәэмин итүдәге активлыгы өчен «Нефть промышленносте отличнигы» билгесенә лаек була.

39 яшьлек мастер юлын аның бригадасында чыныгу алган ир-егетләр кабатлый. Коммунист Г. Мөгыйнов турында язу мастерлар Эрнест Гайнуллин, Тәлгать Садыйковны да мактап телгә алу ул. Алар Гөлүс үрнәгендә артта калган бригадаларга күчеп, башкаларны алга, җиңүгә канатландырдылар. Әнә шул яктан да мастер Г. Мөгыйновны кем башкаларга үрнәк замандашыбыз дип әйтмәс икән?

Кинәт әйтелгән, көтелмәгән сораулар кеше турында яхшырак белергә булыша. Гөлүс Кәримовичның холык-фигылен, тормышка, үз эшенә, кешеләргә, туган ягына мөнәсәбәтен белү өчен уенын-чынын кушып аңа берничә сорау бирдем.

— Сез усал кешеме?

Бу сорауны көтмәгәнгә, ул бермәл каушап калды.

— Төрле вакыт була инде. Урыны белән усал булырга да кирәк. Кайвакыт кызып китәм, усал-усал сүзләр әйтәм. Минем характерны егетләр белә, урынлы була, күрәсең, ачу тотмыйлар.

— Әгәр сезгә тормышыгызны яңадан башларга туры килсә, нинди һөнәр, нинди юл сайлар идегез?

— Нинди һөнәр... Билгеле инде, бораулаучы булыр идем. Безнең балачак Әлмәттә нефть чыгара башлаган чорга туры килде. Нефть эше яңалык, скважиналар бө-

тенләй без күргән нәрсә түгел иде. Малайларны кызыктыру өчен шунысы да бик җиткән.

— Ә хаталар?

— Тормыш булгач, хатасыз гына яшәп булмыйдыр инде ул. Үкенерлек ялгышларны хәтерләмим.

— Әгәр сезне иртәгә «Татнефть»нең генераль директоры итеп сайласалар, беренче эш итеп нишләр идегез?

— Һәркем сәләтенә карап тормышта үз урынын табарга тиеш. Мин аны таптым, дип саныйм.

— Бервакыт телевизордан Азнакай нефтьчеләрен күрсәттеләр. Тапшыруда М. Гринь башлангычы, аны яшьләрнең яклау-якламавы турында сүз барды. Кайбер яшь мастерлар: «Гриньга яхшы шартлар тудыралар. Техника, җиһаз, материаллар белән беренче чиратта аның бригадасын тәэмин итәләр, шуңа эшләре көйле бара»,— дип дәгъва белдерде. Башлангыч инициаторлары аерым шартларга куелырга тиешме?

— Гриньга куелган шартлар турында белмим, ә менә Әлмәттә эшләүче Социалистик Хезмәт Герое, мастер Дамир абый Нуретдиновның эше безнең күз алдында. Бригадасын да яхшы беләм. Бик тырыш, бик эшчән, булдыклы кеше ул үзе. Нинди генә алдынгы ысуллар кулланмасын, нинди генә яңалыклар кертмәсен — көн саен тир түкмәсәләр, тырышмасалар, башлангычлары башлангыч кына булып калачак. Нуретдинов бригадасына эшчән, тәртипле, тәҗрибәле, оста бораулаучылар гына тупланды. Ул аларны идарәдән сайлап җыймады, ә арттагы бригадага күчеп, үз үрнәгендә тәрбияләде, алдынгылар рәтенә чыгарды. Ә тырышлар һәрвакыт җиңеп чыга!

— Сез кулыгызда тылсымлы таяк бар дип хис итегез. Өч теләк теләгез — алар үтәләчәк.

— Теләкләр... Ярый, хыялланыйк. Бу скважинаны яхшы гына бораулап, җиде километрда нефть катламы тапсак иде. Әлмәт данын югары күтәрсәк иде.

— Икенче теләк...

— Үземнең гомеремне озынайтыр идем.

— Өченчесе...

— Җирдә тынычлык булсын. Сугыш кына башлана күрмәсен, калганы җайланыр.

Гөлүснең үзенә озын гомер теләвен мин болай аңлыйм. Ул Әлмәтнең ерак киләчәген, үзләре тапкан нефтьнең шәһәр, республика халкы өчен ничек хезмәт итәчәген күреп белергә омтыла. Әйдәгез, бергәләп нефтьчеләр каласының киләчәгенә күз салыйк әле. Эшне Гөлүснең үзен-

нән башлыйк. Аның тормышында нинди үзгәрешләр булырга мөмкин?

Беренчедән: нефтьче хезмәте тамырдан үзгәрәчәк, бораулау эшләрен автоматика гына башкарачак. Нефтьчеләр идарә пункты янында фасонлы, чиста киемнәрдән генә утырачаклар. Операторлар бүгенге кебек иген кырына аккан нефтьне күрәк белән күмеп йөрмәячәк. Күзге, язгы пычракларга нефтьчеләрнең исләре китмәс. Чөнки скважина яннары асфальтланган булыр...

Әлмәт шәһәре дә танымаслык булып үзгәрер инде ул чакта. Хәзерге «сакаллы төзелешләрне» күрмәссең. Менә дигән кинотеатрлар, больница, мәктәпләр, китапханәләр, спорт заллары, профилакторийлар үсеп чыгар... Ничек итеп киләчәкнең әнә шул якты көннәрен күрәсең килмәсен инде. Шулар хакына бүген бөтен көчен, белемен биреп эшли бит инде Гөлүс кебекләр.

Газинур Вәлиев

ГАЛӘМГӘ ЮЛ



Зиннур абый белән Фәхрия апа гаилә альбомын кәрый-карый күңел хатирәләрен барлап утыралар, тормыш сәхифәләрен күздән кичерәләр. Бер утыру — бер гомер. Менә Сәгъдиевларның дүрт улы бала чагында бергәләп төшкән фоторәсем. Уңда — Роальд, сул якта — Роберт, уртада — Ринат, артта төпчек малай — Рөстәм. Улларының иң олысы Роальд 1932 елның 26 декабрендә туган.

Җир шары сәяхәтчеләрдән башка яши алмый. Колумб, Магеллан, Америго де Веспуччи, котыпны ачучы Роальд Амундсен... Җир йөзендә ачылмаган атаулар, серле утраулар, кеше аягы басмаган урыннар калмады кебек. Әмма планетабызда сәяхәтчеләр яулыйсы үрләр әле җитәрлек. Фрегат, каравелла, шхуналарны «Вега»лар, «Фобос»лар алыштыра. Зиннур абый белән Фәхрия апа 1932 елның салкын декабрендә дөньяга килгән улларына котыпны ачкан Амундсен хөрмәтенә Роальд исемен биреп ялгышмаганнар. Роальд Сәгъдиевның фәнни җитәкчелегендә иҗат ителгән «Вега» космик станцияләре Галлей комитасы үзәге карлы-бозлы төштән гыйбарәт булуын ачыклады. Котыпны ачуга тиң ачыш түгелмени бу!

— Карале, Зиннур, безнең Роальдның балачагы ничегрәк узды соң? Килгән кешеләр дә, танышлары да аптыратып бетерәләр. Без аларның ничек үскәнен күрми дә калдык шикелле. Мәсьәлә чишәргә, баш ватарга кирәк булса, бездән сорамадылар. Гел үзбаш булдылар.

Төрле кеше бар шул. «Роальд ни өчен укырга Мәскәүгә

китте? Казанда укырлык институт юк идемени? Әллә аңа Казан ошамадымы?» — дип сораучылар да очрый. Ул кадәресен каян белим. Үзе сайлады. Мәскәвен дә, физикасын да. Аның академик буласын белгән булсам, көндәлекләр алып барган булыр идем дә бит, белмәгәнмен дип кенә котылам.

— Әнисе, хәтерлисеңме, 19 нчы мәктәпне көмеш медальгә тәмамлагач, физика укытучысы Ольга Васильевна Юшканцева: «Малаегыз физиканы бик шәп белә, шул юлдан җибәрегез»,— дигән иде. Роальд үзе дә физиканы ярата иде. Бу фотоны карагач, аның шахмат уйнап йөргән чаклары да искә төште әле. Рәшит Нәҗметдиновка йөри башлагач, ничек остарды ул. Хәтта Казан чемпионы булды.

— Әйе, Роальд шахмат белән мавыкканга карап гроссмейстер, рәсем мәктәбенә йөргәнгә карап рәссам булмады. Барысын да физика җинде ахры.

М. В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университеты Роальд Сәгъдиев өчен зур фәнгә ачылган капка була. Гаҗәп, ни өчен физика факультетының егерме яшьлек студентын плазма кызыксындырды икән? Шлиман үз гомерен Трояны ачуга багышлаган кебек Роальд та ерак максатын офыктан күтәрелеп килгән Кояшта күргән. Ач сереңне, Кояш! Бөтен гомеремне сиңа багышлаячакмын!

Кояшның плазма хәлендә булуы безгә мәктәп дәресләкләреннән үк мәгълүм. Моннан сиксән ел элек К. Э. Циолковский «кешелек дөньясының иң яхшы өлеше сүнгән бер кояштан икенчесенә күчеп йөрер. Бик күп дециллион елдан соң без, бәлкем, әлегә кабынмаган, әмма хәзер яралгы хәлендә булган кояш янында яшәрбез»,— дип фараз кылган. Аның күрәзәлегеннән соң ярты гасыр да узмады, бер төркем совет галимнәре плазма булдыруга ирештеләр. Бу — киләчәктә кабыначак кояшның яралгысы түгелмени? Кем белә, бәлки, кешелек дөньясы кояштан-кояшка күчеп йөрмәс, бәлки җиһанга тереклек, кодрәт, яшәү көче бирәчәк ясалма кояш уйлап табар. Ул кояшның беренче нурларын кабызучыларның берсе итеп академик Роальд Сәгъдиев та саналыр. Югары температуралы плазма физикасындагы бер ачыш — «Галиев — Сәгъдиев — Коврижныхның күчеру тигезләмәсе» — шул тәүге нурларның берсе.

Ясалма кояш. Кояш кабызырга. Әгәр адәм баласы кулында ясалма кояш булса, ул табигать көчләренә ия булачак. Үз табигате көчләренә. Бу — кешенең холкы, психологиясе, аңында революцион үзгәреш китереп чы-

гаруга сәбәпче булачак. Бу — кеше шәхесенең гаять бай мөмкинлекләрен ачуга, эшкә җигүгә китерәчәк. Бу — Кеше күңелендә Кояш кабызуга тиң булачак.

— Ә менә монысы Роальдның студент вакытта төшкән рәсеме. Ул университетта бик яхшы укыды. Морозов, Сталин стипендияләрен алуын хәтерлим. Әнисе, исендәме, Роальд университетта укыганда Лев Ландауның тугыз имтиханын гел әйтә иде. Ландау зирәк кеше булган, студентны өенә чакыра да әңгәмә уздыра икән. Аның да хикмәте бар: беренче әңгәмәдән канәгать калмаса, студентны бүтән дәшми. Безнең Роальд Ландауның тугыз сынавын да уңышлы узган.

— Исеңдәме, университетны тәмамлар алдыннан Роальд кунакка кайтты да: «Нишлим икән, Ландау аспирантурага керергә тәкъдим итә»,— дип сорады. Үзенең эшләп карарга теләге зур иде. Курчатов җитәкчелегендәге Атом энергиясе институтына эшкә керәм дигәч, без каршы төшмәдек.

Бөек Ватан сугышы елларында фәнни эшчәнлеген Казанда алып барган, илебез атом фәненә, техникасына, энергетикасына нигез салган Игорь Курчатов Роальд Сәгъдиевның хәтеренә уен-көлкеле, җор телле, эш дигәндә бөтен барлыгын оныта торган шәхес буларак кереп калды. «Физкультпривет! Уңышлар бармы? Ачышлар бармы?» — Курчатовның шәкертләре белән очрашканда беренче сүзе, сәламе бу. «Сакал» (яшьләр үзара аны яратып шундый кушамат белән атап йөртә торган булганнар) әңгәмәдәшен һәрвакыт бик игътибар белән тыңлый, күзгә-күз сөйләшә, яшь шәкертнең йөзен, кулларын, үз-үзен тотышын игътибар белән күзәтә. Әңгәмәләрдән соң ул Роальд турында да ныклап уйлангандыр. Кем бу, нинди кеше? Нәрсәгә сәләтле, омтылышлары нидә? Фәнне нәрсә белән баетыр, илгә нинди файда китерер? Мөгаен, Р. Сәгъдиев белән әңгәмәләрдән чыгып, ул Атом энергиясе институтындагы иң яшь белгечнең фәнни язмышын, киләчәген алдан күргәндер, аңа зур өмет баглагандыр. Шулай булмаса, Сәгъдиевны мактап газетага мәкалә язар идемени? Бу вакытта Роальд баш-аягы белән фәнни хезмәткә чума... Һәм менә тәүге адымнар, тәүге уныш. Илебездә беренче атом электр станциясе эшли башлаган еллар була ул. Р. Сәгъдиев атом энергиясен тыныч максатларда куллану буенча II Женева конференциясендә инглиз телендә доклад ясый. Әлеге чыгыштан ук Р. Сәгъдиевның остазы И. Курчатов юлын дәвам итүче булуын күрергә мөмкин. «Атом, водород бомбалары үз өстенле-

геңне күрсәтү, башкаларны куркыту, янау өчен күс
булырга тиеш түгел. Атомны тыныч максатларда кул.
ныраг кирәк. Төрле илләр галимнәре, физикларның
өлкәдәге хезмәттәшлеге планетабызны савыктыруга, т
нычлыкны ныгытуга булышачак» — ди И. Курча'
1956 елны Англиянең Харуэллдагы фәнни үзәгендә сов
галимнәренең атом-төш реакцияләре белән идарә итү
ге эшләре турында чыгыш ясаганда.

Мостай Кәримнең «Ташлама утны, Прометей!» др
масында Прометей кешеләргә ут урлап алып бирә. К
шеләрдә үз көчләренә ышаныч, өмет уты кабыза. Гом
мән, җир шары Прометейларсыз яши алмый. Фән дөнь
сы варисларсыз яши алмый. 1960 елны И. Курчатов үл
Остазының үлемен авыр кичерә Роальд Сәгъдиев. Әм
тормышны, ачышларны дәвам итәргә кирәк. Роальднı
улы туа. Курчатов хөрмәтенә ул аңа Игорь исеме куı
тыра.

1960 елның 16 феврале. СССР Фәннәр Академиясен
С. И. Вавилов исемендәге физик проблемалар институт
Гыйльми совет утырышын академик П. Л. Капица алı
бара. Көн тәртибендә бер генә мәсьәлә — Р. З. Сәгъдие
ның кандидатлык диссертациясенә тәкъдим ителгән «С
рәкләндерелгән плазмада динамика мәсьәләләре» диг
хезмәте. Әлеге утырышның стенограммасында академı
М. А. Леонтовичның мондый сүзләре бар: «Мин Р. З. Сәг
диевның безнең бүлектә гаять зур роль уйнавы турын
басым ясап әйтәсем килә. Ул плазмага бәйле эшләр
теоретик кына түгел, тәҗрибә уздыручыларның эшен к
этләүче, үз фикерләрен тәкъдим итүче, хезмәткәрләр б
лән тәҗрибәләрне бергәләп тикшерүче дә. Ул шунды
типтагы теоретик ки, бездәге лабораторияләр өчен аны
бәһасе әйтеп бетергесез зур».

Әлбәттә, кандидатлык диссертациясе яклау Роаль
өчен көнбагыш яру кебек кенә булмагандыр. П. Капиц
үзе генә нинди «каты чикләвек»! Әмма шул утырышт
Петр Леонидович күрәзәче вазифасын да башкарган ди
әйтергә тулы нигез бар. Ул киләчәктә Сәгъдиевка до
тор, хәтта академик дәрәҗәсе юрый, ул әле югарырагы
на да ирешер, ди. Уенын-чынын кушып: «Кызганыч, шун
дый кызык һәм мөһим эшне диссертант ашыгыбрак баш
карган. Безгә берничә елдан тагын җыелырга һәм аң
доктор дәрәҗәсе бирергә туры киләчәк»,— ди.

Роальд Зиннуровичның докторлык диссертациясен як
лау тарихы кызыклы. Физика-математика фәннәре кан
дидаты исемен алган егерме сигез яшьлек ир-егет (аны

бу дәрәҗәгә аспирантурада белем алмыйча гына ирешүен дә онытмыйк) Новосибирскига килгәч атом-төш физикасы институтында лаборатория оештыра. Кояш серен ачу, Себердә Кояш кабызу — яшь галимнең бөтен максаты шуңа юнәлгән. Кандидатлык диссертациясе сирәкләндерелгән плазмада динамика мәсьәләләренә багышланса, бу юлы Р. Сәгъдиев кояштан җибәрелә торган планетаара плазманы өйрәнә башлый. Үзенең теориясен, фәнни фикерләрен ул лаборатория шартларында тикшерә, дөреслеген исбатлый.

«Мең дә бер кичә» әкиятендә чүлмәктән чыккан җенне хәтерлисезме? Чүлмәк авызыннан төтен күтәрелә башлый, зурайганнан-зурая барып ул гаять көчле гыйфриткә әверелә. 10 миллион градуска җиткереп кыздырылган плазманы шул хәлендә шактый вакыт тоту «гыйфрит»не баш идерү, үзенә буйсындыру дигән сүз. Ярый, әкияттә әкияттәгечә булсын, ә менә атом һәм термик атом-төш энергиясен нинди чүлмәктә сакларга, кайсы шешәдә тотарга? Ун миллион градуслы кайнарлыкка кайсы шешә чыдар икән?

Галимнәр плазма үзлекләрен өйрәнә торгач бу «гыйфрит»не авызлыкларга мөмкин булуын белделәр... Плазма бик күп корылган кисәкчекләрдән гыйбарәт, шулай булгач аны электр һәм магнит кырында гына тотып булачак. Иң кулае — магнит кыры. Әнә шулай итеп Р. Сәгъдиев җитәкчелегендә Себер галимнәре йөз миллион градуслы плазманы магнит кыры «шешәләре»нә — ТОҚАМАҚларга салып тотуга ирешәләр. 1968 елны Новосибирскиның Академия шәһәрчеге плазма буенча халыкара конференция уздыру өчен сайлап алынуына академиклар Р. З. Сәгъдиев, С. Т. Беляев, А. М. Будкер кебек галимнәрнең иҗади хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә туган ачыш сәбәп булды. Шушы елның 11 апрелендә Роальд Сәгъдиевны докторлык диссертациясен уңышлы яклавы белән котлыйлар. Ә инде 36 яшендә ул академик була.

Роальд академик Сахаров белән Мәскәү университетын тәмамлаганда таныша. Диплом эшенең гамәли өлешен ул Андрей Дмитриевич җитәкчелегендәге бүлектә башкарырга тиеш була. Шул чакта аңа йолдызлар эчендәге процесслар — энергия күчерү, нурланышка кагылышлы тема бирәләр.

Нәкъ шул елларда академиклар А. Сахаров белән И. Тамм плазманы идарә ителә торган термик атом-төш синтезына җиткерү өчен магнит белән «йөгәнләргә» кирәк дигән фикер әйтәләр. Соңрак бу идея белән Роальд та

«җенләнә». Ул хезмәттәшләре белән берлектә термик атомтөш энергиясен, плазманы академик Сахаров ачкан магнит «аккумуляторлар» ярдәмендә ТОКАМАКларда булдыруга ирешә.

Сәгъдиев — көчле теоретик кына түгел, тәҗрибә уздыручылар эшен куәтләүче, яңа идеяләр тәкъдим итүче дә. Роальд Зиннуровичның бу сәләте Новосибирскида тагын да тулырак ачыла. Ул Урал һәм Себердәге югары уку йортларыннан сәләтле яшьләрне эзләп таба, аларны Новосибирскига эшкә чакыра. Үзе белән бер көнне физика-математика фәннәре докторы булган В. Покровскийның фәнни казанышында Роальд Зиннуровичның катнашы зур була. Академия шәһәрчегендә тугыз ел эшләү чорында (1961—1970 еллар) аның шәкертләре А. Галиев, В. Карпман, Сәгъдиев теориясе буенча тәҗрибәләр алып баручы Р. Нуртмуллаев, В. Захаров фән докторлары дәрәҗәсенә күтәреләләр. Утыз яшендә фән докторы, угыз икедә СССР Фәннәр Академиясенең член-корреспонденты, утыз алтыда академик булган Р. З. Сәгъдиев 1970—1973 елларда югары температуралар физикасы институтында бүлеккә җитәкчелек иткәндә дә, 1973—1988 елларда СССР Фәннәр Академиясенең галәмне өйрәнү институты директоры булып эшләгәндә дә бик күп булачак галимнәрнең остазына, киңәшчесенә әверелә.

...1975 елның көзе була ул. СССР Фәннәр Академиясенең вице-президентлары П. Федосеев һәм В. Котельников кабинетларында ыгы-зыгы: танылган академиклар, галимнәр ишек катыннан өзелми. Ни өчен шундый угы-чугы, мәшәкать дисезме? Бу көннәрдә Нобель премиясенә лаек булган, Совет илендә шәхес ирегеи кысуга, термик атомтөш энергиясен Кешеләр гомерен өзүгә, үлем максатларында куллануга каршы чыккан академик А. Сахаровны кискен гаепләп үзәк газеталарның берсендә бастырырга әзерләнгән мәкаләгә кул кую өчен. СССР Фәннәр Академиясенең член-корреспонденты, академик, галәмне өйрәнү институты директоры Р. Сәгъдиевны да онытмыйлар. Ә ул исә карьера, һәртөрле исем-дәрәҗәләр, өстенлекләргә алданмыйча остазы, фикердәше ягына баскан бердәнбер кеше була. Р. Сәгъдиев академик Сахаровка бөһтан ялалар яга торган, пычрак хатка кул куюдан баш тарта.

Торгынлык елларында җиде елга Горький шәһәренә сөрелгән, орден-медальләреннән, исем-дәрәҗәләреннән мәхрүм ителгән А. Сахаровка элекке дәрәҗәсен кире кайтаруны таләп иткән бердәнбер кеше дә Роальд Сәгъдиев булды. Ниһаять, 1988 елны Андрей Дмитриевичка Ленин

премиясе һәм СССР Дәүләт премиясе, Социалистик Хезмәт Героеның өч алтын йолдызы кире кайтарылды, ул СССР Фәннәр Академиясенең Президиумына сайланды.

— Роальдның галим дуслары белән 1985 елны Казанга кайткач төшкән бу рәсеме миңа бик тә таныш. Роальд институтында ясалган «Вега» галәмгә очты. Радиодан, телевизордан шул турыда сүз чыкса, бөтен эшемне читкә куя идем. Роальд турында сөйләмәсләрме, үзен күрсәтмәсләрме дип радио, телевизор янынннан китмим. Үзең беләсең, соңгы елларда Казанга еш кайта алмады ич. Бик сагына идек үзен.

Кояш системасы планеталарын даими өйрәнүнең әһәмиятен аңлатырга кирәкме икән? Безнең Галактикада 100 миллиардка якын йолдыз бар, астрономнарга исә бердәнбер планета системасы — безнеке генә мәгълүм. Айны, Венераны, Марсны өйрәнү аларның үсеш закончалыклары бердәй булуын күрсәтә. Мәсәлән, Җирнең якын күршесе Венера (без аны Чулпан йолдызы дибез) галәмне өйрәнү программасында аерым урын тота. Шуңа күрә элеге планетага космик аппаратлар күпләп җибәрелде дә иде. «Вега» (Венера һәм Галлей сүзләреннән алынган) фәнни проектын төзегәндә Роальд Зиннурович бик акыллы, кызыклы, экономияле чишелеш тапты.

Өстәп шуны гына әйтик: «Венера — Галлей кометасы» халыкара проектын тормышка ашыруга зур өлеш керткәне өчен СССР Фәннәр Академиясенең галәмне өйрәнү институты директоры Роальд Зиннурович Сәгъдиевка 1986 елны Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде.

Марсның иярчене Фобосны өйрәнү Р. Сәгъдиев эшчәнлегендә аерым урын тота. Академик бу юлы да «Фобос» станцияләренә «Вега»ларга хас бурычны йөкләде: Кояшны өйрәнергә. Әлбәттә, «Фобослар»ның төп максаты «кызыл планета» — Марсның иярченен өйрәнү иде. Ни өчен нәкъ менә Фобоска йөз тотты соң ул? Кайбер галимнәр фикеренчә, Җир климатына якындагы уп елда һәлакәт яный. Бу бәхәсләр, фараз итүләрне исбатлау, чишү өчен иң яхшы юл — Җирнең «игезәге» булган Марсны, аның иярченнәрен өйрәнү. Роальд Зиннурович фикеренчә, галәм киңлекләрен, башка планеталарны ныграк өйрәнгән саен без үзебез турында күбрәк беләчәкбез.

— Зиннур, без синең белән бәхетле ата-ана булдык. Улларыбыз халык арасында мөхтәрәм кеше булып танылдылар...

— 80 яшь тулган көнемә кайта алмаслар дип борчылып тора идем. Дүртәүләп килеп кергәч югалдым да кал-

дым. Соңыннан белдем: Роальдның Америкадан, Ринатның Швециядән кайтып килеше булган. Роальд, Ринат, Рөстәм тиз генә җыенып кайтырга булганнар. Татарстан поездыннан аларны Роберт каршы алган.

— Балаларның барысының да алай бергәләп җыелган чагы сирәк була. Нишлисең һәркайсының эше, гаиләсе дигәндәй...

Сәгъдиевлар гаиләсенең горурлыгы — ил агасына әверелгән акыллы, могтәбәр ирләр. Роальд Сәгъдиев — Ленин премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое, СССР халык депутаты. Ринат та абыйсыннан калышмады. Ул Новосибирскидагы Академия шәһәрчегендә эшли, СССР Фәннәр Академиясенең Себер бүлеге Химия кинетикасы һәм ялкыны институтында директор урынбасары. Ленин премиясе лауреаты, химия фәннәре докторы. Роберт — Казанда фәнни-тикшеренү институтында экономист булып эшли. Төпчек Рөстәм — Калугада, Роберт кебек фәнни-тикшеренү институтында экономист. Бердәм өйдә бәрәкәт бар. Туганнарның татулыгы байлыктан артык, ди татар мәкале. Нәкъ менә Сәгъдиевлар гаиләсе турында әйтелгән ул. Халкыбыз даның илгә генә түгел, дөньяга таныткан гаилә ул Сәгъдиевлар гаиләсе.

Газинур Вәлиев

ГАГАРИН ОТРЯДЫННАН БЕРӘҮ

Галәм, космос, ракета, «Восток», «Союз», «Салют»... — бу сүзләр хәзер берәүне дә гаҗәпләндерми. Без инде космосны үзләштерү, галәм киңлекләрен өйрәнү чорында яшибез. Космонавтларыбыз сәгатьләр, тәүлекләр генә түгел, ә бәлки еллар дәвамында орбитада яшиләр, эшлиләр. Без бүген аларның кайберләренең исем-фамилияләрен дә истән чыгарабыз, чөнки очыш рекордлары үзгәреп, яңарып тора. Ә шул вакытта беренчеләр турында нәрсә беләбез соң? Дөресен әйтик, моңарчы без алар турында аз белдек. Әйе, Гагарин, Титов, Комаров, Быковский, Леонов, Терешкова исемнәре безгә яхшы таныш иде. Ләкин күпме хәзерләнеп тә космоска оча алмаган — үзенең хыялын, теләген тормышка ашыра алмаучылар да булган

бит! 1986 елда «Известия» газетасында беренче космонавтлар отрядының (бүген аларны хаклы рәвештә «Гагарин отряды» дип атыйлар) исемлеге басылды.

Дөрес, аларның бишесе бер тапкыр космоска менгән, бишесе ике тапкыр космик корабль белән идарә иткән, икесе исә өч тапкыр галәм киңлекләрен айкаган. Ә сигезе туры мәгънәсендә космонавт була алмаган. Шулай да без аларны да хаклы рәвештә космонавт дип атый алабыз. Алар арасында Марс Рафиков исеме дә бар.

Марс Закирович Рафиков тумышы белән Кыргызстаннан. Әтисе — Башкортстан татары, Бөек Ватан сугышында һәлак була. Әнисе Мәрзия Галәветдиновна Буа районының Исәк авылында туып-үскән.

Марсның балачагы сугыш чоры малайларыныкы кебек. 14 яшендә ул тылдагы тырыш хезмәте өчен хөкүмәтебез бүләгенә лаек була. Ә 1961 елда космик очышларга әзерләнгәндә күрсәткән хезмәтләре өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә. Ул көннәрне Марс Закирович үз язмышындагы иң истәлекле чор дип саный.

Космик очышларга әзерлек Гагарин стартына кадәр үк башлана. Җирнең ясалма иярченнәрен, этләрне орбитага чыгару вакыйгаларын исегезгә төшерегез. Ә 1959 елда космонавтлар отрядына кандидатлар җыюга керешәләр. Сәламәтлеге нык, буе 170 сантиметрдан, авырлыгы 70 килограммнан артмаган 30—35 яшьлек очучылар кирәк була. Андый сыйфатларга ия булучыларны, беренче чиратта, хәрби-һава көчләреннән эзлиләр.

— Безнең частька да шундыйдер кешеләр киләчәге, аларның махсус задание үтәү өчен кандидатлар эзләүләре турында хәбәр таралды,— дип искә ала Марс Рафиков.— Бервакыт мине дә алар каршына чакырдылар. Хәлне аңлатып бирделәр, ләкин космос турында бер сүз дә булмады. Бераз уйлаганнан соң ризалыгымны бирдем.

Менә шулай 2 мең очучы арасыннан 200 кешене Мәскәүгә җыялар, тора-бара алар 20 гә кала. 1960 елның 11 гыйнварында КПСС Үзәк Комитеты карары белән Космонавтлар әзерләү үзәге оештырыла, шулай итеп Йолдызлы шәһәрчегенә нигез салына. Аның начальнигы итеп авиация медицинасы белгече Е. А. Карпов билгеләнә. 20 кешедән торган отрядның тормышы теоретик дәресләр, практик күнегүләр белән чиратлаша. Төрле җирләрдә хезмәт иткән, төрле характердагы, төрле яшьтәге, төрле милләттән булган очучылар бик тиз үзара уртак тел табалар. Әлегә аларны кем беренче булачагы кызыксындырмый, һәркайсы бары тик сынатмаска тырыша.

— Парашют спорты буенча атказанган спорт мастеры Н. К. Никитин җитәкчелегендә парашют белән сикерү буенча күнегүләр уздырганнан соң Йолдызлыга кайттык. Безне кыска буйлы, таза гәүдәле, мөлаем кеше белән таныштырдылар. Ул үзен «профессор Сергеев» дип атады. Аның Сергей Павлович Королев икәнен соңыннан гына белдек. Королевның безгә визитлары торган саен ешая барды. Бервакыт ул безне космик корабль эшләнә торган цехка алып барды. «Восток»ны күрсәтте.

— Я, кайсыгызның утырып карыйсы килә? — диде ул.

— Миңа рөхсәт итегез?

— Рәхим ит, Юра!

Гагарин корабль кабинасына керер алдыннан ботинкаларын салып куйды. Аның бу карары Королевның күңеленә артыгы белән хуш килде, елмаеп җибәрде.

Күнегүләрнең ниндиләрен генә күрмәдек. Сурдобарокамераны беренче булып Валерий Быковский үзләштерде. Тәүгеләрдән булып мин дә анда сынау үттем. Бервакыт йоклаган чагымда сулау приборы сафтан чыккан. Тикшерү үткәрүче врач курка калган. Янәсе, үлмәгәнменме? Ул микрофон аша кычкыра башлый. Уянып китеп, гаҗәпкә калдым. Мин әйтәм, тавыш галлюцинацияләре шулай буладыр инде.

Скафандрны сынауны алыйк. Температура 55 градус җылы, дымлылык 40 процент. Өченче тәүлекне уздырганда йокы килә башлады, төшкә диңгез, су фонтаннары керде...

Отрядка килгәндә Комаров, Гагарин, Титов, Беляев, Шонин гына тәмәке тартмый иде, әмма тиздән калганнарыбызга да аларның үрнәгенә ияргә туры килде. Күнегүләр шуны таләп итте.

Күнегүләрдән, дәресләрдән тыш вакытларын отряд членнары бергә үткәрәләр. Андый вакытта гадәттә җитәкчелек Рафиков кулында була. Су коенырга барулар дисеңме, яки шашлык пешерүләр, төрле ярышлар үткәрү — барысы да аның катнашында оештырыла.

С. П. Королов вакыт үткән саен күнегүләрне ашыктыра бара. 20 кешелек отряд белән эшләү читенләшә. Нәтиҗәдә 6 очучыдан торган группа оештырыла. Билгеле, аңа әлеге 20 нең һәркайсысы керә алыр иде. Ләкин барысы да исәпкә алына: буй, авырлык, сәламәтлек, кыяфәт, характер, күнегүләр вакытындагы чыдамлык... Беренче «алтылыкка» түбәндәгеләр керә: Варламов, Гагарин, Карташов, Николаев, Попович, Титов. Әмма озак та үтми, составта үзгәрешләр була. Сәламәтлекләре

аркасында Карташов белән Варламов галәмгә чыга алмыйлар.

Алар урынына Григорий Нелюбов һәм Валерий Быковскийны алалар. Әзерлек дәвам итә. Корбаннарсыз да булмый. 1961 елның 23 мартында отрядның иң яшь члены — 25 яшьлек очучы-истребитель Валентин Бондаренко һәлак була. Сурдобарокамерада 10 нчы тәүлеген уздыручы егет медицина тикшеренүләре узганда кирәкмәскә чыккан мамык кисәген читкә алып ташлый. Игътибарсыз рәвештә ыргытылган мамык эшләп торган электр плитәсе спираленә барып төшә. Нәтиҗәдә кислородка артыгы белән бай камерада янгын чыга. Валентин баштарак утны үзе генә сүндерергә тырышып карый. Әмма кыйммәтле секундларны гына югалта. Камерадан чыгарганда ул әле исән була, бары бер сүзләрне кабатлый: «Мин үзем гаепле». 8 сәгать дәвамында врачлар егетнең исәнлеге өчен көрәшсәләр дә, аны коткарып кала алмыйлар.

— Марс Закирович, ә шулай да әлеге алты кеше арасыннан ни өчен беренче итеп нәкъ менә Гагаринны сайлыйлар?

— Бу сорауга кистереп җавап бирү авыр, әлбәттә. Отрядта лидерлар җитәрлек иде. Мәсәлән, Волынов парашют белән әйбәт сикерә, Николаев — центрифугада, Шонин — термокамерада, Быковский исә сурдобарокамерада сынауларны җиңел кичерә. Комаров теорияне әйбәт белә. Беляев командир буларак игътибарга лаек. Ә Гагаринны аерып торган нәрсә юк кебек. Аерып торган бер сыйфаты да булмау — мөгаен, Гагаринның иң төп сыйфатыдыр. Аның турында Леонов төгәл әйтә: «Юра беркайчан да, беркемнең дә күзенә бәрелеп тормый, ләкин аны сизмичә калу мөмкин түгел». Гагаринның лидерлыгын барлык уңай сыйфатларны бергә берләштерә алуы белән аңлатырга мөмкин. Ул беркайчан да артта булмады, һәрвакыт беренчеләр рәтендә иде.

Очыш алдыннан отрядка яшерен рәвештә анкета таратыла: кем очарга тиеш? 20 кәгазьнең 17 сендә Гагарин фамилиясе язылган була. Иптәшләре аны хөрмәт итеп кенә калмыйлар, ә бәлки чын-чынлап яраталар.

Гагаринның дублеры итеп Титовны билгеләделәр, ә икенче дублер итеп Нелюбовны куйдылар. Әлбәттә, дублер булу да зур җаваплылык йөкли иде.

— Космоска менеп төшкәч, мөгаен, Гагарин үзгәрә төшкәндер?

— Һич юк. Ул һаман да шул Юра булып калды. Бер вакыйга искә калган. 61 нең ахырлары иде бугай. Аме-

рика белән совет баскетболчылары арасында матчлар уздырылган вакыт. Мин культура-спорт чараларын оештыручы буларак, отрядка билетлар алып кайттым.

— Миңа да алдыңмы? — дип сорый Юра.

— Син нәрсә, беренче космонавтка нинди билет кирәк булсын, сине бөтен дөнья белә бит!

Юраны бу сүзләр шатландырмады. Үзенчә үпкәләп тә алды, шулай да баскетболны яратучы буларак, безнең белән спорт сараена кузгалды. Касса алды халык белән тулы. Гагарин бер иптәшебезгә үзенең «космонавт № 1» таныклыгын биреп, кассадан билет алырга җибәрде. Үзе бик кыенсына. Иптәшебез көч-хәл белән дигәндәй, тәрәзә янына үтте. Ләкин кассир аңа шундук билет бирәсе урынга тавыш куптарды. Эш менә нәрсәдә булган икән: Гагарин таныклыгын ниндидер бер чит кеше күрсәтеп маташа, ә Юраны танымаучылар ул вакытта бөтенләй булмагандыр, мөгаен. Нәтиҗәдә кассир милиция чакыра башлый, Гагаринның үзен күргәч кенә тынычлана.

Әйе, ул бездән бер ягы белән дә аерылып торырга теләмәде. «Мин-минлек» дигән нәрсә Юрага бервакытта да хас булмады.

— Ә аның үлеме турында сез нинди фикердә?

— Юрий һәм аның инструкторы Владимир Серегин 1968 елда күнегү очышы вакытында һәлак булдылар. «Правда» газетасында Гагарин белән Серегин һәлакәте турында профессор Белоцерковский белән очучы-космонавт Леоновның ике язмасы басылды. Нишләптер, анда язылганнар белән килешеп бетәсем килми. Аларга һәлакәттән котылу өчен 2 секунд вакыт җитмәгән, янәсе. Шулай итеп, очучыларның осталыгы шик астына алынган. Серегин — тәҗрибәле очучы-инструктор, ә Гагарин, белгәнегезчә, диңгез авиациясендә хезмәт итеп килгән очучы-истребитель. Минем уйлавымча, Гагарин белән Серегин самолеты магнит дулкыннары ташкынына эләккән булырга тиеш. Бу фикер күпләр белән очрашып сөйләшкәннән соң туды. Соңгы вакытта үзәк матбугатта басылып чыккан мәкаләләрдә бу вакыйгага ачыклык кертелде.

— Марс Закирович, космонавтлар отряды членнарының язмышлары белән якыннанрак таныштырып китсәгез иде.

— Белгәнегезчә, Гагариннан тыш, әле тагын бик күпләр галәмгә чыктылар, бөтен дөньяда танылдылар. Хәзер Йолдызлы шәһәрчегендә яшиләр, космонавтлар әзерләү үзәгендә эшлиләр. Бондаренко һәлак булды. 1967 елда «Салют» кораблен сынаганда Комаров һәлакәткә оч-

рады. Нелюбов... Титовның очышыннан соң Нелюбов, Аникеев, Филатьев «салган» килеш хәрби комендатурага эләгәләр. Һәм отряд командиры аларның өчесен дә отрядтан чыгару турында приказ яза. Әлбәттә, бу вакыйгада төп гаепле Григорий, ә Аникеев белән Филатьев аның «кайнарлыгы» корбаннары. Заикин исә сәламәтлеге аркасында очмыйча калды.

— Марс Закирович, ә үзегезнең тормыш?

— Мин отрядтан 1962 елда киттем. Кавказда һәм Карпатта хәрби самолетларда очарга туры килде. 30 еллап гомеремне авиациягә багышладым, 14 төр самолетны сынадым. 46 яшемдә лаеклы ялга чыктым, гаиләм белән Алма-Атада төпләндем. Бер вакыйга истә калган. Самолетым һәлакәткә очрагач, катапульта ясарга туры килде Берәүнең бакчасына килеп төштем. Хуҗаның ничек гаҗәпләнгәнен күрсәгез иде...

— Гаиләгез турында да берничә сүз әйтсәгез иде.

— Хатыным Рәйхана Кадыйровна Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган белгеч. Улым хәрби һөнәрне сайлады. Кызыбыз музыкаль училищеда, консерваториядә укыды. Менә әнием әманәте буенча янә Казанга — Татарстанга кайттым, туганнар, якташлар белән очраштым.

Инде олыгая төшкән Марс Закирович Рафиковка карыйм. Менә ул тере тарих, безнең горурлык. Аның белән сөйләшкәннән соң үзеңне Гагариннар буыны, беренче космонавтлар белән очрашкан кебек хис итәсең.

Айрат Садыйков

БЕЗ — ҖИР УЛЛАРЫМЫ?

«Бик җайлы шөгыль таптым: кармакларымны алам да көн саен балык каптырырга китәм. Шулай ике көн узды. Өченче көнне миңем белән сәер хәл булды. Шулай яр буенда балык каптырам. Тып-тыныч. Әкәмәт сәер тойгы кичердем. Эчем «жуу» итеп куйды, дип кенә әйтү аз булыр, аяк табанымнан алып баш түбәмә кадәр өнемне

алып ток узгандай булды. Чак кына урле-кырлы сикермәдем. Көпә-көндез бит, баш очымда — кояш, алдымда елга елтыр-елтыр ага. Шундый тойгы, гүя, артымда кемдер бар, ул мине эзәрлекли, яный сыман. Авыл кешеләре: сак булыгыз, бу тирәдә котырган аю йөри дип кисәткәннәр иде. Беренче уем шул булды: аю тырнагына капҭым. Борылып карасам, җан әсәре юк...»

Пермь өлкәсенең «М өчпочмагы» дип йөртелгән урында — Сылва елгасы буендагы Молебка авылында башка цивилизация әһелләре белән очрашыр алдыннан Виктор Коршунов әнә шундый тойгы кичергән. Ә инде төнлә, йокларга яткач... Хәер, Казан кунагының нинди әкәмәтләргә, могҗизага тап булуын алдан чишеп салсак, хикәятебезнең кызыгы калмас. Иң элек «М өчпочмагы» дип йөртелгән урынның тарихы белән танышып үтик. Риганың «Советская молодежь» газетасы журналисты Павел Мухортовның (ул галәмгә очарга җыенучы космонавтлар отрядында медицина тикшеренүләре уза): «Мин Җирдән читтә яшәүче космик цивилизация белән элемтәгә кергән беренче журналист»,— дигән сенсацияле белдерүеннән, матбугаттагы язмаларыннан соң Пермь өлкәсендәге Молебка авылы меңләгән кешенең табыну урынына — тылсымлы «Мәккә»гә әверелде.

Оча торган «тәлинкә»ләр, гантель, эшләпә, банан рәвешендәге әкәмәтләр күрәсегез киләме? Йолдызлардан килгән кунаклар белән кайсыгызның элемтәгә керәсе килә? Башка цивилизацияләр турында палатка стенасында «кино» карарга телисезме? Андый теләк-ниятләрегез булса, «М өчпочмагы»на — Молебка авылына рәхим итегез. «Советская молодежь» газетасы хәбәрчеләре В. Синицын һәм В. Шулаков язмалары әлеге урын белән кызыксынуны тагын да көчәйтеп җибәрде. Хәзер Пермь өлкәсе экскурсияләр, туристик сәяхәтләргә килүчеләрне кабул итү ягыннан теләсә кайсы тарихи урын белән ярышырлык. Монда яшәүче бер карчыкның елга аша көймәдә көненә өч йөзләп кешене бер яктан икенче якка чыгаруын сөйлиләр. Унарлап, егермеләп, утызлап та киләләр, кемнәр генә килми! Молебка авылына студентлар да, медиклар, геологлар, галимнәр, хәтта шуның өчен гаиләсеннән, туганнарыннан, эшеннән ваз кичеп бомжга (аларны «яңа иман апостоллары» дип йөртәләр) әверелгән кешеләр дә сукмак салган. Юл чыгымын каплау өчен дә, «сырхауга дәва, сихри көчкә ия» дип тә Молебкадан туфрак, тайга урманыннан агач кисеп алып китүчеләр дә бар икән.

Бу мосафирларның һәммәсе эше юктан кызык эзләп

йөрүчеләр икән, дип уйлап ялгышмыйк. Бу авыл туфрагына фәнни максатларда аяк баскан кешеләрне «сталкер» дип атыйлар. Мәсәлән, Казан шәһәренең «Факт» группасы егетләре Молебкада фәнни-тикшеренү уздырырга, аномаль зона һәм хәлләрне өйрәнү өчен юлга чыкканнар. 1989 елның көз, кыш айларындагы сәфәрләре нәтиҗәләре турында «Комсомолец Татарии» газетасының кайбер саннарында басылып та чыкты. Шул группаның бер әгъзасы — Дмитрий Хафизовның Пермь өлкәсенең Молебка авылына баргач башыннан кичкәннәрен тыңлап карыйк әле.

— Без Молебкага беренче тапкыр октябрь аенда өч көнгә бардык. Килеп төшсәк... Бәй, без монда ялгыз түгел икән ич. Илебезнең кайсы якларыннан гына килмиләр икән бирегә! Килә торалар, китә торалар. Сталкерларның беришесе безне: «Монда өнне ала торган, бик куркынычлы алан бар, сак булыгыз!» дип кисәтте. Свердловск ягыннан килүчеләр болай дип тә өстәде: «Менә без әйтте диярсез, шул аланга аяк басып палатка кору белән, яңгыр коя башлаячак». Гаҗәпләнүебезгә каршы, нәкъ шулай килеп чыкты да. Иртән палаткадан чыкканчы яңгыр өзмәде дә, куймады да.

Монда башка сыймый торган хәлләр еш була икән. Әйтик, башта коеп яңгыр ява, аннары гына кургашын болытлар куера башлый. Югыйсә, киресенчә булырга тиеш. Яки бер үк араны төрле вакытта узасың. Анда үр менеп төшә торган урын бар. Сигез йөз метрлап булыр. Шуны мин беренче тапкыр көзге пычракта, биштәр асып, унбиш минутта уздым. Икенче тапкыр, коп-коры, аяз көнне дә унбиш минутта үттем. Ә өченче мәртәбә тездән пычрак изеп биш минутта кичтем. Яңгыр явып үткәч, палатка стенасына ак порошок утыра. Андрей тәвәккәлләп аны авызына кабып карады. «Җәмәгать, гап-гади акбур ич бу!» — димәсенме! «М өчпочмагы»ндагы шарсыман, элипсоид рәвешендәге томан, кардагы өчпочмак, ярымшар билгеләр, чылбырлы трактор эзенә (бер ягына гына) охшаш эзләр, урман эченнән Свердловск егетләре корган палатканың баш очына кадәр сузылган аномаль полоса безнең өчен табышмак булып кала. Әйтергә оныткамын: безне килеп төшкән шәпкә бер карчык Сылва елгасы аша чыгарырга ниятләде. Әмма аның «калтырча»сы безне чыдатмады, юл капчыкларыбыз, биштәрләребез чүрәкәй үрдәкләр сыман йөзеп киттеләр. Бата-чума теге як ярга чыккач, биштәрләрдән суны түгәргә тотындык. Ни гаҗәп: фотоаппарат, фото-кино тасмалар салган капчык-

ларыбыз гына манма иде. Фотоаппарат булмаган ертык, иске биштәрләр коры дияргә була. Анысы бер хәл, «М зонасы»на кергәч фотоаппаратлар эшләүдән «баш тартты». Күгәреп каткан диярсең. Фонарьларның батареялары «утыруын», фотоаппарат яктырткычларының янып чыгуын, сәгатьләр һәм компасларның дөрес күрсәтмәвен нәрсә белән аңлатырга? Монда каты кычкырып сөйләшсәң, сүгенсәң, өермә күтәрелә, учак ягуга болытлар пәйда була. Шундый хәлне көлеп сөйлиләр. Берәүләр «М өчпочмагы»нда хәмер эчәргә җыенган булган. Әмма ниндидер көч аларны шундый итеп куган, алар хәтта палатка корганда каккан казыкларын суырып алырга да өлгермәгәннәр. Явыз ният белән, үзләренә ниндидер файда эзләп килгән кешеләр дә аланда озак тора алмый. Мактанып әйтү түгел: безнең группа «Курку үзәне»ндә дүрт сәгатьтән артык яшәп үзенә күрә рекорд куйды.

Гомумән, монда адым саен — табышмак. Молебкада вакытның дүрт сәгатькә алга китүен ни белән аңлатырга? Монда вакыт үлчәме бөтенләй башка. Бервакыт өч сәгатькә югалып торган егетне иптәшләре: «Син кайда йөрисең? Сине өченче көн дөнья бетереп эзлибез бит инде!» — дип каршылаганнар. Бу зонада ундүртенче көнне кешенең температурасы кырык бергә күтәрелә. Тиз генә ярдәм күрсәтмәсәң, бәлагә тарган кешенең «янып» үлүе дә бар.

«Советская молодежь» газетасы каршындагы тарих-география җәмгыяте әгъзалары Олег Орловский белән Виктор Коршунов та «М өчпочмагы»нда сәер, могҗизалы хәлләргә адым саен очраганнар. Язмабызны В. Коршунов хикәятеннән башлаган идек. Төнлә йокларга яткач аның белән нәрсә булган, дисезме? Хәер, бу хакта Виктор үзе яхшырак сөйләр.

— Палаткада йокларга яткач мин кирәкмәгән уй-хисләрдән котылыр өчен Запорожьедан килгән гипнозчы Сергей киңәше буенча күз алдыма утлы боҗра булдырырга тырыштым. Байтак тырышкач кына әлеге утлы боҗраның очын-очка ялгый алдым. Боҗра ялгануы булды, ул дөрләп кабынды. Боҗра эчендә ак томан хасил булды, аннары мин матур йөзле, сакаллы, озын чәчле, киң маңгайлы, төз нечкә борынлы картны күрдем. Әлеге картның йөзе бераздан юкка чыкты, аның урынына латин хәрефе, спираль, өчпочмак, аның түбәсендә ромб пәйда булды. Ул да булмады, мин чытыр-чытыр килгән аваз ишеттем, гүя, югары көчәнешле электр линиясе астында ятам. Шуннан соң гына тынычлап йокыга киткәнмен.

Көтмәгәндә төнлә уяныл киттем. Нәрсәдер булырга тиеш кебек. Әллә иптәшләрем сөйләгәнчә, палатка стенасында «кино» күрсәтергә җыеналар микән? Юк, «кино» да, башкасы да күренмәде. Күз алдымда тагын аксыл томан пәйда булды, күземне чытырдатып йомсам да юкка чыкмады. Шулвакыт кемнеңдер минем баш «тартма»-ма кереп «оялаганын» сиздем. Миңа эндәшәләр иде. Тавыш-тынсыз гына, күңелдән.

— Син кем? Нигә безнең белән бәйләнеш эзлисең?

— Мин — кеше. Мин сезгә бары тик яхшылык кына телим. Сезнең турында күбрәк беләсем килә.

Алар мине өч көн һәм ике төн буе күзәтүләрен, минем башка иптәшләремә ошамавымны әйтте. Мин алар белән элемтәгә керә алуыма өметләнмәвемне, шуңа күрә тыныч кына балык каптыруны хуп күрүемне белдердем. Алар һәммәбезне дә күзәтү астында тоталар икән, бу юлы минем белән элемтә урнаштырырга булганнар, күрәсең. Мин балык тотканда сәер тойгы кичерүемне, төнлә йокларга яткач күз алдымда карт кыяфәте пәйда булуын әйттем, боларның нәрсә аңлатуын сорадым. Карт йөзе — символ икән, алар шулай итеп минем аңыма үтеп кергәннәр. Аннары: «Синең миеңдәге мәгълүматны укырга мөмкинме?» — дип сорадылар. Ризалык биргәч, шундый тойгы кичердем: гүя, мине китап битләрен ачкандай «укыйлар». Егерме минут буе миңа сорау арты сорау яудырып кына тордылар. Элемтә вакытында мин үземне шулкадәр җиңел, иркен, әйбәт хис иттем, җан рәхәте кичердем дисәм дә арттыру булмас. Әйтерсең мине җирдән күтәреп бишектә тирбәтәләр, әмма бишекне дә, тәнемне дә тоймыйм.

Ә инде иртән уянгач... Җеп өзәрлек тә хәлем юк, әйтерсең төне буе утын ярганмын. Ул көнне эш кайгысы булмады, мин бу төнне дә элемтә буласын белгәнгә тизрәк йокларга яттым. Алар белән бәйләнешкә кергәч тагын күңелдән генә әңгәмәне дәвам иттек. Дөресрәге, алар миңа сорау арты сорау яудырып кына торды. Мин бер генә түгел, хәтта берничә әңгәмәдәшнең сорауларына җавап бирүемне сиздем. Сорау арты сорау... Җавап бирүне тоткарласаң, сорау берничә тапкыр кабатлана. Үзем дә аларга берничә сорау бирә алдым. Шундук җавап бирделәр.

Ничек башыма килгәндер, мин аларны күрергә теләвемне «әйттем». Җавап урынына мине югарыга күтәрә башладылар. Биеклек чама белән йөз-йөз илле метрлап булгандыр. Үзебезнең палатканы, учак янында гәп сатып утыручы өч иптәшемне күрдем. Аланны, елганы, урман

чалымнарын аермачык күрсәттеләр. Югарыга күтәргәндә ни җил, ни тәнне һава кытыклавын тоймадым. Шуннан мине көнчыгышка таба алып киттеләр. Күзләрем генә оча сыман, тәнне, кул-аякларымны тоймыйм. Күз алдымда буе сигез йөз, иңе чама белән дүрт йөз метр булган аланлык пәйда булды. Озынча тамчыга охшаган. Үзәнлек ай нурына күмелгән дип әйтергә була, ай нурыннан дүрт тапкыр яктырактыр да әле. Тик кайдан яктыртканны күреп булмый. Аста — аланда көмешсыман комбинезоннан алты-сигез сын күреп алдым. Ерактан аларның чырайларын танырлык түгел. Баш урынында ниндидер якты нәрсә. Әллә башлык инде, әллә чәч. Алардан кырык метрлап булыр, тагын өч сын күренде. Алар тораташ кебек катып калган, ә тегеләре нәрсәгәдер иелеп нидер кыландыралар иде.

Ун-унбиш секундлап алан өстендә тукталып торгач, мине алан буйлап сәгать йөрешенә каршы әйләндерделәр. Аннары сәгать теле уңаена әйләндек. Шуннан күзем томалангандай булды. Берничә секундтан соң мин үз палаткамда ятам, аяк-кулларым, тәнем дә үз урынында иде. Күрәсең, очыш-сәяхәт вакытында минем тәнем палаткада калган, ә җаным, аңым (тупас кына әйткәндә мием) «канатланганнар» булып чыга.

Аланлыкка икенче сәяхәт вакытында миңа йолдыздан килүчеләрне, аларның оча торган «тәлинкә»ләрен якыннан күрергә туры килде. Мине үзәнлеккә төшерделәр. Ике «тәлинкә»нең берсе җирдә ятса, икенчесе ике метр биеклектә «асылынып» тора. Бернинди терәксез. Бу юлы үзәнлеккә төшүгә мин үз аягымда басып торуымны, кул хәрәкәтләремне, гәүдәмне тойдым. «Тәлинкә» астына күз салсам, түгәрәк люк күреп алдым. Баскычсыз ничек менәләр икән моңа дип уйларга өлгермәдем, яныма ике гуманоид килеп басты. Йөзләре кешеләрнеке сыман, чырайлары матур, көмешсыман комбинезоннары ай нурында ялык-йолык килә. Алар телепатия юлы белән «тәлинкә»нең эченә күз салырга чакырды. Миңа очу аппаратының тышкы ягы да кызык тоелды. Диаметры ун метр чамасы, көмешсыман, терекөмешсыман дип әйтергә дә була. Терекөмеш ялтырый, ә бу тонык төстә. Миңа «кино» күрсәттеләр. Үзләренең галактикаларын. Алар яшәгән җиргә кадәр унҗиде миллион яктылык берәмлеге икән. Җирдән анда кайтып җиту өчен күпме вакыт кирәк? дигәнгә: «Биш секунд»,— дип җавап кайтардылар. Әлеге җаваптан мин каушабрак калдым, ахрысы, алар «экран» һәм символлар ярдәмендә бу очышның нидән гыйбарәт бу-

луын күрсәттеләр. Башта «тәлинкә»не Җирдә, без урнашкан аланлыкта күрдем. Аннары панорама кушылды, ягъни спираль сыман җыела башлады. Күтәрелгән «тәлинкә» күздән югалды. Аннары спираль кирегә сүтелә башлады, икегә кушылган панорама ачылды, бер сызыкка сузылды, ягъни офык пәйда булды. Ул да булмады, «тәлинкә» Җир өстенә төшеп тә утырды. Алар үзләре теләгәнчә пространствоны кирәкле ноктада «сүтә» һәм «җыя» алуларын күрсәттеләр. Яныма ук килеп баскан гуманоидларның кешегә бик нык охшавын әйткән идем. Төс-битләре Европа кешеләренеке шикелле. Грек тибындагы дип әйтсәм төгәлрәк булыр. Чәчләре озын да, кыска да түгел. Уртача аксыл чәч. Буйлары да төрлесенеке төрлечә. Чама белән йөз сиксән сантимер булыр. Һәммәсе дә — ирләр. Йөзләрендә шатлык, сагыш, янсә елмаю күрә алмадым. Беренче хис белгертми торган катып калган йөз. Әмма бу кешеләрдән ниндидер җылы, мәрхәмәтлелек, киң күңеллелек, дустанә хисләр бөркелеп тора сыман. Алар янында үзеңне иркен, тыныч тотасың.

Алар мине үзләренә кунакка чакырдылар. «Кире әйләнеп кайтырбызмы соң?» — дип сорадым.— «Кайчан кайтырбыз?» — «Өлгерәбез әле»,— диделәр. Мин курка калдым. Ярый ла, йолдызга кунакка җаның-тәнең белән бергә очсаң. Әгәр бергә очмасаң? Шундук ризалык бирмәвем яхшы булган. Югыйсә, иптәшләрем мине үлгәнгә санап, җансыз яткан гәүдәмне җирләргә җыенган булганнар. «М өчпочмагы»ннан киткәндә йолдыз кешеләре миңа код бирделәр. Аның ярдәмендә мин Молебка авылындагы гуманоидларны Ригада да элемтәгә чакыра алам.

— Сез әлеге мөмкинлектән файдаланып, үзегезне кызыксындырган сорауларга җавап алырга, кайбер мәсьәләләрне хәл итүдә булышуларын сорамадыгызмы?

— Пермь өлкәсенең Молебка авылына без шундый максат белән килгән идек: башка цивилизация (сталкерлар телендә «ВЦ» дип йөртелә) әһелләре ярдәмендә Бөек Ватан сугышы елларында фашистлар талап алып киткән гәрәбә бүлмәнең язмышын ачыкларга. Әмма галактикадан килүчеләр: «Бу — кешеләрнең үз эше, сезнең тормышка, эшләрегезгә катышырга, тыкшынырга безнең хакыбыз юк. Сез — ирекле кешеләр»,— дип йомшак кына баш тарттылар. Тунгус метеориты, Атлантида сере, өчпочмак рәвешендәге символның нәрсә аңлатуын да җавапсыз калдырдылар. Әмма ВЦ белән элемтәләр вакытында мин байтак сорауларыма җаваплар алдым. Түбәндә кыскача шулар белән таныштырып үтәсем килә.

— Без — Җир улларымы?

— Юк. Сезне без башка цивилизациядән алып килдек. Сез — безнең улларыбыз, кече туганнарыбыз.

— Сез безнең ата-бабабыз булгач, сезнең ата-бабаларыгыз кемнәр?

— Алар башка йолдызларда, галактикаларда яшиләр, аларның ата-бабалары башкаларында...

— Иисус Христос булганмы?

— Әйе, 888 — Христос саны.

— Алла бармы?

— Алла ул — Югары Акыл. Сезнең өчен без — Алла.

— Галәмдә безнең кебек кешеләр яши торган башка планеталар тагын бармы?

— Бар. Җир йөзендә генә дә сездән башка тагын ике цивилизация яши. Алар башка үлчәмдә гомер итә. Без аларны да күзәтеп торабыз. Берсе үсеш ягыннан сездән бик күпкә алга киткән. «Икенчесен миңа да күрсәттеләр. Әлегә анда XVI гасыр. Дөрес, мин феодал замокларын да, рыцарь турнирларын да күрмәдем. Ул цивилизациядәге җир сөрүче крестьяннарны, яшеллеккә күмелеп утырган авылларны күрергә мөмкин булды»,— ди В. Коршунов.

— Без, кешеләр,— сезнең улларыгыз. Сез кешеләргә ата-аналар үз балаларын кайгырткан кебек булыша аласызмы?

— Без кешеләргә бары тик яхшылык кына телибез. Сезгә бик теләп булышыр идек, әмма сез безнең ярдәмне кемнәндер өстенрәк булу өчен яисә явыз ниятләрдә файдаланырга тырышасыз.

— Чернобыль фаҗигасе бүген дә күпләрне борчый. Авария булыр алдыннан һәм фаҗигадән соң Чернобыль өстендә оча торган «тәлинкә»ләр күпләп пәйда булган, дип сөйлиләр. Беренче реакторны могҗиза аркасында гына шартламый калган диләр. Аның ничек шартламый калуы хәзергә кадәр галимнәрнең башына сыймый. Әгәр беренче блокта һәлакәт булса, калган өч реактор да шартлыйсы булган. Авария фаҗигаләрен кимету өчен сез нәрсә дә булса эшли аласызмы?

— Без булдыра алганның барын да эшләдек.

— Без, кешеләр, Җир шарын шундый фаҗигаләрдән саклау, һәлакәтләрне булдырмау өчен нишләргә тиеш?

— Үз өстеңдә эшлә, акылыңны бает, намусыңны чиста тот. Көнләшү, нәфрәт, явызлык, эчкерлелек кебек сыйфатлардан, начар гадәтләрдән арын. Үзең чиста, намус-

лы, гадел булсаң, җәмгыятьне дә чиста, гадел итеп булачак.

— Безнең киләчәгебез өметлеме, барыр юлыбыз дөресме? Кешелек дөньясын 2000 елны һәлакәт көтә, кыямәт көне җитә, дигән сүз дөресме?

— Технократик юлдан китү аркасында кешелек дөньясы зур ялгышлар ясады. Сез химия, автомобиль гигантлары кору белән мавыгасыз, табигатьне пычратасыз. Моның нәтиҗәләрен сез шунда күрәчәксез: гасыр азагына эчә торган су запасының 17—18 проценты гына калачак. 2000 елны дөнья бетәчәк дигән сүзгә ышанмагыз, Җирнең язмышы — сезнең кулда.

— Сез закон төшенчәсен ничек аңлыйсыз? Сездә законнар бармы? Нинди кануннар буенча яшисез?

В. Коршунов бу сорауга җавап рәвешендә үзенә § билгесен күрсәтүләрен әйтте. Башка цивилизациядә законнарның бер параграфын үтәмәү — һәлакәткә тиң. Сталкер шунысына игътибар иткән: башка цивилизациядә бер параграфның койрыгы икенчесенекенә тоташкан. Ни өчен Җирдә, безнең җәмгыятьтә законнарның көчсез, гаделсез, кайберләренең хәтта мәгънәсез булуы шуннан аңлашылыр. Чөнки бездәге законнар бер-берсенә бәйләнмәгән, кайберләре хәтта бер-берсенә каршы килә, берсе хуплаганны икенчесе инкарь итә, юкка чыгара.

— Кеше үлгәч, аның җаны кая китә? «Теге дөньяда яшәү» дигән нәрсә хакмы?

— Адәм баласы вафат булгач, аның биоэнергетик көче тугызынчы көнне Җирдән аерыла. Кырыгынчы көнне ул күккә иңә, икенче дөньяда яши башлый. Адәм җанының индивидуаль йөзе саклана. Катлам-катлам булып урнашкан икенче дөньяга күчкәч адәм җаны бер дәрәҗәгә күтәрелә, үз тиңнәре арасында яшәвен ул шулай дәвам иттерә.

— Кешенең биокыры мәңгелекме?

— Икенче дөнья Җир шарының яшәвенә бәйле. Җир йөзендә тереклек бетсә, икенче дөнья да юкка чыгачак.

Бер караганда акылга сыймый торган, әкиятләрдә генә була торган шундый хәлләргә, могҗизаларга очраганнар сталкерлар. Бәлки без Җирдән читтә яшәүче цивилизацияләр белән уртак тел табу, аралашу гасырының бусагасы булган унъеллыкта яшибездер? Чыннан да, башка цивилизацияләр белән элемтә урнаштырган кешеләрне инде Мәскәү, Ленинград, Рига шәһәрләрендә шактый диләр. Иртәме-соңмы аларның Казанда, Татарстанның башка шәһәрләрендә дә пәйда булуы ихтимал. Чөнки шундый

элемтәдә торучылар киләчәктә бу кешеләр саны геометрик прогрессиядә артачак, диләр. Хәтта Мәскәүдә башка цивилизацияләр белән бәйләнеш тотучыларның Үзәге дә оештырылды.

Ярый, без Дарвин теориясе буенча маймылдан килеп чыккан кешеләр булмыйк та, ди. Әмма Җир шарын атомтөш сугышы, экологик һәлакәттән башка цивилизация әһелләре саклап калыр әле дип тынычлану зур хата булыр иде. Әйе, без — маймыл түгел, безгә Җирдә адәм төсле яшәү өчен акыл, иман, вөҗдан бирелгән. Бер нәрсә ачык: Җир шарын, димәк Мәңгелекне Кешелеклелек, Матурлык, Изгелек, Игелек, Намус, Мәхәббәт, Шәфкатьлелек, Аек акыл гына саклап калачак.

Газинур Вәлиев

ГОМЕРЛЕК МАКСАТ

Татарның Шерлок Холмсы кем икәне беләсезме? Гафу, болай дип сорау бик үк төгәл булмас. Сорауны болайрак куйыйк: татарның Конан Дойлы дип кемне саныйсыз? Күңелегездән, детектив, маҗаралы хәлләр, җинаятьчеләрне эзләүче тикшерүчеләр, касса, кибет басу тарихы турында кызыклы итеп язучы әдипләрне барлый башлагансыздыр. Кемдер күңеленә килгән беренче авторны, мәсәлән, Мәгъсүм Насыйбуллинны яки Шамил Шәйдуллинны әйтер. Кемдер хәзерге заманны түгел, элекке чорны исенә төшерер һәм язучы Заһир Бигиевнең «Меңнәр яки гүзәл кыз Хәдичә» әсәрен телгә алыр... Ул да детектив роман дип аталырга хаклы ич. Бар үтереш, бар интрига, бар җинаятькә сәбәп булган меңнәр... Кемгә ничектер, мин үзем татарның Артур Конан Дойлы дип язучы Зөфәр Фәтхетдиновны саныйм. Аның белән танышуым да детектив китаплардагы кебек искәрмәгәндә, очраклы рәвештә булды.

Кич иде. В. И. Ленин исемендәге республика фәнни китапханәсенең туган якны өйрәнү бүлегенә озынча буйлы, какча гәүдәле, 40—45 яшьләрендәге ир килеп керде. Исәнләшеп өс-башын чишенгәч, өстәл артына утырды. Гөларам ханым аңа Ходаковның сирәк очрый торган китабын китереп бирде. Мин ана башта игътибар да итмәгән идем. Китапханәнең даими укучысы пенсионер Фатыйма апа ул иптәшнең кем һәм кайдан булуын белергә теләп сүз катты. «Бәлки иштеткәнсегез, китапларымны укы-

ганыгыз да бардыр. Мин Мәскәүдән, язучы Зөфәр Фәтхетдинов булам»,— дип җавап бирде ул. Детектив китаплар авторы, юридик фәннәр докторы, профессор Зөфәр Мәгъсүм улы Фәтхетдинов белән танышлыгыбыз әнә шуннан башланды.

— Вакытым булган саен Казанга юл тотам. Лекцияләрдән бушаган арада, өч көнгә генә булса да кайтып килим дип кайттым. Казан — ул ачылмаган серләр дөньясы. Монда кемнәр генә булмаган! Патша, император дисеңме, даһилар, атаклы кешеләр дисеңме! Ул шаккатыргыч маҗаралы хәлләргә килгәндә Казаннан да кызык урын юктыр. Казанда яшәүче язучыларга гаҗәпләнәм мин. Аларның кул астында никадәр бай материал, нинди бай, кызыклы тарих! Тарихи роман язасыңмы, маҗаралы повестьмы — әллә ничә томга җитәрлек.

Мин хәзер «Өрәк төн уртасында килә» исемле романымны тәгәлләп киләм. Ул — трилогиянең өченче китабы булачак. Беренчесе «Үлем әлмәге» дип атала. 1990 елны Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты. Икенче китабымның исеме — «Кара тол» кушаматлы резидент» Анысын 1991 елда бастыру өчен Мәскәү нәшриятына тапшырган идем.

Трилогиянең өченче китабында 1917 елны Казанда булган вакыйгалар сурәтләнә. 1917 елның 14 август төнендә Казанда бик зур шартлау була. Дары заводының көле күккә оча. 100 меңнән артык артиллерия снаряды шартлый. Ул шулкадәр көчле шартлау була ки, шәһәрдәге барлык йортларның тәрәзәләре коелып төшә, ә шартламаган снарядлар алты километрга оча. Ул елдагы кайбер газеталар язганча, әлеге һәлакәт детонациядән килеп чыкмаган. Архивларда утырып, шул чордагы Казан, Мәскәү, Петроград газеталарын өйрәнеп, мин шундый нәтиҗәгә килдем: бу — Кайзер Германиясе разведкасы эше. Башка берни дә түгел, гап-гади диверсия. Россия белән сугыш алып барган Германия разведкасы тимер юлларны өзү, дары заводларын шартлатуны үз алдына стратегик максат итеп куйган була. Казанда алар моңа ирешәләр. Дары заводы ул чорда зурлыгы, әһәмияте ягыннан Россиядә икенче урында торган. Бер яктан Кайзер Германиясе агентурасы, икенче яктан ЧК, өченче яктан Самара хөкүмәтенә каршы көрәш романымның сюжет сызыклары булып торалар.

— Сез хәзер кем: галимме, әллә язучымы?

— Галим дә, язучы да. Хәзер Мәскәүнең электрон машиналар төзү институтында хезмәтне һәм табигатьне сак-

лау, хокук кафедрасына җитәкчелек итәм. СССР Эчке эшләр министрлыгы академиясенең, Мәскәү дәүләт университетының докторлык диссертацияләре буенча гыйльми советларының әгъзасы булып торам. СССР Законнары эшләгәндә Министрлар Советы комиссиясендә консультант буларак катнашам. Академик Л. Абалкинның «акыл үзәге»нә («мозговой центр») керәм.

Казан белән дә араны өзмим. 1986, 1988 елларда В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының юридик факультетында дәүләт имтиханнары кабул итү комиссиясе рәисе булдым. Берлин, Прага университетларында немец телендә лекцияләр укыйм, социалистик илләрнең академик журналларына фәнни мәкаләләр язгалыйм.

— Сез ничек язучы булып киттегез? Мәктәптә укыганда шигырь, хикәяләр яза идегезме? Язучылык эше укытучылык, гыйльми эшегездә комачауламыймы?

— Фәнни мәкаләләр, китаплар теле әдәби әсәрләр теленнән нык аерыла. Иң авыры — тел өстендә эшләү. Телдәге кытыршылыклар, рәсмилек, циркулярлык, корылыктан котылу авыр. Мәктәптә укыгандагы кебек сочинение күчереп кую гына түгел бу. Беләсезме, мин хәзерге мәктәп балалары кебек 11 класс бетергән кеше бит. Җиденче класста укыганда бер ел күчми калдым. Шул рус теле һәм әдәбияты аркасында инде. Сочинениеләрне гел «икеле»гә яза идем. Үземнекеләр булса бер хәл иде, гел кешенекен күчерәм. Әле дә хәтердә: безгә «СССР халыклары әдәбиятында социалистик реализм» дигән темага инша язарга куштылар. Туктале, мәйтәм, бер шаккатырыйм әле боларны. Гел кешенекен күчерү эш түгел, үз башым белән языйм әле. Яздым да соң! Аны укыгач ыржаеп көлделәр, мыскылладылар. Моңа бик гарьләндем. Аннары мәктәпне бетергән, яисә югары класста укучыларның иншаларын җыеп алам да күчереп бирә идем. Укып бетергәнче шулай эшләдем. Хет хатасыз булсын, хет биш урынына ун бит яз — «өчле»дән артыкны куймыйлар иде.

Язучылыкка тотынуым тагын да кызык булды. 37 яшемдә докторлык диссертациясе язып тәмамладым. Ул чакта Казанда һәм Мәскәүдә хокук белемнәренә кагылышлы ике китабым, илледән фәнни мәкаләм басылып чыккан иде. Миңа шундый киңәш бирделәр: агай-эне, бездә фән докторларының уртача яше — 56, сиңа әле кырык та тулмаган. Өч ел көт, аннары карарбыз. Туп-туры шулай дип әйттеләр. Нишләргә? Өч елны заяга уздырыйммыни?

Тотындым детектив повесть язарга. Яздым. Бөек Ватан сугышында һәлак булган абыйларым Мирза һәм Әсрар Фәтхетдиновларның якты истәлегенә багышланган әсәремне «Молодая гвардия» нәшриятына илттем. Укыдылар. Повестеңны калдыр, дүрт елдан бастырып чыгарырбыз, диделәр. Дүрт ел миңа бик озак тоелды. Казанга алып кайтып Татарстан китап нәшриятына тәкъдим иттем. Шулай итеп 1982 елны беренче повестем басылып та та чыкты.

— Сезнең кайсы повесть яки романыгызны алсаң да, анда татар исемнәрен, фамилияләрен очратасың. Күп вакыт Казанда булган вакыйгалар сурәтләнә. Казанка елгасы, Уң Болак урамында булган җинаять телгә алына. Минем уйлавымча, сезнең әсәрләрегездәге Святовск Свияжск, ә Светловолжск Казандыр кебек. Ә менә «Военный следователь» повестенда төп герой татар язучысы, шагыйрь Зәки Шәрәфетдин улы Нуретдинов (Зәки Нури) фамилиясен йөртә. Болар очраклы хәлме, әллә сез аларны әсәрләрегезгә аңлы рәвештә керттегезме?

— Мин Кострома шәһәрендә тусам да, яшьлек, студент елларым Казанда узды. Дөрес, башта өч ел армиядә хезмәт итеп акылга утырып кайтырга туры килде. 1962 елны Казан университетының юридик факультетына укырга кердем. Әтием — инвалид, әнием өйдә генә эшли, ярдәм көтәр кешем юк. Шуңа күрә бик тырышып укыдым, вакытның кадерен белергә өйрәндем. Тора-бара стипендиямне күтәрделәр. Яхшы укырга омтылыш шулкадәр көчле булган: мәктәптә «дүртле» алсам, түшәмгә сикерә идем, ә университетта «дүртле» алсам, бер атна балтасы суга төшкән кешедәй йөрим.

Укыганда 1 разрядлы чаңгычы, йөгерешче, биатлончы идем. Факультет, университет ярышларының берсен дә калдырмыйм, гел җыелма команда составында булам. Беренчелекне бирәүгә дә бирмибез. Тренерым Сабир Нәфыйковны әле дә хөрмәт белән искә алам. Ул бездән чаңгы буенча спорт мастерлары әзерләү максатын куйды. Мин мастер дәрәҗәсенә тарта алмасам да (ул чакта мастерлыкка кандидат дигән нәрсә юк иде әле), өч-дүрт кеше спорт мастеры исемен алды. Спорт миңа ихтыяр көчен тәрбияләргә булышты. Бу дөньяда акыл белән генә яшәп булмый. Ихтыяр көче дә кирәк.

Казанда укыганда вакытның кадерен белергә өйрәндем. Шул еллардагы гадәт буенча мин хәзер дә чират торганда, автобустамы, трамвайдамы, метродамы — кечкенә китап чыгарам, укыйм, башка килгән фикерләрне

куен дәфтәренә теркәп куям. Якутлар табыладыр вакыт белән... Вакыт — ул байлык, хәзинә. Аны әрәм-шәрәм итмәскә, файдалы эшкә тотарга кирәк. Үз алдыңа куйган зур максатларны ун, унбиш елдан тормышка ашырырмын, бүген түгел, иртәгә тотынырмын дип уйлама. Бүгеннән, хәзердән үк тотын, мая башы тупланa торсын.

Университетны тәмамлагач, аспирантурада калырга бик теләсәм дә, калдырмадылар. Туган шәһәрем Костромага кайтып прокуратурада тикшерүче булып эшли башладым. Төрле хәлләргә юлыктым: мәетләрен дә, законны бозуларны да күп күрдем. Хәтта бервакыт ишек катында саклап торып башыма тимер белән дә суктылар. Чик буе гаскәрләрендә хезмәт итүем ярап куйды: бандитларның икесен ике якка селтәп аттым. Телефоннан яңаулар, мине кайбер эшләрдән читләштерергә маташулар да булды. Торгынлык еллары галәмәте: җинаять эше берәр җитәкче, начальникка барып тоташса, аны йомып калдыралар, я тизрәк «ябып» куялар иде. Көндез җинаятьчеләр эзлим, тикшерәм, төнге уникедән иртәнге өчкә кадәр чаңгыда йөрим, аннары китапка тотынам, аспирантурага әзерләнәм. Дүрт ел буе тәүлеккә 3—4 сәгать кенә йоклый идем. Ул бушка узмады, мин Мәскәү университеты аспиранты булдым. Шунысын да әйтим: Казан университетын тәмамлап ун ел узгач кына үз гомеремдә беренче тапкыр ял йортына бара алдым. Ул чакта миңа 37 яшь иде.

Әсәрләремдәге татар исемнәре әнә шуннан. «Тайна стоит жизни» (ул «Казан утлары» журналында «Ачылган серләр» исеме астында басылды) повестенда төрле милләт кешеләре — татарлар, руслар, яһүдләр арасындагы дуслыкны күрсәтергә теләдем. Дустыңның кем булуын иң авыр чакта белерсең, диләр. Тикшерүчеләр, милиция хезмәткәрләре иң четерекле, экстремаль, катлаулы хәлләрдә калалар, үлем белән йөзгә-йөз очрашалар. Менә шул чакта иптәшлек, чын дуслык беленә дә инде.

Без күп вакыт кешенең кадерен ул якты дөнья белән саубуллашкач кына беләбез. Тукай әйтмешли, без аны каян белик, үзе үлеп аңлатмагач. Нишләп киресенчә булмаска тиеш? Шуңа күрә мин үз әсәрләремдә замандашларым Равил Шәрәфиев, җырчылар Мөнирә Булатова, Вафирә Гыйззәтуллинаны, Г. Камал исемендәге академия һәм М. Җәлил исемендәге опера-балет театрларын телгә алдым, әсәрләремә керттем. Үлгәннең түгел, исәннең кадерен белергә кирәк. Халкыбызның культура казанышларын, яхшы, күренекле кешеләрен күрсәтергә, дәрәҗәбезне

гел күтәрергә кирәк. «Военный следователь» повестен мин Бөек Ватан сугышы елларында Константин Заслонов җитәкчелегендәге партизаннар отрядында разведчик булган Зәки Нури сөйләгәннәрдән чыгып яздым. Шуңа күрә төп геройның исем-фамилиясен үзгәртмичә калдырдым.

«Шул повестьта хәрби тикшерүченең бик кызыклы шөгыле, хоббие турында әйтелә. Ул канатлы, тылсымлы сүзләр, акыллы гыйбарәләр уйлап чыгара. Буш вакыты булган саен уйлана, фикерләрен кесә дәфтәренә теркәп куя. Болай эшләү аңа — разведчикка хәтта катлаулы хәлләрне тикшерергә, дөрес юлны сайларга, җинаятьнең җеп очын табарга да булыша. Шагыйрь Зәки Нуриның шундый шөгыле булганмы, әллә бу мавыгуның сезгә дә катнашы бармы?

— Бар, бик бар! Беләсезме, мин уникe ел буе үзем уйлап чыгарган канатлы сүзләр, максимнарны җыеп бардым. Алар хәзер 600 дән артып китте. Алтмышлабын мин «Военный следователь» повестенда кулландым. Гомеремнең иң зур максаты — татарның Ларошфукосы, Козьма Прутковы булу. Без инглиз халкының бөеклеген, акылын, кодрәтен Ларошфуко, Честерфильдның канатлы сүзләре, акыллы гыйбарәләре, хатлары тупланган китаплары буенча беләбез. Нәрсә генә юк анда: халыкның әдәп кагыйдәләре, иманы, бөеклеге, культурасы, тормыш-көнкүреше, акылы... Честерфильдның улына хатларын укып карагыз. Яшүсмерне олы тормыш юлына менә дигән кеше, чын гражданин итеп әзерләүдә һәркемгә кулланма булырлык, әдәп, сафлык, итагатьлек кагыйдәләре тупланган кодекс бит бу. XVIII гасырда язылган шул китапны бүген дә кызыксынып, яратып укыйсың, тормышыңа кулланма итеп аласың.

Элгәре мин гел фән дип яшәдем. Теләгемә ирештем. Аннары төп максатым канатлы сүзләр, максимнар китабы чыгаруга әверелде. Фән эшенә хобби дип карый башладым. Кыйммәтләр урыннарын алышты. 600 максим арасында бар үземә нык ошаганнары, бар иптәшләрем, дусларым күңеленә хуш килгәннәре, бар уңышлылары, йомшаграклары. Нәшриятка илтеп тапшыргач ышанасылары килмәде. Гаҗәпләнделәр. Зур язучылар ошатты ошатуын. Гади укучы боларны аңлый алмас дип әйтүчеләр дә булды. Әнә шул канатлы сүзләр, хикмәтле гыйбарәләр, максимнар китап булып чыкса, бу дөньяда үз эшемне башкардым дип санар идем.

— Канатлы сүзләр, гыйбарәләрне ничек уйлап чыгарасыз, бу шөгыль күпме вакытыгызны ала?

— Канатлы сүз яки гыйбарә языйм әле дип махсус утырганым юк. Башка язучылар китапларын укыганда башка кылган фикерләрне теркәп куям. Акыллы сүзләр чыганагы — тормыш үзе. Күзәтәсең, әйләнә-тирәндә яшәүчеләрнең тормыш-көнкүрешен, гади халык белән җитәкче работниклар арасындагы мөнәсәбәтне өйрәнәсең, уйланасың, чагыштырасың. Менә Казанда кунакханәгә туктагач бер танышым чиновникның үзен ничек мыскыллавын сөйләде. Мин бу очракны болай бәяләдем: «Минминлеге чамадан ашкан чиновник үтенеч белән килгән кешенең түбәнчелек белән соравыннан никадәр ләззәт тапса, шулкадәр бу үтенеч аның җенен чыгара». Китапка керәчәк тагын бер афоризмның мәгънәсе болай. Бу дөньяда яшәүчеләр дүрт төркемгә бүленә. Эгоистлар — үз кайгысын гына белүчеләр. Тере түмгәкләр — кеше кайгысы иртә керә, кич чыга торган кешеләр. Альтруистлар — кеше кайгысын йөрәкләренә якын алалар һәм ярдәм кулы сузалар. Ә менә дүртенче төркемгә мин бөек гуманистларны, иң кешелекле кешеләрне, кеше кайгысын ишетүгә, күрүгә түгел, хәтта күзаллауга ук борчыла башлаучы, шундук ярдәм кулы сузарга ашыгучы кешеләрне кертәм. Алар Ганди, Кинг, академик Сахаров, Әсгать Галимҗанов кебек кешеләр. Аларны мин өч меңенче елда яшәүчеләр дип саныйм.

Тукай бик белеп әйткән: халык зур ул, әдип ул, шагыйрь ул, дип. Канатлы, акыллы сүзләр, афоризмнар китабымда мин халкыбызның бөеклеген, зурлыгын, акыллы, әдәпле, кодрәтле, талантлы булуын күрсәтергә теләдем.

Газинур Вәлиев

КҮҢЕЛДӘН КҮҢЕЛГӘ

«Ничек дипломат булырга?» Дипломат булыр өчен кайсы уку йортын тәмамларга кирәк? Яшь кешенең башына мондый сораулар килүе бер дә гаҗәп түгел. Без һәр көнне зәңгәр экранга текәләбез, газета-журналлар

укыйбыз. Һәрхәлдә бүгенге заманда «дипломатия», «политика» дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә.

Күптән түгел хәбәрчебез СССР Тышкы эшләр министрлыгында Көньяк Азия илләре буенча советник булып эшләүче якташыбыз Йолдыз Хәлиуллинга мин (ул Казанга кунакка кайткач) шушы сораулар белән мөрәҗәгать иттем.

— Мин Әгерҗе районының Иске Кызылъяр авылында туып-үстем,— диде ул.— Дипломат булырмын дип бала чакта башыма да китермәгән идем. Электромеханика техникумын тәмамлагач, Краснодар шәһәрендә эшләдем. Армиядән кайткач Казанда берәр институтка керергә исәбем бар иде. Әмма шул вакытта Мәскәүдә Халыкара мөнәсәбәтләр институты барлыгын ишеттем. Бик дәрәҗәле институт, керергә дә бик кыен, имеш. Мин үземнең чит телләрне тиз үзләштерү сәләтем барлыгын сизә идем. Башка уй килде: ә нигә бәхетне сынап карамаска? Кем әйтмешли, кизәнәсең икән, зурдан кизән... Ләкин гаризаны биргәч шүрләп тә калдым: бер урынга унҗиде кеше! Шулай да, имтиханнарны уңышлы тапшырып, конкурстан уздым.

— Димәк, дипломат булыр өчен чит телләрне белү җитә?

— Алай димәс идем. Билгеле, чит телләрне белми торып, Халыкара мөнәсәбәтләр институтына керү турында хыялланырга да ярамый. Минемчә, дипломат бөтен яктан хәбәрдар булырга тиеш. Институтта минем белгечлегем Көньяк Азия буенча иде. Аеруча Пакистанның тарихын, бүгенгесен, халкының гореф-гадәтләрен, традицияләрен өйрәндем. Берәр илгә дипломат итеп билгеләнәр икән, син ул дәүләт турында барысын да белергә тиеш — тышкы һәм эчке сәясәтен дә, политик структурасын да, әдәбиятын да, мәдәниятен дә...

— Институтны тәмамлагач сезне Пакистанга билгеләделәрме?

— Мине башта аспирантурада калдырганнар иде. Әмма күп тә узмады, Тышкы эшләр министрлыгына чакырып: «Сезне Индонезиягә илчелеккә атташе итеп җибәрәбез»,— диделәр. Бөтенләй көтелмәгән тәкъдим булса да, мин каршы килмәдем. «Атташе» бик яңгыравыклы сүз, ләкин илчелектә ул иң түбәнге ранг санала. Шулай да кичәге студент өчен бу шактый ук зур мәртәбә...

— Тагын кайсы илләрдә эшләдегез?

— Пакистанда ун ел. Румыниядә дүрт ел эшләдем.

— Румыния татарлары белән очрашырга туры килмәдеме?

— Мин анда шактый күп татар яшәгәнен белә идем, ләкин аралашырга, очрашырга туры килмәде.

— Дипломат, гадәттә, полиглот та була. Сез ничә тел беләсез?

— Иң мөһиме — туган телемне беләм. Инглиз, рус, урду, төрек телләрендә яхшы аңлашам. Урду теленә күренекле язучыбыз Әмирхан Еникинең бер хикәясен дә тәрҗемә иттем. Татар әдәбиятына гашыйк мин. Индонезиядә булсын, Пакистанда булсын, «Казан утлары» журналын даими алып тордым.

— Якташларыбыз арасыннан , тагын дипломатлар бармы?

— Тышкы эшләр министрлыгында шактый күп якташларыбыз эшли. Гомумән, дипломатия өлкәсенә татарлар элек тә бик кыю үтеп кергән. XVI—XVII гасырларда татар теле Россиядә рус теле белән беррәттән халыкара тел ролен уйнаган. Элегрәк аның урыны тагын да зур булган. Бер генә мисал. Патша Иван III вакытында кайсыдыр илдән шиндидер чит телдә язылган хат килгәч, аны «рус, латин һәм татар телендә язылган хатларга гына җавап бирәбез» дип кире кайтаралар. Татар теле ул чакта Көнчыгыш илләре белән дипломатик мөнәсәбәтләрдә файдаланылган. «Патша хәзрәтләре» Алексей Михайловичның татарча язылган хаты да тарихка билгеле. XVIII гасырда язылган «Исмәгыйль сәяхәтнамәсе» әдәбиятыбыз җәүһәрләре рәтенә керә. Бу бик кызыклы әсәр. Исмәгыйль Бикмөхәмматов Һиндстанга Россия илчесе булып бара. Сәяхәтнамә әдәби әсәр генә түгел, ул шул вакыттагы сәяси атмосфераны, Россиянең көнчыгыш политикасын чагылдырган тарихи документ та... Тышкы эшләр министрлыгының архивында мин Исмәгыйль Бикмөхәмматовның донесениеләренә дә тап булдым. Бу кеше — бик кызыклы шәхес... Дипломатиядән башка, аның патша тарафыннан кушылган бүтән вазифалары да булган шикелле. Шуны әйтәсем килә: халкыбызның тарихы бай, архивларда күпме документ тузан җыеп ята, татар яшьләре тарихыбызга игътибарлырак булсыннар иде.

Халыкара мөнәсәбәтләр институтында, сирәк булса да, якташларыбыз укый. Мәсәлән, бу уку йортын ике ел элек Чирмешән егете Шамил Ногманов тәмамлады, аннары ул Әфганстанда тәрҗемәче булып эшләде.

— Сез халыкара күзәтүче Фәрит Сәйфел-Мөлеков белән танышмы?

— Яхшы таныш. Ул үзе Үзбәкстанда туып-үскән. Кече яшьтән үк үзебезнең татар теленә, татар әдәбиятына, татар мәдәниятенә гашыйк кеше. Сирәк булса да, без аның белән үз телебездә сөйләшеп утырырга яратабыз.

— Казанга сез еш кайтмыйсыз. Үзгәрешләр сизеләдер?

— Әлбәттә. Казан зурая, матурлана, яңара. Әмма бу яңарыш иске тарихи биналарны җимерү хисабына бармасын иде. Казан безгә борынгы, тарихи шәһәр буларак кадерле. Мин бирегә кызым Гөлнара белән кайттым. Рухи башкалабыз аңа бигрәк тә ошады. Сөембикә манарасы янында озак басып тордык...

— Яшьләргә теләкләрегез бардыр, Йолдыз Нуриевич?..

— Үз телебезне, үз тарихыбызны яхшы белергә тырышыгыз, шул очракта гына башка халыклар күңеленә үтеп кереп була.

Әңгәмәне *Ркаил Зәйдуллин*
алып барды

ЭЧТӘЛЕК

Җырчы. *Эльс Гаделев* 3
Гармун бәләкәй булса да... *Хәррас Әюпов* 8
Сүз көче. *Шамил Маннапов* 13
Сәхнә баскычларында. *Язилә Абдулкадыйрова* 17
Кеше сынлы өермә. *Замир Низаметдинов* 25
«Һәр язмышта — күңелем җылысы». *Илдус Сафин* . . . 32
Ул — каеннар иленнән. *Госман Гомәров* 36
«Иң яхшы әсәр әле язылмаган». *Рина Зарипова* 40
Хыялымда — матурлык. *Рина Зарипова* 43

Һәр дәресе — бер тарих. *Мөдәррис Әсъләмов* 46
Теле барның даны бар. *Мөдәррис Әсъләмов.* 50
Заман әлифбасын кем язган? *Газинур Вәлиев* 53
Бөреләр уянганда. *Сәйдә Зыятдинова* 58
Мең рәхмәт сезгә. *Язилә Абдулкадыйрова* 64

Барысы да аның турында. *Фәүзия Бәйрәмова* 68
Урман шавы. *Фәнзаман Баттал* 76
Үзең өчен генә яшәмә. *Хәмзә Зарипов* 79
Арендатор Нәфыйк. *Фәнзаман Баттал* 83
Канатларыгыз талмасын, акчарлаклар. *Газинур Вәлиев* . . 87

Иң шифалы дәва. *Шамил Маннапов* 92
Таш гасырдан мирас булып. *Рина Зарипова* 96
Чәчәкләр. *Нурислам Хәсәнов* 99
Менә нимасам могҗиза! *Клара Гыйлаҗева* 103
Аюлар, бакалар... һәм кошлар докторы. *Язилә Абдулкадыйрова.* 108

Җиңү китерүче дулкыннар. *Айрат Садыйков* 112
Шашкага — шахматтан. *Айрат Садыйков* 114
Алисә — гроссмейстер. *Атлас Гафиятов* 117
Бөркет күңеле кыяда. *Язилә Абдулкадыйрова* 123
«Хөкем — соңгы чик». *Нурсали Булатов* 128
Егерме мең ел бергә! *Язилә Абдулкадыйрова* 134
«Күктә — төн пәриләре». *Язилә Абдулкадыйрова* . . . 138
Юллар дәшә еракларга. *Мирхәт Хөснимәрдәнов* 142
Тәвәккәл таш яра. *Мәгъсум Гәрәев* 147
Җиде кат җир астында. *Газинур Вәлиев* 151

Галәмгә юл. *Газинур Вәлиев* 159
Гагарин отрядыннан берәү. *Айрат Садыйков* 166
Без — Җир улларымы? *Газинур Вәлиев* 171

Гомерлек максат. *Газинур Вәлиев* 181
Күңелдән күңелгә. *Ркаил Зәйдуллин* 187

Массово-политическое издание

Коллектив

ВЫБИРАЙ НА ВКУС

(на татарском языке)

Художество редакторы *Ш. К. Насыйров*
Художнигы *Б. А. Чукомин*
Техник редакторы *Ф. Х. Абдрахманова*
Корректорлары *Р. С. Хәмидуллина, Т. Р. Шакирова*

ИБ № 5865

Җыярга тапшырылды 17.05.90. Басарга кул куелды 30.07.90. ПФ 01144. Форматы $84 \times 108^{1}/_{32}$. Типогр. кәгазе № 2. «Литературная» гарнитурасы. Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 10,08. Шартлы буяу-оттиск 10,50. Нашер-хисап табагы 10,77. Тиражы 3500 экз. Заказ Л-232. Баясе 40 тиен.

Татарстан китап нашрияты.
420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство.
420111. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия
һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының
Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты.
420111. Казан, Бауман ур., 19.

40 тиен